Безнең Мирас
НАШЕ НАСЛЕДИЕ
12
декабрь 2021
ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

С.Хәким һәм Г.Әпсәләмов

«Байлар гадәтенчә көчәнмәгез!»
4 бит

Батый хан архивы: ике көн мичтә яндырылган
38 бит

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС
12 +

12
(336)
декабрь 2021

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ильяс Җиһаншин
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Рүзәл Мөхәммәтшин
Данил Салихов
Индус Таһиров
Данис Шакиров
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Алмаз Фәйзуллин
(843) 222-09-83 (17-92)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энҗе Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-93)

SMM-белгеч
Ләйләгөл Сафина
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал
(на татарском и русском языках)

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Сибгат Хәким

ТАРИХИ МИРАС

4 «Байлар гадәтенчә көчәнмәгез!» *Л.Габдрафикова*
10 Нагайбәк туганайлар, сез кайдан? *Ф.Закиров*
17 Татар эшкуарлары: авылдан шәһәргә таба. *Ж.Миңнуллин*
24 Кырымда татар тамгалары. *Г.Акчокраклы*
30 Бараҗ нәселе яки Иске Сәфәр авылына кем нигез салган? *Р.Сәетов*
34 Коточкыч ачлык. *Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин*
38 Батый хан архивы: ике көн мичтә яндырылган. *М.Госманов*
44 Гәүһәршад. *Ф.Зариф*

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

ТАТАР ГАМЕ

48 Туксанбайда – Акмулла авылында. *Л.Лерон*

53 Мифтахетдин Акмулла шигырьләре

54 Иске Сәфәрдә – китап бәйрәме

56 «Безнең мирас» котлый!

ДИНИ МИРАС

57 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*

64 «Тәбәнәк Бохаралы»ның бөек эшләре. *И.Җиһаншин*

69 Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре. *Ә.Рәхими*

70 Дин дәресләре. *С.Бикбулат*

ӘДӘБИ МИРАС

72 Татар мөһаҗире Рәсәйнең элеккеге башкаласында. *Х.Миңнегулов*

75 Хәсән Туфан һәм Сирин. *Ә.Шәрипов*

78 Сүз шатлыгы. *Ф.Зөлкарнәй*

82 Зәки Нури шигырьләре

84 Җыр белән атлыйбыз. *Ш.Юзеева*

88 Үткәннән хатлар

90 «Бу дөньядан китеп барсам әгәр...» *Ф.Яруллин*

92 Милләт гамьле Флера. *Р.Шәрафиев*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

97 Каһарман язучы. *Р.Мөбарәкшина*

100 Кара тәкъдир. *Р.Батулла*

102 Истә, һаман да истә!

СӘНГАТИ МИРАС

106 «Кәләү Гайшә» җыры

ШАЯН МИРАС

108 Көлке куа килә...

БАЛАЧАК МИРАСЫ

110 Без барыбыз да – балачактан

112 «Безнең мирас» хәбәрләре

114 «Безнең мирас» журналының 2021 елга библиографиясе

118 Мирасворд

119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Декабрь*

Заказ №Е-3970. Тираж – 3032 данә. Формат 70х100 1/16
Басарга кул куелды: 29.11.2021. Чыгу көне: 06.12.2021.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә:
Сибгат Хәким (уңда) һәм Габдрахман Әпсәләмов

Югалтуның ни икәнен белә,
Югатуны белми һич йөрәк.

Сибгат Хәким

Сибгат Хәким хатыны Мөршидә Вилданова белән

СИБГАТ ХӘКИМ
(4.12.1911-3.08.1986)

***

Җыр язмышы – кош язмышы кебек,
Бер тирәдән үтә юллары;
Җыр да кайчак егылып төшә җиргә,
Күтәрелә кайчак югары...

***

Безнең буын – озын чылбыр ул,
Кырлар буйлап узган юлдыр ул.
Озын чылбыр. Бик күп боҗралар.
Ул боҗралар – бар да без алар...

***

Тукай, Тукай – татар халкының ул
Бугазында газап төере...

***

Туган як – сандык, зәңгәр күк –
Өстендәге сырмасы...
Сандыкта яткан сөлгеләр –
Һәркайсы бер җыр башы.

***

Картайгач төшкән мәхәббәт
Булмый әүвәлге кебек.
Августта чәчәк күрсәтеп
Алган бәрәңге кебек.

***

Калды күңелдә авылның
Догалы кичке яме;
Агач башы тәсбих тарта,
Яфраклар – дисбеләре.

*Текстны журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №12 декабрь 2021

«Байлар гадәтенчә көчәнмәгез!»

(Ризаэддин Фәхреддин һәм татар модасы)

Лилия Габдрафикова

Ризаэддин Фәхреддин гаиләсе белән. 1905 ел

XIX гасырның соңгы чирегеннән татар халык киемендә зур үзгәрешләр күренә башлый. Бу яңа шәһәр модасына иярү татар түрәләре һәм сәүдәгәрләреннән башланган күренеш. Ике гасыр чатында ул шаукым кайбер муллалар гаиләсенә, бигрәк тә шәһәр җирендә торучыларга да үтеп керә. Әлбәттә, укымышлы һәм яшь, заман сулышы белән кызыксынучан, гыйльми һәм башка төрле дөньяви яңалыклардан да хәбәрдар булган Ризаэддин Фәхреддин татар тормышының ауропалашуыннан читтә калмаган. Һәм аның үзенең киенеп йөрүендә дә, төрле хезмәтләрендә дә шушы чорның кием-салымындагы үзгәрешләре вә мода мәсьәләсе чагылыш тапкан.

Әлегә кадәр Ризаэддин Фәхреддиннең мирасына мода, имидж һәм, гомумән, гади яшәеш күзлегеннән караучы бик күренмәгәнгә, без бу юнәлешне күзәтергә булдык.

«Саескан кебек иярмәгез!»

Ризаэддин Фәхреддин «Нәсыйхәтләр» сериясендә чыккан китапларында кием мәсьәләсенә дә кагылып китә. Ул бу хакта ир һәм кыз балаларны тәрбияләүгә багышланган китапларында да яза. Икесендә дә «Кием әдәпләре» дигән баб бар. Киемнәрне пакь һәм тәртипле йөртүдән тыш, ул киемгә *«артык байлык»* һәм *«гомер»* исраф итмәскә өнди. Галим бик зәвыклы, кыйммәтле әйберләр белән дә мавыкмаска куша. *«Төсе гүзәл, чыдавы аз булган киемнәрне сайлау – дөнья гыйльмен белмәү галәмәтедер»*, – дип яза ул, ягъни кием еш алыштырган кешеләрне булдыксыз, рациональ түгелләр дип саный.

Шуңа күрә ир-атларга, балаларга да, кызларга да Р.Фәхреддин кием белән артык нык мавыкмаска һәм бигрәк тә башкаларга иярмәскә киңәш итә. *«Кием кию турысында үзегезгә иш булмаган кешеләргә саескан кебек иярмәгез! Киемнәр белән мактанмагыз!»* – ди ул егетләргә. Кызларга исә мондый нәсыйхәтләр бирә: *«Үзегезгә, хәл вә дәрәҗәгә туры килмәгән киемнәрне, хәтта кодрәтегез җитсә дә, кимәгез, бөек гаиләләр вә байлар гадәтенчә киенергә көчәнмәгез вә кызыкмагыз!»*

Бу фикерләр инде татар җәмгыятендә шул чорда мода мәсьәләсе көчәюгә ишарәли. Кыз балаларга атап язылган нәсыйхәтләр китабы Оренбургта 1903 елда басылып чыга, ә ир-ат балаларга нәсыйхәтләр җыентыгы 1908 елда Казанда дөнья күрә. 1903 елгы китабында ук Ризаэддин Фәхреддин «мода» аңлатмасын куллана һәм бер-ике кәлимә сүз яза: *«...халык сөйли дип мода сөйләмәгез, модага әсир булмагыз, һәркем тарафыннан хуш күрелгән, ясалма булмаган киемнәрне киеп, моданы үзегезгә әсир итегез!»*

«Мода сөйләмәгез, мода ишетмәгез!»

Биш елдан соң, 1908 елда чыккан хезмәтендә Ризаэддин Фәхреддин «мода» аңлатмасына күбрәк урын бирә. Ул моданы хупламый һәм аңа катгый рәвештә каршы икәнен күрсәтә. *«Мода сөйләмәгез, мода ишетмәгез, мода белән гамәл кылмагыз, мода белән белеш булмагыз! Мода исерткеч вә яки отыш уенының бер төре булыр, аңа дучар булган кеше, үзе һәлак булмый торып, аннан аерыла алмас»,* – дип яза галим бу күренеш турында. Бу чорда инде, чынлап та, мода белән мавыгучылар күбәя. Мәсәлән, кешенең әйберенә карап, аның никадәр алдынгы карашлы, кадимчеләр рәтендә түгел икәнен белгәннәр. Беренче урыс инкыйлабы елларында яшьләр арасында таралган кием-салымнар аша аларның социалис-

тик карашлымы, түгелме икәнен дә аңлап булган. Шуңа күрә ир-атлар арасында үзенең тышкы кыяфәтенә, имиджга нык игътибар иткәннәре күбәя. Ризаэддин Фәхреддиннең модага каршы фикерләрен шул үзгәрешләр белән аңлатып була.

Галим үзе һәм гаиләсе ничек киенгән?

Аның шәхси тормышын алсак, монда да заман һәм моданың йогынтысын аз булса да күрәбез. Галим үзе һәм аның гаиләсе ничек киенеп йөргән? Җәдитчелек һәм модернизация үзгәрешләре аларның кыяфәтенә йогынты ясаганмы-юкмы? Бу сорауларга җавапны Р.Фәхреддин гаиләсенең фотоларыннан эзләп табарга була. Гомумән, фоторәсемнәргә галим уңай караштa торган, бу хәрам, дип, каршылык белдермәгән һәм, мөмкинлек булганда, гаиләсе белән фотолар алдырырга тырышкан. Ризаэддин Фәхреддиннең иң беренче фоторәсеме 1891 елгы, Уфага казый булып килгәч төшкән. Әлеге фотосурәттә аңа 32 яшь, ул озын казаки, балаклары төшерелгән чалбар һәм башына төрек фәсен кигән. Балаклы чалбар һәм башына фәс киеп төшүе Ризаэддин Фәхреддиннең замана модасыннан, ул чорда бигрәк тә популяр булган госманлы мәдәниятеннән хәбәрдар булуын күрсәтә.

1897 елны гаиләсе белән төшкән фотода Риза казыйның кыяфәтендә артык үзгәрешләр юк: шул ук төрек фәсе һәм озын казаки, балаклары төшерелгән чалбар. Ир балалары да шул рәвештә киенгән, әмма аларның башларында татар кәләпүшләре. Барысының да киемнәре күбесенчә карарак төсләрдә. Нурҗамал абыстайда кадимичә кыяфәт: иркен тегелгән күлмәк, шул төскә якын камзул һәм зур калфагы яулык астыннан бик үк күренми, күлмәге итәксез. Гомумән, Фәхреддин рафикәсенең кыяфәте бик тыйнак булса да, зиннәтле алкалар һәм муенсалар белән абыстай зәвыклырак күренергә тырышкан, ахрысы.

1902 елда гаиләсе белән шулай ук Уфада төшкән фоторәсемдә Риза казыйның тышкы кыяфәте бераз үзгәргән. Төрек фәсе урынына – кәләпүш, иске кара казаки урынына яңачарак тегелгән, бераз кыскартылган һәм ачыграк төстәге казаки кигән. Балаларының киемнәре иске рәвештә, ә менә Нурҗамал абыстай күлмәгенең итәгендә бизәкләр күренә, калфагы бераз зурая төшкән һәм зиннәтле бизәнгечләр дә кимегән. Күкрәгендә бер генә затлы брошь сыман нәрсә бар.

Ризаэддин Фәхреддин 1898 елда чыккан «Тәрбияле хатын: нәсыйхәтләр» китабында зур чулпы тагуны яисә «муенга көмеш яки алтын тәңкәләр асу»ны хупламавын аңлата. *«Боларны асып йөрүдән, банкка салып, аз булса да процентны алып тору файдалы булыр»,* – дип яза ул һәм бу җөмләдә без аның риба мәсьәләсенә булган карашы да уңай булганын күрәбез.

1905 елда Уфада гаиләсе белән төшкән фоторәсүрәттә Риза казыйның кыяфәтендә артык үзгәрешләр юк, ә менә Нурҗамал абыстай бөтенләй башкача киенгән. Аның күлмәге дә бер төстәге тукымадан түгел, ә чуар материалдан, бик купшы иттереп тектерелгән бала итәкле камзолы да бик зәвыклы, ә башында исә кечкенә калфак, яулыксыз, чәчләре җыелган, толымнары күренми. 1897 һәм 1902 нче еллардагы фоторәсемнәрдән аермалы буларак, Нурҗамал абыстайның артык зиннәтле муенсасы да, алкалары да юк. Балалар әүвәлге рәвештә киенгәннәр: озынрак казаки һәм кәләпүшләр, кызлары Зәйнәп тә матур калфактан һәм чуар тукымадан тегелгән күлмәктән.

1912 елда Оренбургта торган чорында Ризаэддин Фәхреддин биш мәртәбә фотога төшә. Гаиләсе белән төшкән фотосурәттә инде җиде ел эчендә балаларның үскәне, тормышның шактый үзгәргәне сизелә. Мәсәлән, Риза хәзрәт шулай ук

кара кәләпүштән һәм казакидан, әмма өс киеме бераз кыскара төшкән. Нурҗамал абыстай әлеге фотода шулай ук калфаклы, әмма башында инде яулыгы да бар. Итәкле күлмәге ачык төстә, камзолсыз. Укучы балаларның өсбашларында – мәктәп формалары, училище мундирлары; гимназистка Зәйнәп мәктәп күлмәгеннән һәм кара алъяпкычлы, калфаксыз. Иң олы уллары «аляфранка» стилендәге костюмда: галстуклы, жилеткалы, костюмының якасы кайтарылып тора. Кече кызы Әсма да шәһәрчә күлмәктән, ак якалы, калфаксыз. Гаиләдә иң кечкенә малай гына әүвәлгечә, шәкертләрчә казаки һәм кәләпүш кигән.



Ризаэддин Фәхреддин. 1912 ел

Шунысы кызык: шул ук 1912 елда Ризаэддин Фәхреддин тагын дүрт фоторәсем – үзенең портретларын ясатып алдыра. Аларның дүртесе дүрт төрле кыяфәттә. Икесе дин әһелләренә якын: берсендә ул чалма ураган һәм чапан кигән, икенчесендә шулай ук ак чалма, әмма кайтарма якалы чикмән киеп төшкән. Бу кием мөфти янында эшләгән казыйлар киеменә якынрак. Тагын ике фотода ул дөньяви рәвештә төшкән: үзе гел киеп йөргән кара кәләпүштән һәм казакидан. Бер фотода ул шул кыяфәттә язу-сызу белән булышып утырган кебек, ягъни «Шура» журналының редакторы образын гәүдәләндерә. Икенче фотосурәттә Риза хәзрәт шулай ук язу-сызу өстәле янында утыра, шул ук декорациядә. Шуңа күрә бу ике фоторәсемнең бер үк вакытта төшерелгәнлеге күренеп тора. Әмма әлеге фотода ул каракүл бүректән һәм бик озын фасонлы казакидан. Бәлки, беренче фото – «Шура» журналы редакторының гадәти рәвешен, ә икенчесе бәйрәмчәрәк кыяфәтен чагылдыргандыр.

Бу фотосурәтләрне күзаллау Ризаэддин Фәхреддиннең киемгә мөнәсәбәте рациональ булуын, аның мода һәм кием алыштыру белән мавыкмавын күрсәтә. Ул гомер буе диярлек кара кәләпүш һәм мәдрәсә заманыннан күнеккән казаки фасонындагы кием киеп йөри, шәһәр модасы дип, «аля-франка» костюмнар барламый. Яшь чагында гына аның бераз госманлыларча фәс киеп йөргәне була.

Ыштанмы, чалбармы? Чалбар кию хәраммы?

1915 елда «Шура» журналының өч санында Ризаэддин Фәхреддиннең «Киемнәр хакында» дигән бик күләмле мәкаләсе басылып чыга. Мәгърифәтченең әлеге хезмәтендә аның шушы чордагы татар киеменең үзгәрешләренә кагылган

Ризаэддин Фәхреддин гаиләсе белән. 1912 ел

«Элекке вакытларда Бохарадан кайтучыларның башларында – чалма вә өсләрендә чапан буладыр иде, сезнең өстегездә бәрхет якалы чикмән вә башыгызда каракүл бүрек күреп гаҗәпләндем».

бик кызыклы фикерләре тупланган. Моннан тыш, галим бу үзгәрешләрнең шаһиты буларак, утыз-утыз биш ел дәвамында татар модасының үсешенә күзәтү ясый алган. XIX гасыр уртасындагы *(«Мәрҗани заманында»)* үзгәрешләр белән чагыштырганда, үз чорындагы үзгәрешләр тизрәк булды дигән фикергә килә ул.

Мәдрәсәдә укыган вакытын искә төшереп, Ризаэддин Фәхреддин ул елларда чалбар турында низаг зур булуын язып үтә. Әгәр башта ыштанмы, чалбармы дип баш ватсалар, соңрак чалбарның балакларын читек өстеннән салындырып йөрүгә күчәләр. Бер төркем чалбар киюне һаман хәрам дип санаса, икенче төркем чалбарны читек вә оек кунычы эченә кертеп кигәндә генә зарар юк дип санаган. *«Заманына күрә егет санала торган бер хәзрәт бергә укыган дустыбыз булган углына: «Үзеңә чалбар тектереп җибәрәм, ләкин балакларын җибәреп киярга ризалыгым юк!» – дип хат язган иде»,* – дип хәтердә яңарта ул заманны, ягъни 1870-1880 нче елларны Р.Фәхреддин.

Риза хәзрәтнең үзенең әлеге чордагы фотоларын искә төшерсәк, 1890 елда ул фотога чалбар балакларын тышка чыгарып киеп төшкән, ягъни заманына күрә алдынгы карашлы булган. Әмма башка төрле яңа мода йогынтыларына ул әле үзе дә каршылык күрсәткән. Мәсәлән, авыл шәкертләре Уфага имтихан бирергә барып кайткач, аңа шәһәр казыйларының «урысча» киенеп йөрүләрен кайтып сөйләгәннәр. «Урысча» киенү дигәннәре – башларындагы каракүл бүрек, өсләрендәге бәрхет якасы кайтарыла торган чикмән, аякта – үкчәле итек. Ризаэддин Фәхреддин үзе дә тимер юлда бер шәкертне шул кыяфәттә очратып, аны бераз шелтәләп ала: *«Элекке вакытларда Бохарадан кайтучыларның башларында – чалма вә өсләрендә чапан буладыр иде, сезнең өстегездә бәрхет якалы чикмән вә башыгызда каракүл бүрек күреп гаҗәпләндем».* Бу гади генә шәкерт булмый,

ә Мәккәдән уку бетереп кайтып баручы. 1880 нче еллар хакында Ризаэддин Фәхреддин: *«Ул вакытта шәкертләр, меллалар үзләре тупый яки камчат вә кама, кондыздан (...) бүрек кияләр иде»,* – дип яза.

Шунысы кызык: Риза хәзрәтнең 1912 елдагы бер портретында без аны нәкъ шул кыска каракүл бүректән һәм кайтарма бәрхет якалы чикмәннән күрәбез. Заманалар үзгәрә, ә шәһәр модасы тора-бара халык арасында ныграк тарала башлый. Ризаэддин Фәхреддиннең Уфада казый булып эшләве, шәһәр татарлары белән якын аралаша башлавы һәм, гомумән, яңа җирдә төрле катламнан булган мөселман халкын күзәтүе кадими карашларын үзгәртүенә дә зур йогынты ясаган. Мәсәлән, мөфтияткә, ягъни Оренбург Мөселман диния нәзарәтенә шәһәр модасына ияргән кешеләр дә эшкә йөргән. Шулар арасында фуражкалы һәм «аля-франка» костюмлысы яшь казыйны бигрәк тә шаккатырган. Әмма күз бу хәлгә дә ияләшкән. *«Мәккә вә Мәдинәдә укып та фуражка вә цилиндр киеп йөрүчеләр күбәйгәннән соң, бу эшкә күз уранды, чит-ят күрелми башлады»,* – дип яза Ризаэддин Фәхреддин 1915 елда.

«Урысча» киенү хәләлме? «Мөселманча кием булырга мөмкин дә түгел!»

Татар модасының тарихына кагылып, ул Уфа шәһәре буенча да кызыклы күзәтүләрен китерә. Кыска кием кию, ягъни кыска казакилар, аның уенча, Уфада 1904 нче елларда тарала башлый. *«Мин үзем кыска киемнәрне иң элек шул елда мөселман магазиннарында хезмәт итүче приказчикларда күрдем,* – дип искә ала Ризаэддин Фәхреддин. – *Тубыктан йөри торган казакилар бу көн ни дәрәҗәдә көлкеле булсалар, шул вакытта кыска казакилар да шул дәрәҗәдә көлке иде. Халыклар боларны күргәндә тыела алмый көләләр, койрыкларын кисеп җибәргән кигәвеннәргә охшаталар иде».* Әмма Ризаэддин казый үзе исә, озын казакилар көлкеле күренә хәзер, дип язса да, фотоларда искечә озынрак казакилар киеп төшүне кирәк дип санаган.

Шулай да «урысча» киенүне ул хәрам дип язмаган. Ә күп мөселман халкының шәһәр киеменә күчүен ул модага һәм «үзләреннән өстен булган урысларга» иярү белән генә түгел, ә башка сәбәпләрдән дә күргән. Мәсәлән, Ризаэддин Фәхреддин фикеренчә, күп мөселман сәүдәгәрләре «әманәткә аз игътибар» итәләр – *«кыйммәтле әйберләрне бозалар», «кискән нәрсәләрне артканын үзләренә алып калалар», «кадерле нәрсәләрне аннан-моннан тегәләр».* Галим аларны алдашуда һәм *«пөхтә мөгамәлә кылмау»*да гаепли. Моннан тыш, кибетләрнең үзендә тегүчеләр булмавын, аяк киемнәрендә номерлар юклыгын да әйтеп китә ул. *«Шушы эшләр халыкларның иске милли киемнәреннән бизүләренә вә башкаларның киемнәрен ихтыяр кылуларына сәбәп булды»,* – дип яза Р.Фәхреддин.

Бу күләмле мәкаләне йомгаклап, галим «мөселман киеме» һәм «мөселманча кием» юк дигән нәтиҗә ясый. Себердә торучы мөселманнар һәм Гарәбстандагы мөселманнар бертөрле кием киеп йөри алмыйлар дип саный ул: *«Утыз градус салкын белән утыз градус кайнарда мәгыйшәт итүче ике кеше өчен бер форма ярамавы табигый».* Шуңа күрә дөньяда милли киемнәр булса да, дини кием юк дип яза һәм: *«Мөселманча кием исемендә бер кием булмады вә булырга мөмкин дә түгел»,* – дигән нәтиҗәгә килә.

Шулай итеп, Ризаэддин Фәхреддиннең татар киеменә, модасына карашлары әле дә актуальлеген югалтмаган, бу фикерләр бүген дә заманча яңгырый. ■

Безнең мирас №12 декабрь 2021

Нагайбәк туганайлар, сез кайдан?

Фоат Закиров*

Нагайбәк чибәрләре

Нагайбәкләр язмышы бик гыйбрәтле һәм бер үк вакытта күп халыкларга үрнәк булырлык! Барлык язмыш сынауларын узып, асылларын гына түгел, телләрен һәм борынгы гореф-гадәтләрен саклап калган халык буларак зур хөрмәткә ия алар. Нагайбәкләр тарихы рус хөкүмәтенең көнчыгыш чикләрен киңәйтү, башкорт, казакъ, калмык халыкларын буйсындыру тарихы белән турыдан-туры бәйле.

***Фоат Дәүли улы Закиров** – галим-агроном, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты. Галим – үсемлекләр физиологиясе, агулы үсемлекләр турында китаплар, туган авылы Кәче тарихы һәм шәхесләренә багышланган мәкаләләр авторы. Арча районындагы Кәче авылында яши, бакчачылык һәм төбәк тарихын өйрәнү белән шөгыльләнә.

Нагайбәкләр Арчаданмы?

Бактың исә, нагайбәкләрнең килеп чыгышы буенча эзләнүләр инде күптән башланып, шактый бәхәсләр тудырган һәм алар бүгенгә хәтле хәл ителмәгән икән. Бер төркем галимнәр нагайбәкләрне арча татарлары дисә, башкалары, нугай татарлары, башкортлар яки татар белән калмык каны кушылудан килеп чыккан халык, ди. Әйдәгез, күп галимнәр тарафыннан дөреслеккә якын дип саналган беренче фикергә тукталыйк.

Иң әүвәл әлеге халык «новокрещеные татары», «татары-казаки», «крещеные магометаны» буларак танылган. Бәләбәй өязендә Нагайбәк ныгытмасы төзелгәч кенә, анда хезмәт итәргә китерелгән казак катлавына караган татарлар халык телендә нагайбәкләр дип атала башлый.

В.Н.Витевский 1877 елда нагайбәкләрнең Казан яулап алынгач чукынган арча татарлары, башлыча арча морзалары токымыннан булырга тиешлеген ассызыклый.

Оренбург казак атаманнарыннан булган Ф.М.Стариков 1884 елда үзенең «Откуда взялись уральские казаки?» исемле китабында нагайбәкләрнең, чукындырылып, Бәләбәй һәм Минзәлә өязләренә күчерелгән арча татарлары икәнлеген яза: *«Нагайбаки — крещеные татары, выходцы из Арска. После крещения они переселились в Башкирию из Казанской губернии. В Башкирии они населяли Билибейский и Мензелинский уезды»*.

Профессор Н.Ф.Катанов та нагайбәкләрнең ата-бабалары арча татарлары булуын ассызыклый. Аның фикеренчә, бу татарлар Казан ханлыгы рус дәүләте составына кергәч тә көчләп чукындырылганнар һәм Агыйдел белән Ык буйларына күчерелгәннәр.

Е.А.Бектеева нагайбәкләрнең күбесе татар, ә төгәлрәк әйткәндә, нугай морзалары гореф-гадәтләренә тугры халык, дип, ул аларның нәсел шәҗәрәләрен саклау-ларын ассызыклый.

Тарихчы Д.М.Исхаков һәм И.Р.Атнагуловлар да нагайбәкләр тамырының Казан ханлыгы заманында яшәгән арча җайдакларына тоташу фикерендә торалар.

Ә иң мөһиме – нагайбәкләр үзләрен Явыз Иван тарафыннан чукындырылган һәм араларында морзалары да булган арча татарлары токымыннан, дип саный.

Күпсанлы морзалар кайдан килгән?

Бу сорауга җавап бирү өчен, бераз тарихи чигенеш ясыйк. Чиләбе өлкәсендәге Нагайбәк районының төбәкне өйрәнү музее директоры А.М.Маментьев фикере буенча, 1533 елда Нугай Урдасы морзасы Йосыф би 12 яшьлек кызы Сөембикәне Казан ханы Җангалигә кияүгә бирә. Риваятьләрнең берсендә Сөембикәне ерак юлда кораллы 600 гаскәри егет – морза балалары озата килүе һәм аларның соңыннан Арча кирмәне янында яшәп калулары, Казан алынгач чукындырылулары бәян ителә.

П.И.Рычков нагайбәкләрнең кайчандыр мәҗүсилек дине тарафдарлары булуын да ассызыклый: *«Что нагайбаки были крещеными «из магометан», отметил существование у них еще двух компонентов крещеных «идолопоклонников»*.

В.Н.Витевский да нагайбәкләрдә мәҗүсилек диненнән калган «яңгыр боткасы»нда корбан чалу йоласы саклануы турында яза. Биредә шуны ассызыклап үтәргә кирәк: яңгыр теләп корбан чалу хәзерге көндә Татарстанда бары тик

ике генә авылда – Арча районындагы Кәче һәм Балык Бистәсендәге Балыклы Чүкәйдә генә башкарыла. Ә бит Балыклы авылы нагайбәкләр тарихында еш искә алына! «Чүкәй» кушаматлы нәсел Кәчедә дә бар. Ә кушаматның тарихы Балыклы Чүкәй авылына турыдан-туры бәйле.

Нагайбәкләр тарихының билгесез чоры

Оренбург казак гаскәрләре старшинасы Ф.М.Стариков һәм рус тарихчысы В.Н.Витевский фикеренчә, нагайбәкләрнең, чукындырылып, Бәләбәй һәм Минзәлә өязләренә күчерелгән Арча төбәге татарлары икәнлеге билгеле булса да, аларның кайсы авыллардан килгәнлеге һәм туган ватаннарыннан кайчан күчерелүләре сер булып кала.

Арча районының Кәче авылы тарихында да шул заманнарга караган ике табышмак бар. Казан алынгач, Арчаның үзендә һәм аның тирәсендәге күп кенә татар авыллары урынында яндырылган нигезләр генә кала. Кәче иле дә бу афәттән читтә калмый. Чыннан да шул вакыттан башлап 1678 елгы халык саны алуга кадәр Кәче тарих сәхифәсеннән югалып тора. 1552-1678 нче еллар арасында Арчага терәлеп торган Кәче иле җирләре һәм анда яшәүче халык белән ни булган? Тагын бер табышмак: тирә-яктагы авыллар чукындырылганда яки аларның нигезенә руслар килеп төпләнгәндә Кәче нигә чукындырылмый һәм аның җирләре рус крестьяннарына бирелми? Минем уемча, бу ике сорауга бер җавап булырга тиеш һәм аны нагайбәкләр тарихыннан эзләргә кирәк!

Казан-Арча тарафлары яулап алынганнан соң, рус хөкүмәте яңа җирләр белән тиз арада идарә итә алмый. Шул вакытларда күп авыллар юкка чыга, халык төрле якка тарала. Кәченең тарих сәхнәсеннән юкка чыгып торуы да әлеге чордагы вакыйгалар белән бәйле булырга мөмкин:

1. Халыкның массакүләм качуы. Казан яуланганнан соң, җәза отрядларыннан курыккан җирле халык туган җирләрен ташлап еракка – чытырманлы кара урманнарга, ә кыюлары исә Кама аръягына кача башлый. Шул вакытларда Кәче халкының да болгар җирләренә, ә бәлки, 1431 нче елларга кадәрге борынгы нигезләренә күченүе бик мөмкин. Чөнки Кәче халкының Кама аръягында, ә төгәлрәге, хәзерге Иске Чишмә авылы – элеккеге Яңа Чишмә ныгытмасы тирәләрендә печәнлек җирләре һәм балык тоту урыннары булуы билгеле. Ул җирләр Манашев биләмәләре булса кирәк. Чыннан да, ДНК анализы буенча, Кәчедәге Хәйруллин Шакир һәм Хөснетдинов Сәлахларның Манашев нәселенә тоташуы ачыкланды.

2. Морзаларны буйсындыру. Казан алынганчы ук чукынып урыс патшасына хезмәткә күчкән йомышлы татарлар катламы Казанны алуда һәм чик буйларын саклауда катнаша. Ә Казан ханлыгы яулангач, морзаларны ни көтә? Фершампенуаз поселогы атаманы С.И.Никитинның В.Н.Витевскийга биргән документында нагайбәкләр арасында Казан алынгач үзләре теләп чукынган татар морзаларының да булуы турында әйтелә: *«В числе коих татарские мурзы, крестившиеся сразу же по взятии Казани Иваном Грозным».* Әйе, аерым морзаларның, гомерләрен, дәрәҗәләрен, байлыкларын саклап калу бәрабәренә, үзләре теләп чукынулары билгеле. Ләкин патшаның ышанычын аклар өчен «теләп чукыну» гына җитми. Йомышлы татарлар рус дәүләтенең эчке өлкәләренә – Сүр (Сура), Үкә (Ока) елгалары аръягына, аның түбәнге агымына һәм Иделнең өске ягына куылалар. Баш күтәрүгә әвәс татарлар, «бераз кулга ияләнгәч» кенә, 1556-1559 нчы елларда барган Рус-

Нагайбәк балалары

фин сугышына (Лифляндия сугышына) һәм 1558-1582 нче еллардагы Рус-Ливон сугышына җибәреләләр. Мәсәлән, Ливон сугышында катнашкан 31 мең кешенең 6 меңнән артыгы йомышлы татар була.

1561 нче еллардан башлап патша хөкүмәте аерым йомышлы татарларга тугры хезмәтләре өчен рус дәүләтенә үз теләкләре белән кушылган башкортларның җирләрен бүләк итә башлый. Мәсәлән, 1561 елда Мораса елгасы буеннан Ситдыйков (Сюндюков) исемле татар беренчеләрдән булып җир биләмәсе ала. Шулай ук Алатар өязеннән кенәз Мостафин, соңрак башка кенәзләр, мәсәлән, Яушевлар, Еникеевләр, Урманчеевлар да башкорт җирләренең чын хуҗаларына әйләнәләр.

3. Халыкны ныгытмалар төзелешенә куу. Җирле халыкны буйсындырып тору өчен, элекке татар шәһәрләре урынына Арча (1555), Лаеш (1557), Тәтеш (1571), Уфа (1574) крепость-калалары, 1584 елда Царевококшайск (хәзерге Йошкар-Ола), Уржум, Малмыж остроглары төзелә. Әлбәттә, гомер-гомергә колыкка төшкән халык, арзанлы эш көче буларак, авыр төзелешләргә куылган. Арча янындагы Бирәзә, Божа, Кәче, Чүриле, Кишмәт һәм Абҗабар авыллары халыкларының да төзелешләргә җибәрелүләре бик мөмкин.

Кама аръягы җирләрен үзләштерү

1552 елда Казан ханлыгын яулап алганнан соң, Россия дәүләте Каманың уң ягында гына хакимлек итә. Кама аръягындагы җирләр озак вакытлар үзләштерелми. Шул ук вакытта әлеге җирләр Нугай Урдасы карамагында була. Халык Кама аръягына аяк басарга куркып яши, печән әзерләргә дә «нугайлар килмәгән елны» гына чыгалар. Биредә җирле халык бик аз була. *«Западное Закамье до сооружения засечной черты представляло собой пустующую территорию, где кочевали степные народы»*, – дип яза рус тарихчысы Г.И.Перетяткович.

Шул заманнарда Кама аръягын беренчеләрдән булып Мәскәү яуларыннан качарга мәҗбүр булган Казан ягы халкы үзләштерә башлый. Кагыйдә буларак, алар яшәү өчен элегрәк юкка чыккан авыл урыннарын, бәлки, ата-бабалары туган җирләрне сайлыйлар...

Нагайбәк хатыны

1557 елда башкорт җирләре дә Россиягә күчкәч, 1561 нче еллардан башлап аерым йомышлы татарлар хуҗасыз яткан җирләрне үзләштерүгә беренче адым ясый. Шул ук елларда бирегә чиркәү-монастырь җирбиләүчеләре һәм качкын рус крестьяннары килеп урнаша башлый. 1602-1603 нче еллардагы «Писцовая книга И.Болтина»га карасак, бу елларда Кама аръягында авыллар түгел, ә бәлки, печән әзерләү, умартачылык һәм җәнлек аулау биләмәләре турында гына сүз барганын күрәбез. Әлеге җирләрдә Кәче халкының көтүлек, печәнлек һәм балык тоту биләмәләре булганлыгы алда искә алынды.

1598-1613 нче еллар – рус хөкүмәте өчен кара көннәр, Болгавыр чор. Мәскәү тарафында изелгән, кимсетелгән-хурланган халык Идел буендагы Нижегородск-Казан төбәгенә күпләп агыла. XVII гасырның 40 нчы елларында рус алпавытлары да Кама аръягына килә башлыйлар. Әмма башбирмәс, хөрриятккә күнеккән дала халкына бу баскынчылык ошамый. Каракалпак, калмык, нугай, татар һәм башкорт чапкыннары яңа килгәннәрне гел борчып тора. Шуңа да карамастан, Кама аръягын үзләштерү дәвам итә. Тик булган хәрби ныгытмалар халыкның куркынычсызлыгын тәэмин итә алмыйлар.

1650-1658 нче елларда Кама аръягы ныгытмалары төзелү

Әлеге ныгытма, чик буйларын саклау һәм халыкның Себер якларына качуын туктату белән бергә, Россиянең көнчыгыш киңлекләрен яулау сәясәтен дә гамәлгә ашыруда беренче адым булып тора. Заманына күрә иксез-чиксез озынлыкта – 300 чакрымга сузылган чик сызыгы булдырыла: Иделнең сул ягындагы Акъяр ныгытмасыннан (Чирмешән елгасының уң яры буйлап) Ык елгасына кадәр арада Акъяр, Ерыклы, Тиинск, Биләр, Яңа Чишмә, Кичуй, Зәй ныгытмалары төзелә. Зәй ныгытмасы Минзәлә острогы белән тоташтырыла.

Корылмалар кору эше 1652 елның җәендә башлана. Төзелештә Казан өязендәге һәр алты йорттан берәр кеше катнаша. Шул ук вакытта Арча һәм Балтач якларын-

нан да төзүче татарларның күпләп китерелүе хакында әйтелә. Ныгытма чагыштырмача тиз арада – биш ел эчендә корылып бетә. Баштарак бирегә хезмәткә казаклар һәм Смоленск поляклары китерелә. Шул вакытта Арча ныгытмасыннан да гаскәриләрнең бер өлеше күчерелүе билгеле. 1653 елның сентябрендә Лаеш ныгытмасыннан 100 казак (сословие!) татары гаиләсе белән китерелә.

1690 нчы елларда чик сызыгының эчке ягында буш яткан җирләр калмый диярлек. Шуннан соң, 1690-1718 нче елларда, халыкны чик сызыгының тышкы ягына – Кама аръягының көньяк-көнчыгышына күчерү этабы башлана. Казан тирәсе халкы да, чукындырудан качып, шундагы буш яткан уңдырышлы туфраклы җирләргә авыллары белән күченә. Мәсәлән, 1721 елда гына да Арча даругасыннан 13 210 кеше шул якларга юл тота, ә Кәче авылыннан 31 гаилә күченә.

1734-1736 нчы елларда Кама аръягында яңа ныгытма төзелү

Рус хөкүмәте «шыпырт кына яулап алу» сәясәтенең икенче зур этабына керешә, Кама аръягы чикләрен тагын да киңәйтү планнары тормышка ашырыла башлый. Шул вакыттан башлап беренче төзелгән Кама аръягы чик сызыгы «Иске чик сызыгы» буларак атала. Андагы бушап калган авылларга олы яшьтәге солдатлар гаилә белән күчерелә.

Яңа чик сызыгы төзүнең беренче этабында 3 мең тирәсе эшче катнаша. Татарлар да яңа төзелешләргә куыла: Көнчыгыш Кама аръягындагы Бәләбәй һәм Минзәлә тирәләренә күп авыллар күчерелә. Шулай итеп, Бакалы һәм Нагайбәк ныгытмалары тирәсендә хәзерге Мамадыш районындагы Ахманово һәм Ямашево; Кукмара һәм шулай ук Лаеш районындагы Балыклы; Балтач районындагы Кили (Килиево), Яваш (Дияшево), Яңавыл (Янаул) кешеләре килеп, яңа торак пунктларны еракта калган авыллары исемнәре белән атый башлыйлар. Күчеп килүчеләр, ясаклы халык буларак – патшага, ә җирләреннән файдаланган өчен башкортларга салым түләп яши. Соңрак аларның күбесе, салымнардан котылу өчен, башкорт сословиесенә языла. Ф.М.Стариков язуынча, Бакалыда, Нагайбәктә һәм алда искә алынган авылларда яшәүчеләрнең күбесе 1762-1795 нче елларда нагайбәкләр дип йөртелә.

1736 елдан, патшабикә Анна Иоанновна указы буенча, Нагайбәк казак гаскәрләре булдырыла. Указ нигезендә, шул ук елны Бәләбәйдән ерак булмаган Ык елгасының уң ягында Нагайбәк авылы ныгытма буларак игълан ителә һәм үзгәртеп төзелә. Төзелешкә җибәрелгән ирләр казак хезмәтенә алына.

Бер үк вакытта Татарстанның көнчыгышында яшәүче икенче чукындыру корбаннары – яңа керәшеннәр дә әлеге ныгытмаларга яки алар тирәсендәге авылларга, станицаларга күчерелә. Яңа чик сызыгы төзелеше 1736 елда тәмамлана. Ныгытмалар тирәсендә барлыгы 14 яңа авыл пәйда була.

1748 елда Оренбург казак гаскәрләре оештырыла. Анда нагайбәкләр аерым полк буларак керәләр.

1837 елда Орск һәм Троицк ныгытмалары арасында яңа чик сызыгы

Әлеге ныгытмаларны саклау өчен, беренчеләрдән булып, Оренбург казак гаскәрләре һәм гаскәр составына кергән Нагайбәк полкы да күчерелә. Күченү

1842 елның 23 февралендә башлана. Бакалы һәм Нагайбәк станицаларында яшәүче нагайбәк, калмык һәм урыс казаклары, гаиләләре белән атларга төялеп, булдыра алганча йорт кирәк-яракларын алып, озын юлга кузгала – Урал тауларын аркылы кичеп, хәзерге Чиләбе өлкәсенең көньягына килеп чыга. Алар өч төркемгә бүленә.

Төньяк төркем. Оренбург губернасының Троицк өязендәге Верхнеувельская (Варламово), Ключевский (Лягушино), Попово, Болотово һәм Краснокаменка авыллары. Бирегә Бакалы станицасында яшәгән 500 нагайбәк күчерелә. Алар үзләрен «бакалылар» дип саный.

Үзәк төркем. Оренбург губернасының Верхнеуральск өязендәге Кассель, Фершампенуаз, Париж, Требия, Остроленский, Астафьевский авылларының халкы, нигездә, Нагайбәк ныгытмасыннан килеп төпләнә. 1882-1893 нче елларда Остроленский, Фершампенуаз, Париж һәм Требия станицаларында чиркәүләр төзелә. Чиркәү эшләре татар телендә алып барыла. Нәтиҗәдә, нагайбәкләр чиркәүгә теләп йөри башлыйлар. Требиядә ислам тәэсире көчле була, чөнки андагы алтын приискаларының хуҗалары – бертуган Шакир һәм Закир Рәмиевләр. Алар чукынган татарларны чиркәүгә йөртмәс өчен төрле хәйләләр куллана. Мәсәлән, эшчеләргә акчаны ял көне – чиркәүгә бара торган вакытта яки башка урыс бәйрәмнәре көннәрендә бирә. Шуның өстенә, чиркәү көннәрендә приискада базар оештыралар. Әлбәттә, бу очракта җирле халык чиркәүгә баруны түгел, ә базарны сайлап, үзенә кирәк-яракны юнәтә.

Көньяк төркем. Орски өязендәге Нежинка, Гирьял, Алабайтал, Подгорный һәм Ильинская авыллары. Бирэдә нагайбәкләр җирле татар казаклары белән бергә урнаштырыла. Нәтиҗәдә, монда яшәүче бер төркем нагайбәкләр исламга кайталар.

***

Арча ягы тарафыннан кузгалып, гасырлар дәвамында менә шундый озын-озак күченү юлы уза нагайбәк халкы. 1812 елда алар Оренбург казак гаскәрләре составында Наполеонга каршы сугышта Парижга кадәр барып җитәләр һәм анда җиңүчеләр хөрмәтенә уздырылган парадны ачучы полк буларак катнашалар. Шул хөрмәткә алар яшәгән авыллар Фершампенуаз, Париж дип атала башлый.

19 нчы йөз ахры-20 нче йөз башында нагайбәкләр Япон һәм Беренче бөтендөня сугышларында кан коя. Репрессия елларында гасырлар буена сакланып килгән нәсел язмалары, шәҗәрәләре, саклык йөзеннән, юкка чыгарыла. Казак сословиесе бетерелгәч, 1920 нче елларда нагайбәкләр яңадан гади крестьянга әйләнә. Җан исәбе вакытында алар гел татар булып кына язылып киләләр, бары тик 2002 елгы сан алуда гына аерым этнос буларак теркәләләр.

Нагайбәкләр хәзерге көндә Чиләбе өлкәсенең Нагайбәк районындагы Кассель, Остроленский, Париж, Фершампенуаз, Астафьевский, Требия авылларында һәм Чибәркүл районындагы Варлам, Попово, Болотово, Краснокаменка һәм Ключевский авылларында яши. Алар Татарстанда яшәүче керәшеннәр белән аралашып торалар. Нагайбәкләр Казан ягын «Иске ил» дип, ә андагы керәшеннәрне «Иске йорт туганайлары» дип атый.

Нагайбәкләр аерым халык, ягъни аерым этнос булып исәпләнсәләр дә, чынлыкта алар туган җирләреннән кубарылып китәргә мәҗбүр булган Казан арты, Арча ягы татарлары. Минем ике як халкының да ДНК анализларын чагыштырасым килә. Әлеге күләмле эш киләчәктә башкарылыр дип өметләнәм. ■

Татар эшкуарлары: авылдан шәһәргә таба[1]

Җәүдәт Миңнуллин

XIX гасырның беренче яртысы Россия империясендә феодаль җәмгыятьнең кризисы көчәю белән характерлана. Феодаль мөнәсәбәтләр җитештерүче көчләрнең үсеше, сәнәгатьнең алга китүе өчен тоткарлык булып әверелә. Империядә самодержавие һәм крепостнойлык тәртипләренә каршы революцион-демократик хәрәкәт барлыкка килә. Гомумроссия масштабындагы бу процесслардан татар халкы да читтә кала алмаган, әлбәттә.

Татарлар составына һиндлылар да кергән

Бу гасырда Россиядә татар исемен йөрткән берничә халык (этник берәмлек) яшәгән:

1. Урта Идел һәм Урал буе татарлары;
2. Себер татарлары;
3. Әстерхан татарлары;
4. Кырым татарлары;
5. Литва татарлары.

Килеп чыгышлары белән бер үк төрки тамырга барып тоташкан һәм бер диндә булган бу кардәш халыклар «татар» үзатамасын йөртсәләр дә, аларның

Күренекле татар байлары Акчуриннар һәм Шакуловлар яшәгән Зөябаш авылының күренеше. 2016 ел

[1] Мәкалә галимнең Казан университетында укыган лекцияләре нигезендә әзерләнде. – ***Ред.***

барысын да бер халык, бер этнос дип әйтеп булмый. Әйтик, кырым һәм литва татарларын мөстәкыйль этник берәмлек итеп карау дөресрәк булыр. Тарихи язмышлары, телләре һәм үзаңнары белән алар Урта Идел һәм Урал буе татарларыннан аерылып торалар.

Урта Идел һәм Урал буе татарлары бөтен татар халкының үзәген, аны берләштереп торучы көч ролен уйнаган. Татар халкының бу төркеме XVIII-XIX гасырларда төрле этник төркемнәрнең – казан һәм касыйм татарлары, мишәрләр консолидациясе нәтиҗәсендә формалаша. 18-19 нчы йөзнең уртасында Урта Идел һәм Урал буе татарларының 67-68 процентын – казан татарлары, ә 30-31 процентын мишәрләр тәшкил иткән. Касыйм татарлары бары тик 1-2 процент кына булган.

1795 елда Россиядә 617,3 мең татар исәпләнсә, 1857 елда аларның саны 1416,1 меңгә җитә. Шуларның 2 проценты шәһәрләрдә яшәгән. Урта Идел һәм Урал буе татарларының төп массасы Казан, Оренбург, Уфа, Пермь, Вятка, Түбән Новгород, Пенза, Рязань, Сембер, Самара, Саратов һәм Царицын губерналарында гомер иткән.

Себер татарларының халык булып формалашуы Себер ханлыгы дәверендә үк башланган. XVIII-XIX гасырларда Себер татарларын Россия татарларының локаль-территориаль төркеме дип карап була. 19 нчы йөз уртасында ук Себер татарлары Урта Идел буе татарлары белән тыгыз этник бәйләнешкә керәләр. Себер татарларының төп өлеше Тубыл һәм Томск губерналарында яшәгән. 1795 елда бу территориядә 35 меңләп себер татары гомер итсә, 1857 елда аларның саны 45,2 меңгә җиткән. Шулардан 1 мең кеше шәһәрләрдә – Томск, Төмән, Тара һәм Тубыл шәһәрләрендә яшәгән.

Әстерхан татары

Тубыл татарлары. 1874 ел

Әстерхан татарлары турында сөйләгәндә, беренче чиратта, Әстерхан ханлыгы заманыннан ук калган җирле төрки халыкны күздә тотарга кирәк. Аларны «карагач» (кундрау) һәм «йорт татарлары» дип атаганнар. Алар нугай этник бердәмлеге нигезендә формалашканнар. Әмма, галимнәр фикеренчә, әстерхан татарлары бердәм мөстәкыйль халык булып үсеп китә алмаган. Әстерхан татарлары составына XVIII гасырда ук шәһәрдә яшәгән бахара (бохарлы), фарсы һәм һиндлылар да кергән. Әлбәттә, алар бик күп булмаганнар. Карагачлар, шулай ук төрекмән һәм каракалпакларның кечкенә төркемнәре белән кушылганнар. Әстерхан якларына Урта Идел һәм Урал буе татарлары 18 нче йөз башларында ук барып чыкканнар. Петр Інең Фарсы походы вакытында гаскәрдәге шактый татар солдатлары биредә яшәп калган. 1795 елда Әстерхан татарлары арасында читтән килгән 2 меңгә якын татар булган. 1795 елда 13 мең әстерхан татары исәпләнсә, 1875 елда аларның саны 25,7 меңгә җиткән. Шуларның 5 меңе шәһәрләрдә яшәгән һәм XIX гасыр уртасында Әстерханда гомер иткән татарларның 58 процентын читтән килгән татарлар тәшкил иткән (Әстерханда XIX гасыр уртасында барысы 2,9 мең татар яшәгән). Әлбәттә, җирле татарлар белән килгән татарлар вакытлар үтү белән катнаш никахларга кергән. Шулай итеп, 19 нчы йөзнең беренче яртысында Әстерхан төбәгендә татар халкының төрле этник төркемнәре арасында үзара якынаю процессы дәвам иткән.

> «Җир участоклары даими рәвештә – 10-12 елга бер тапкыр хуҗалыклар арасында ирләр санына карап бүленгән. Хатын-кызларга имана җире бирелмәгән.

Татарларның 98 проценты авылда яшәгән

XIX гасырның беренче яртысы Россиядә феодализм строеның кризисы көчәю белән характерлана дидек. Менә шушы чорда татарларның икътисади хәлләре ни дәрәҗәдә булган? Алар нинди кәсеп белән тормыш алып барган? Бу өлкәдә нинди яңалыклар күзәтелә?

Татар халкының абсолют күпчелеге авыл җирендә яшәгәнлектән, төп шөгыле игенчелек һәм терлекчелек булган. Дәүләт[2] крестьяннары саналган татарлар җирдән община (җәмәгать) хокукында файдаланганнар. Шуңа күрә җир участоклары даими рәвештә – 10-12 елга бер тапкыр хуҗалыклар арасында ирләр санына карап бүленгән. Хатын-кызларга имана җире бирелмәгән.

Җир эшкәртүдә элеккедән килгән өч басулы система кулланылган. Игенчелек культураларыннан татарлар арыш, тары, борчак, борай, солы һәм карабодай иккән. Техник культуралардан бәрәңге, җитен һәм киндер үстерелгән. Терлекчелек, аучылык, балыкчылык, чолыкчылык һәм бакчачылык хуҗалыкта ярдәмче роль уйнаган. Табигый шартлар уңайлы булган кайбер төбәкләрдә, мәсәлән, Себердә һәм Әстерхан губернасында аучылык, балыкчылык һәм бакчачылык җирле татарлар хуҗалыгында төп урыннарның берсен алып торган. Кыр эшләре тәмамлангач, кыш көннәрендә авыл халкы тукучылык белән шөгыльләнгән, шул ук вакытта читкә китеп сезонлы эшкә яллану да елдан-ел арта барган.

---

[2] Бу чорда алпавытлар һәм крепостной крестьяннар саны чагыштыргысыз дәрәҗәдә аз булып, алар икътисади һәм иҗтимагый тормышта сизелерлек роль уйнамаганнар.

Чит илгә 15 миллион пот икмәк

19 нчы йөз башында капиталистик мөнәсәбәтләр акрынлап авыл хуҗалыгына да үтеп керә башлый. 1801 елгы закон буенча кеше яшәмәгән җир участокларын теләгән кешегә сатарга һәм сатып алырга рөхсәт ителә. XIX гасырның беренче чирегендә бер Казан губернасында гына да 18 мең 835 дисәтинә җир сатыла. Күп кенә татар сәүдәгәрләре һәм хәлле крестьяннар шактый зур җир, урман һәм болынлыклар сатып ала башлый. Димәк, татарлар арасында да җирнең буржуаз милеккә әверелү процессы башлана. Ә моңа кадәр җир белән сату итү бары тик дворяннарга гына рөхсәт ителгән, ягъни бу аларның привилегиясе була.

«Күп кенә татар сәүдәгәрләре һәм хәлле крестьяннар шактый зур җир, урман һәм болынлыклар сатып ала башлый. Димәк, татарлар арасында да җирнең буржуаз милеккә әверелү процессы башлана.

19 нчы йөзнең 30 нчы елларында Россиядә сәнәгать күтәрелеше башлана һәм бу авыл хуҗалыгына да тәэсир итмичә калмый. Крестьян хуҗалыкларында камилләштерелгән эш кораллары, машиналар кулланыла башлый. Чәчкеч, ургыч һәм молотилка барлыкка килә. Әмма татарларда әлеге процесс урысларга караганда акрынрак бара. Авыл хуҗалыгында борынгыдан килгән агач сука, сабан, агач тырма, урак һәм чабагач кебек эш кораллары кулланыла. Кайбер татар алпавытлары һәм хәлле крестьяннар җиргә ашлама кертә, техник культураларның мәйданын арттыра башлый, әмма мондый хуҗалыклар әле бик аз була.

«XIX гасырның 40-60 нчы елларында Казан губернасыннан Россиянең үзәк өлкәләренә һәм чит илләргә ел саен 15 миллион потка якын ашлык җибәрелә.

Авылга капиталистик мөнәсәбәтләрнең үтеп керүе ашлык сатуның артуына китерә. XIX гасырның 40-60 нчы елларында Казан губернасыннан Россиянең үзәк өлкәләренә һәм чит илләргә ел саен 15 миллион потка якын ашлык җибәрелә. Эре җир хуҗалары һәм бай крестьяннар авылда яллы хезмәтне тагын да күбрәк куллана башлыйлар, бигрәк тә җәйге кыр эшләре вакытында. Шулай итеп, авыл халкының төрле социаль катлауларга аерылу процессы тагын да көчәя, тизләнә.

Татар эшкуарлары үсештә

Җитештерү чараларын югалткан һөнәрчеләр һәм тәмам бөлгенлеккә төшкән крестьяннар, үзләрен һәм гаиләләрен туендыру өчен, завод-фабрика хуҗаларына ялланалар. 19 нчы йөзнең 50 нче елларында Казан төбәгендә ирекле хезмәт көчләре базарында татарларның саны 50 мең кешегә җитә.

XIX гасырның беренче чирегe татарларда капиталистик мануфактураның тагын да үсеше һәм шулай итеп кул хезмәтеннән машина хезмәтенә күчү өчен шарт-

лар туу белән характерлы. 18 нче йөздәге кебек үк, сәнәгатьнең комач җитештерү тармагы уңышлы рәвештә үсә бара. XIX гасырның беренче 15 елы эчендә комач мануфактураларының саны 25тән 42гә җитә. Шактый санда татар сәүдәгәре һәм эшкуарлары яшәгән Әстерхан комач җитештерү үзәкләренең берсенә әверелә. 1816 елда бу шәһәрдәге татарлар кулында елына 100 мең аршын төрле тукыма җитештерүче 27 комач һәм 2 ефәк мануфактурасы була. Шулай да Казан һәм Вятка губерналарындагы мануфактуралар белән чагыштырганда, Әстерхан мануфактуралары кечкенә, ваграк санала.

19 нчы йөзнең беренче чирегендә татарларда поташ сәнәгате дә зур тизлек белән үсә. 1817 елда татар эшкуарлары кулында барысы 40 поташ заводы исәпләнә. Поташ сәнәгатенең үзәге Оренбург губернасында була: биредә барлыгы 29 поташ заводы исәпләнә, 7 завод Вятка һәм 6 завод Казан губернасында урнаша.

Туып килүче татар буржуазиясе күн эшкәртү сәнәгатендә дә үз позицияләрен ныгыта бара. 1815 елда татар күн эшкәртү заводлары 111 меңнән артык тире чыгаралар, ә XVIII гасыр ахырында татарлар барысы 24-25 мең генә тире эшкәрткәннәр. Бу үсеш 4 мәртәбә артык дигән сүз.

Сабын кайнату сәнәгатендә дә үсеш күзәтелә. Сабын кайнату үзәге булган Казанда 1815 елда 50 мең потка якын сабын ясала, ә 18 нче йөз ахырында 2,5 тапкырга кимрәк җитештерелә.

XIX гасырның беренче чирегендә сәнәгатьтә яңа тармаклар да барлыкка килә. Бу чорда татарлар Казан һәм Вятка губерналарында кәгазь эшләү мануфактуралары ачып җибәрәләр. 1815 елда Казанда ике татар сәүдәгәре терлек мае эшкәртә торган ике завод ача. 1818 елда Сембер губернасының Сызрань өязендә Тимербулат Акчурин сукно мануфактурасына нигез сала. Ул 1825 елда ике мануфактура хуҗасы була һәм анда 1300 кеше ялланып эшли.

Тимербулат Курамша улы Акчурин

19 нчы йөзнең беренче чирегендә элек ябылган кайбер предприятиеләр яңадан эшли башлыйлар. 1812 елгы рус-француз сугышы башлангач, Әсәдулла Иноземцевның XVIII гасыр азагында ук туктап калган бакыр кою заводы эшли башлый. 1828 елда биредә 2500 пот бакыр коела. Сәнәгать күтәрелеше алдыннан сәүдәгәрләр һәм эшкуарлар (предпринимательләр) карамагына үз заманы өчен шактый

зур суммада акча туплана. Мәсәлән, бары тик Казандагы гильдияле сәүдәгәрләр кулында гына да игълан ителгән капитал 1801 елда 110 655 сум булса, 1809 елда ул 482 000 сумга җитә, димәк, биредә дә үсеш сизелә. Шундый ук хәл Оренбург, Әстерхан һәм Касыйм татарларында да күзәтелгән.

Татар фабрикасында – чит ил станоклары

19 нчы йөзнең 30 нчы еллары ахырында-40 нчы еллар башында Россиядә сәнәгать күтәрелеше башлана һәм ул крепостнойлык тәртипләре җимерелгәч кенә тәмамлана. Россия сәнәгатендә башланган машина индустриясе чоры кул хезмәтенә нигезләнгән мануфактураның акрынлап капиталистик төрдәге фабрикага, заводка әверелүенә китерә. Эшләп чыгаруда машина куллану җитештерүнең артуын тәэмин итеп, фабрика продукциясенең бәясен төшерүгә этәрә. Шулай итеп, базардагы кул көче белән мануфактурада эшләп чыгарылган кыйммәтле продукцияне фабрика тауары акрынлап кысрыклап чыгара башлый. Сәнәгать күтәрелеше иҗтимагый мөнәсәбәтләр өлкәсендә дә җитди үзгәрешләргә китерә. Бу чорда чын мәгънәсендә яңа сыйныфлар – буржуазия һәм пролетариат формалаша башлый. Сәнәгать күтәрелеше иң элек руслар кулындагы завод-фабрикаларда башлана. Бу процесс тора-бара татарларга да үтеп керә. Мәсәлән, Сембер өязендә 1848 елда йомышлы татар Әхмәт Алиев пар казаннары куелган сукно фабрикасы ачып җибәрә. Гомумән, Сембер губернасы татар сәнәгате тарихында зур роль уйный һәм ул сукно җитештерү үзәгенә әверелә. 1849 елда Сөләйман Акчуринның пар казаннары һәм механик туку станоклары куелган 2 сукно фабрикасы эшли башлый. 1853-1856 нчы еллардагы Кырым сугышы вакытында патша хөкүмәтеннән гаскәр өчен сукнога бик зур заказлар алган бу фабрикант үз эшен тагын да киңәйтә-үстерә бара. Әйләнештәге капиталы 30дан 80 меңгә, ә аннан соң 200 мең сумга җитә. XIX гасыр урталарында Самара һәм Саратов губерналарында Алиев һәм Дибирдиевларның сукно фабрикалары ачыла. Биредә хәтта чит илгә җитештерелгән станоклар да кулланышка кертелә.

1857 елда Казан губернасында барысы 263 предприятие исәпләнә һәм алар 5 миллион сумлык тауар җитештерәләр. Бу предприятиеләрнең өчтән бере татар капиталистлары кулында була.

Татарлар – рус сәүдәгәрләренә җитди көндәш

Сәнәгать күтәрелеше еллары базарның киңәюе һәм тотрыклануы белән дә характерлы. Ярминкәләр тагын да җанлана. 1848 елда Казан губернасында 22 ярминкә булса, 1858 елда аларның саны 28гә җитә. Өяз шәһәрләреннән Мамадыш, Зөя, Лаеш, Чистай, Спас һәм Тәтеш үзләренең ярминкәләре белән дан тоткан. Татар сәүдәгәрләре Мәкәрҗә, Пермь губернасындагы Бөгелмә ярминкәләрендә дә үз тауарларын күпләп саткан. Алар асылда төрле тукымалар, күн, тире, мех, агач һәм керамик савыт-саба, тимер эш кораллары һ.б. тауарлар белән сәүдә иткән. Сәүдәгәрләр Юнысов, Якупов һәм Акчуриннар кулында берничәшәр миллион сум капитал туплана.

Эчке базарның киңәюендә базарлар да зур роль уйнаган. 1858 елда Казан губернасында 120дән артык зур базар булган. Татар сәүдәгәрләре, бигрәк тә Казан һәм Оренбург янындагы Сәгыйть бистәсе (Каргалы авылы) сәүдәгәрләре Казакъстан, Урта Азия, хәтта Кытай белән дә сәүдә алып барганнар һәм бу төбәктә

Татар мулласы ике хатыны белән

рус сәүдәгәрләренә җитди көндәш булганнар. Чөнки татарлар әлеге төбәктә урта гасырлардан бирле сәүдә иткәннәр. Тел, гореф-гадәт якынлыгы татар өчен җиңеллек тудырган. Өстәвенә, мөселман сәүдәгәрләреннән салым башка диндәге сәүдәгәрләргә караганда азрак алынган.

***

Шулай итеп, 19 нчы йөзнең беренче яртысында татар җәмгыятенең икътисады феодаль характерын акрынлап югалта бара, ә капиталистик мөнәсәбәтләр исә әйдәп баручы көчкә әверелә. Завод-фабрика сәнәгатенең чагыштырмача тиз үсеше, ялланып эшләүчеләрнең саны арту, авыл хуҗалыгына капиталистик мөнәсәбәтләр үтеп керү, яңа икътисади үзәкләр барлыкка килү – болар барысы да туып килүче татар милләтенең икътисади нигезе киңәюенә һәм ныгуына китергән.

Чыганаклар:

1. История Татарии в материалах и документах. – М.: Государственное социально-экономическое изд-во, 1937.
2. Материалы по истории Татарии второй половины XIX в. Аграрный вопрос и крестьянское движение 50-70-х гг. XIX в. – М.-Л.: изд-во АН СССР, 1936.
3. История Казани в документах и материалах. XIX в.: промышленность, торговля, финансы. – Казань: Магариф, 2005.

Дәреслекләр:

1. Сабирова Д.К., Шәрәпов Я.Ш. Ватаныбыз тарихы (иң борынгы чор-XX гасыр ахыры) / Д.К.Сабирова, Я.Ш.Шәрәпов. – Казан: Мәгариф, 2001.
2. Тагиров И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век) / И.Р.Тагиров. – Казань: Татар.кн.изд-во, 1999. ■

Кырымда татар тамгалары

Госман Акчокраклы

عوسمان آقچوقراقلى

قريمدا تاتار تامغالارى

Кырымдагы татар халкының тарих, сәнгать вә әдәбият, вә иҗтимагый тормышына караган мәгълүмат туплау нияте илә, Кырым мәркәзи башкарма комитеты вә Кырым Комиссарлар Шурасының тырышлыгы белән, 1925 елның июль-август айларында дала тарафларында яшәгән татарлар арасында әүвәлдән бирле кулланыла килгән тамгаларга дикъкать ителде.

Мәгълүм булган бу тамгаларны Кырымда яшәүче татар халкы, башкаларныкыннан аерыр өчен, үз малларына кызган тимер белән баскан. Ләкин галимнәр тамгаларны хайваннардан түгел, ә кабер ташларыннан туплады.

Тамгалар менә шундый хәлдә сакланган. 1925 елгы фото

Экспедиция әгъзалары Абызлар кыясындагы тамгаларны өйрәнә. 1925 ел

Госман Нури-Әсән углы Акчокраклы (1879-1938) – кырым татарларының күренекле язучысы, журналист, тарихчы-археолог, тел галиме-полиглот, этнограф һәм педагог. Ул Исмәгыйль Гаспралының «Зынҗырлы» мәдрәсәсендә, Истанбулда һәм Каһирәдә белем ала. Санкт-Петербургта гарәп каллиграфиясеннән дәресләр бирә. Шунда ук булачак шәркыятьче И.Ю.Крачковскийны укыта.

Галимнең мәкаләләре «Тәрҗеман», «Өлфәт», «Вакыт» һәм «Шура» кебек татар вакытлы матбугатында даими басыла. Бакчасарайда аның тырышлыгы белән И.Гаспралы музей-йорты ачыла, Кырым татар педагогика техникумында татар укытучылары тәрбияләнә, йөзләгән тарихи ядкярләр өйрәнелә.

Галим 1938 елда милләтчелектә һәм пантюркизмда гаепләнеп атып үтерелә.

Игътибарыгызга кыскартып тәкъдим ителә торган текстны Госман Акчокраклы 1926 елда Баку шәһәрендә узган I нче Бөтенсоюз тюркологлар съезды өчен махсус язган һәм Бакчасарай шәһәрендә китап итеп бастырып чыгарган.

Кырымның татар авылларындагы һәр зиратында тамгалы ташларны очратырга мөмкин. Мондый ташларда тарих вә язу булмас. Ялгыз бер тамга кабердә яткан әүлиянең кайсы кабиләгә яки олыска караганын аңлатыр. Моннан шәхеснең кем икәне ачыклана. Ак Мәчеттән (Симферополь) төньяк-көнбатышка юл тотарак Сарабыз, Хәйдәрбали вә Алач авылларын кичеп, Абызлар исемле бер авылга килеп керелер. Ул инкыйлабка кадәр Гросс атлы бер кешенең милке булган, хәзерге көндә Ак Мәчет рабфагының идарәсендә булган бер совхоз карамагында. Бу совхоздан көньякка таба ике чакрым кадәр җир баргач, дала уртасындагы табигый бер кыяга чокып язылган тамгаларны күрергә мөмкин. Бу кыя татар халкы тарихында

аз мәгълүм. Ул бүгенгә кадәр Кырым тарихы белән кызыксынган тарихчыларның дикъкатеннән читтә кала килде. Язылган вә басылып чыккан Кырым тарихларында да бу тамгалы кыяташ турында һичбер шәй күрелмәде. Кыяның мәйданы 250-300 кв.сажен кадәр җир алыр. Анда тәртипсез рәвештә уелган 60лап тамга бар. Болардан ачык күренгән 35ен без язып алдык. Кыя җир белән тигезләнеп беткәнлектән, фоторәсемгә авырлык илә генә төшердек.

Кырымның төрле урыннарыннан тупланган татар тамгалары: 1) Абызлар; 2) Хәйдәрбали; 3) Алач; 4) Җулпак; 5) Кара Корт; 6) Айдаргазый; 7) Күзләвә шәһәре (Евпатория); 8) Такыл; 9) Кырык Чулпан; 10) Кадыш; 11) Калач; 12) Каймак; 13) Кирләвәт.

«Абызлар төбәгенең бәрәкәтле туфрагы электән үк көтүлек өчен хезмәт иткән. Ә көтүлек җирләреннән фәкать бу кыяда тамгалары уелган кешеләр генә файдалана алган.

Абызлар кыясындагы тамгалар хакында татар картларында төрле риваятьләр бар. Кайберләре диярләр ки: гүя вакыты илә бу әтрафта яшәгән татар кабиләләре, мөһим булган мәсьәләләрне киңәшү өчен, бу җирдә җәмгыять яки парламент төзегәннәр. Тагын бер риваятькә күрә, татарлар Кырымга элек килгәч тә, бу җирдә кабиләләргә тамга бирелгән вә, онытылмасын өчен, шәкелләре әлеге ташка нәкыш ителгән, имеш. Кырым тарихын тикшергән А.А.Маркович исә башкача фикер әйтә: *«Иске вакытларда сахра татарлары, сабанчылыктан бигрәк, хайван асрау илә мәшгуль булган. Болар һәр ел, кыш айларын кичерү өчен, хайваннарын Кырымның тау тарафына күчергәннәр. Хайван күчен бер тәртип белән озату фикере илә булса кирәк, боларны әүвәл бер ноктага туплау һәм барлау тиеш була. Шуңа күрә әлеге кыя Абызлар авылы малларының туплана торган урыны вазыйфасын башкарган вә хайваннарны тауга җибәрер алдыннан, терлек югалмасын өчен, бу урында аларга тамга сукканнар».* Карт профессорыбызның фикерен бөтенләй үк кире какмыйча, үз тарафыбыздан шуны бәян итәбез: Абызлар төбәгенең бәрәкәтле туфрагы электән үк көтүлек өчен хезмәт иткән. Ә көтүлек җирләреннән фәкать бу кыяда тамгалары уелган кешеләр генә файдалана алган.


- ١١ -

قریمدا تامغالاریك تاشلار اوزه‌ربنده كورونيشله‌ری (*)

(*) بو شه‌كيلله‌ر عيلمی هه‌يئه‌ت آعزاسی موعالليم — ره‌سسام ره‌شيد چه‌له‌بی‌يف تارافيندان آسلينا باقاراق ره‌سم ايديلمش وه ره‌سسام وارفالامه‌يه‌ف تارافيندان حاك ايديلمشدير.

Кабер ташларындагы тамгалар. Г*ыйльми комиссия әгъзасы, мөгаллим, рәссам Рәшид Чәләбиев рәсемнәре*

«Тамгалар, хайваннардан вә кабер ташларыннан кала, акча, байрак, ярлык, мөһер кеби шәйләрдә дә кулланылган. Акчаларда тамгалар аеруча күп очрый.

Тамгаларның формалары каян һәм нәрсәдән алынган дисәгез, аларның күбесе бик гади штрихлардан торуын искәртергә кирәк. Элекке вакытларда тамга нәрсәне дә булса аңлатканмы икәнен дә әйтүе кыен. Ләкин күп кенә тамгаларның хезмәт кораллары һәм көнкүреш кирәк-яраклары рәвешеннән алынганлыгын, аларның исемнәре белән аталуын ачык күрергә мөмкин. Күчмә тормыш чорын хәтерләткән тамгалар башкача ясалса, утрак тормышка һәм игенчелеккә күчү белән тамганың яңа формалары барлыкка килгән. Моны тамганың рәсеменнән дә, атамасыннан да җиңел аерырга мөмкин.



Кайбер тамгаларның шәкеленә карасак, аларның гарәп хәрефләренә һәм саннарына охшаганын күрербез. Ләкин тамгаларның гарәп хәрефләре килгәнче үк кулланылганын истә тотсак, моның гадәти охшашлык кына икәне аңлашыла.

Тамгалар арасында ай, йолдыз кеби күктәге шәйләрнең шәкелләре булганы кеби, халык арасында «Сөләйман мөһере» диелгән алты почмаклы йолдыз шәкеле дә күрелер. Бу шәкел авыллардагы хаҗи яки муллалар каберләрендә очраганлыктан, моның Ерак Шәрыктан түгел, ә Якын Шәрыктан, Гарәбстан вә Сүриядән килгәнен фаразларга мөмкин. Алты почмаклы «Сөләйман мөһере» Бакчасарайдагы Хан сарае диварларындагы нәкышлар арасында да күрелер.

Кайбер ташларда ике тамга күрелер. Бу исә ике аерым кабиләдән өйләнгән ир вә кияүгә чыккан хатынның һәр икәвенең нәсел тамгалары күрсәтелгәнен аңлата.

Тамгалар, хайваннардан вә кабер ташларыннан кала, акча, байрак, ярлык, мөһер кеби шәйләрдә дә кулланылган. Акчаларда тамгалар аеруча күп очрый. Төрек-татар ханнарының һәрберсе үзләренә караган кабиләнең яки олысның тамгасын акчага сугуны гадәт иткән.

1925 елның язында Кырымдагы Иске Кырым шәһәрендә табылган акчаларга мондый тамгалар сугылган:

Акчаның иясе	**Дата**	**Тамга**
Тукта	1291	
Үзбәк	1312	
Туктамыш	1288	
Шәдибәк	1403	
Хаҗигәрәй	1466	

Кырымда табылган тәңкәләргә сугылган хан тамгалары

Тамгалар бина бизәлешендә дә кулланылган. Бакчасарайдагы Хан сараеның диварларында Гәрәйләрнең тарак тамгасы күрелер. Янәдә Бакчасарайдагы Җуфет кальганың диварындагы бөек капусында шундый бер тамга бар. Моның вакыты илә бу кальгада яшәгән татар ханнарыннан яки бәкләреннән калганлыгы ихтимал.

Мәгълүм ки, татар ханлыкларында дәүләт чикләре аша экспортлана торган товарларга тамга салынган, шул исәптән читтән кергән мал-мөлкәткә сугылган тамга да «пропуск» функциясен башкарган. Моның белән татар дәүләтләренең

Сулдан уңга: тарихчы һәм этнограф Госман Акчокраклы һәм Бакчасарайдагы Хан сараеның беренче директоры Хөсәен Боданинский. 1925 ел

аерым кешеләре – тамгачылары шөгыльләнгән. Шуннан рус телендәге таможня сүзе барлыкка килгән дә инде.

Соңгы вакытларда шәрыкны өйрәнүчеләр барчабызга мәгълүм булган Орхон язулары илә татар тамгалары арасында уртаклык барлыгын вә Орхон язуының тамгалардан алынган булу ихтималы барлыгын искәртәләр. Профессор Милионарский «Күлтәгин һәйкәле» исемендәге әсәрендә дә бу турыда сөйләп биргән иде. Без, әлеге мәсьәләне дикъкатькә алып, тамгаларны Орхон язуы илә чагыштырдык. Орхон әлифбасында 37 хәреф бар. Шулардан 16сының Кырымдагы татар тамгалары белән охшаш икәнлеген күрдек.

***

Бу кыска гына мәкаләбездә без төрек-татар халкы мәдәниятенең бер өлеше булган тамгаларның шәкелләрен вә ниләрдә кулланылганын күрдек. Азиядә хайван малында кулланылган тамгалар, Кырымда терлекне тамгалаудан тыш, кабер ташларына да ясала. Бу гадәтнең Азия төркиләрендә булу-булмавы турында мәгълүматыбыз юк. Әгәр дә аларда тамганы кабер ташларында куллану гадәте юк икән, Кырым ярымутравын бөек бер «Тамгалар музәханәсе» дию мөмкин булачактыр. Чөнки монда һәр татар авылындагы зиратта борынгы тамгалар очрый. Тамгалар тарихын өйрәнергә теләгән кешеләр өчен Кырым ачылмаган тарих булып кала бирә. Кыска вакыт эчендә безнең экспедиция тарафыннан 400гә якын тамга җыелды. Мин шикләнмим: әле шуның кадәр үк тамга билгесез калды.

Кырым татарлары теленнән ***Ленар Гобәйдуллин*** *тәрҗемәсе* ■

Безнең мирас №12 декабрь 2021

Бараҗ нәселе яки Иске Сәфәр авылына кем нигез салган?

Рәис Сәетов

Тарихын белмәгән халык белгәннәрнең колы була...
Гамил Афзал

Иске Сәфәр авылы күренеше

Шәҗәрәбезнең бер өлеше булган Бүләр (Бараҗ) шәҗәрәсе бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән. Бу – безнең өчен олы табыш.

Икенче бик мөһим документ – безнең авыл тирәсенең картасы: «Дистанция землемера Лисицына 1801 года». Бу картада 1801 елда Сәпәр (Сәфәр) авылы күренә, Терпеле белән Кадермәт тә бар. Бөят елгасы ике яклап урман-әрәмә белән капланган.

Тагын бер документ – карта «Расселение башкир племени Еней в XVIII-нач. XX вв». Монда безнең авылның Бүләр кабиләсенә кергәнлеге күренә. Бүләр (Бараҗ) шәҗәрәсе белән әлеге картадагы Бүләр кабиләсенең бер халык икәне дәлилләнә, ягъни Болгар төркиләре икәнлегебез күрсәтелә.

Мөһим документларның берсе – 1834 елда үткәрелгән VIII ревизия вакытында Бүләр вулысына кергән, башкорт таифәсендәге (сословие) Сәфәр авылында яшәүчеләр исемлеге, 1859 елгы XX ревизиядә Оренбург губернасының Минзәлә өязендәге 18 нче башкантонының 1 нче «Йорты»на караган Сәфәр авылында яшәүчеләр исемлеге.

«Тулы канлы тормыш белән яшәгән Болгар дәүләтен 1236 елда Батый төмәннәре, 1240 елда яңадан азатлык фетнәсе күтәргән өчен Биләр (Буләр) каласының гаскәр башлыгы Сүбәдәй «бүреләре» килеп тар-мар итә. Шәһәр нигезенә кадәр җимерелә, елга кан булып ага, тормыш юкка чыга. Кинәт ватылган чүлмәктән таралган борчак-ярма шикелле, исән калган болгарлар да, балаларын, ата-аналарын саклап калу өчен, Минзәлә, Ык, Сөн буйларына сибелә. Шулай итеп, Актаныш җирләренә Биләр, Болгар, Җүкәтау һәм Кашаннардан исән калган болгар качаклары да килеп җитә». (Разил Кыямов рефератыннан. – Чаллы, 2016.)

«Татарская энциклопедия»дә, безнең Сәфәр авылына XVII гасырда нигез салынган, дип язылган. Бу вакыт бик чамалы.

«Дистанция землемера Лисицына 1801 года» картасында безнең авылның исеме ачык итеп *«дер.Сапарова»* (Сәпәр) дип язылган. Шул исәптән, якындагы авыллар да картада *«дер.Кадерметева, дер.Терпели, дер.Новая Богада, дер.Ахунова»* дип күрсәтелгән. Документларда бит Саперово, Сапарово дип рус хәрефләре белән руслар язган. Ә бит язганда хәреф хаталары да булырга мөмкин, ничек ишетсәләр, шулай язганнар, руслар хәзер дә авыл исемнәрен үзләренчә үзгәртеп язалар (*«Күн»не – «Конь» (Питрәч) яки «Зирекле»не «Ерыкла» (Яңа Чишмә) дигән кебек*). Мәсәлән, Пучы авылын русча Поисево дип атыйлар, үзенең төп исеменнән бер генә «п» хәрефе калган. Сәфәр исемле авылыбызны да Саперово, Сапарово дип шул замандагычарак язганнар дип әйтеп була.

Авылга беренче булып Сәфәр исемле кеше килеп утырып, авылны ул нигезләгән һәм аның исеме авыл исеменә күчкән, дип әйтү дөреслеккә туры килми. Авылга нигез салучы булып Туктар бабабыз тора, дип күп дәлилләр китерергә була. Ошбу шәҗәрә моны ачык күрсәтә:

18 нче буын



19 нчы буын

Йахшыкай, Сәфәр, Госман, Солтанай шушы авылда нигезләнеп яши. Солтанайның тамыры билгесез. Иң күп тамыр җәйгәне Госманныкылар, аннары Йахшыкай, аннан Сәфәрнеке. Җир турындагы документларга кул куючылар *«Юлдаш Ишдевлетов, Кутла Сафаров, Имангул Яхшигулов»* – барысы да Туктар бабайның оныклары. 1834 елгы исемлектә мәзин Габделвәли Туктаров, указлы мулла Габделхалик Габҗәлилов та шулай ук Туктар бабай оныклары.

Бу исемлекне дәвам итеп булыр иде, әмма әйтеп узганнары да авылыбызга Туктар баба нигез салганын аңлаешлы күрсәтеп тора, бар нәрсә дә Туктаровларга килеп төртелә, димәк, нигезләүче алар – көчле нәсел булган.



«Дистанция землемера Лисицына 1801 года» картасы

Ә Сәфәр исеменә килгәндә, мондыерак фикер туа. Сәфәров дигән фамилияне бер документта гына күрә алдык. 1785 елның февралендә Зәй елгасы буенча генерал-поручик А.Г.Петров-Солововның җир сатуы турындагы ул документка (№172) безнең авылдан *«башкир Котлы Сафаров»* кул куйган. «Башкир» булгач, бу катлам кешеләре җиргә хуҗа икәнлекне күрсәтеп тора инде. 1834 елгы исемлектә аның улы мәзин Муса Котлин исеме бар. Аның 70 яшькә кадәр яшәве мәгълүм. Бәлки, атасы Котлы Сәфәров мәрхүм булгач, Сәфәров фамилиясен йөртүчеләрнең бетеп баруына борчылып, авылда абруе зур булган Сәфәр бабайга хөрмәт йөзеннән, авылга Сәфәр исемен кушканнардыр. Бик мөмкин...

Төбәк тарихын өйрәнүче якташыбыз Йосыф Хуҗинның да Сәфәр авылының килеп чыгышына нисбәтле фикерләре кызыклы: *«Бүләр хан белән Туктарга кадәр чама белән 425 ел арасында 17 буын килеп киткән. Сәфәр 25 елдан соң туган, дисәк, 450 ел килеп чыга. Димәк, авыл чама белән 1614 елда барлыкка килгән булырга тиеш. Авыл тарихчылары, бирегә 1612 елда Сәфәр исемле кеше килеп утыра, дип язалар.*

1646 елгы грамотада Богады вотчинасы, Терпеле һәм Тыңламас елгалары искә алына. Богады биләмәсендә Иске һәм Яңа Богады, Сәфәр, Кадермәт һәм Солтангол авыллары керә.

Ахун, Сәфәр, Яхшый, Бүләк, Әлмәт, Чуракай, Сәет, Кадермәт һәм Сеңрән авыллары Бүләр волостена кергән. 1658 елның 5 мартында Бүләр волосте Сәфәр авылы вотчиннигы патша һәм бөек князь Алексей Михайловичтан үзләренә тиешле ясакны Казанга түләргә рөхсәт сорый. Бөек патша аларга һәр елны Казанга 5 батман (1 батман – 4100 грамм) бал һәм 2 сусар (куница), ә Уфага 10 сусар күләмендә ясак түләргә рөхсәт бирә.

Рәсми кәгазьләрдә кемнең алданрак теркәлеп калуын ачыкларга омтылып карыйк.

1757 елның 1 мартында Җәнәй волостеның Апас авылы кешесе Котлы Минеев иптәшләре белән Агыйделдә балык тоту урынын Каракул волосте крестьяны Л.Д.Глезденевка 20 елга түләүле биләүгә биреп тору хакында эш кәгазе тутыра. Аңа кул куючылар арасында яланда утырган Сәфәрдән Сәлим Московов, Меди (Мәһди?) Сарбаш та була.



Уфа губернасы картасы

Иске Сәфәр авылы зираты.
28 август, 2021 ел.
Л.Лерон фотосы

Әлеге документ Сәфәр авылына Агыйдел тамагыннан да килеп урнашканнар диярга тулы ышаныч бирә, шулай булмаса, зур елга буенда аларның җирләре булмас иде. Авылның Җанай волостена кертелүе дә шуны куәтли. Торалы, Сәлкәй нәселләре дә көн күрә биредә. Ә Туктаровлар, алда әйткәнемчә, көчле кавемнән була.

Туктарның улы Сәфәр, күрәсең, биредә сәфәр аенда тугандыр, аның әлеге нәселдә абруе зур була, алда әйтеп үтелгәнчә, шуңа да исемен 123 елдан авыл атамасына әйләндерәләр».

Сәфәрлеләрнең кардәшләре нигез салган кайбер авылларны да искә алып үтик.

Бүләр хан улы Йәдәшнең Ихсан исемле улының Әлмөхәммәт белән Колмөхәммәт атлы угыллары Сикия елгасы тирәсендә Мөслим районы белән чиктәш Табанлыкүл авылына нигез сала. Яхшыйның Югарысы һәм Түбәне дә – Бүләр хан токымнарыннан булган Туктарның Йахшыкай угылы дәвамчылары яши торган авыллар. Торак урыннары кайбер документларда Йахшыбай дип тә күрсәтелгән.

Йәнәй вулысы җирләрендә – Аксаз инеше буенда Сәфәр авылыннан күчеп киткән кешеләр Яңа Сәфәр (рәсми булмаган исеме – Тәтәй аул) авылын нигезли, ул 1828 елдагы рәсми документларда телгә алына *(«О земельной споре между башкирами Енейской и Камбарской тюб Мензилинского уезда»)*. Хәзерге вакытта Актаныш районындагы Татар Ямалысы авылының бер урамы булып исәпләнә.

Ә Бүләр вулысы җирләрендә исә Яңа Сәфәр исемендәге икенче торак пункт барлыкка килә. 1913 елгы белешмәлектә әлеге авыл Байсар вулысы составында күрсәтелгән, 1921 елгы һәм аннан соңгы документларда Әмәкәй вулысы торак пункты дип теркәлгән. Хәзерге көндә Мөслим районына керә.

(Язма «Сәфәрем» китабыннан (авторлар – Р.Сәетов, И.Хаҗиева) алынды.) ■

КОТОЧКЫЧ АЧЛЫК

СӘХИФӘ ИДЕЛ БУЕНДАГЫ 1921-1922 НЧЕ ЕЛГЫ АЧЛЫКНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА ҺӘМ АЧЫГЫП ВАФАТ БУЛГАН МӘРХҮМНӘР ИСТӘЛЕГЕНӘ БАГЫШЛАНА.

Ачлык белән көрәш

Татарстан җөмһүриятеннән күчүче ачлардан 5 мең кадәр кешенең Богородский[1] пристанена җыелганлыклары һәм анда бик зур авырлыклар күреп ятканлыклары хакында Татарстан Мәркәз Башкармасы хозурындагы Ачларга ярдәм комиссиясеннән хәбәр алынган иде. Комиссия андагы халыкларның хәлләрен тикшерү һәм ярдәм итү өчен, **иптәш Исхак Казаков рәислегендә** Саулыкны саклау, Мәгариф һәм Иҗтимагый тәэминат халык комиссариатларының вәкилләреннән гыйбарәт бер һәйәт җибәргән иде. Комиссия президиумының 29 август мәҗлесендә **иптәш Казаков бу хакта доклад ясады.**

Докладтан аңлашылдыгына караганда, мәзкүр һәйәт әгъзалары иң әүвәл Тәтешкә барып, андагы исполком, Ачларга ярдәм комиссиясе, Балаларның тормышларын яхшырту комиссиясе, Политбюро, Рабкрин[2], Халыкның саулыгын саклау шөгъбәсе *(бүлеге)* вәкилләре белән мөзакәрә иткәннәр *(киңәшкәннәр)* һәм, 27 августта берләшеп Богородскийга килеп, андагы күчүчеләрнең хәлләрен тикшергәннәр. Андагы халыклар барысы 54 груһтан *(төркемнән)* гыйбарәт, аларның күбесе татарлар. Араларында авырулар да бар, үзләре ачык һавада яталар.

Күчүчеләрнең күбесен төрле алдакчылар, документлар алып бирәбез һәм яхшы җирләргә җибәрәбез, дип котыртып алып килгәннәр вә алардан кеше башына 6-9 мең сум акча җыйганнар да, үзләре качып киткәннәр. Шуның нәтиҗәсендә, бичара ачлар бигрәк тә авыр хәлләргә төшкәннәр.

Богородскийга барган һәйәт мәзкүр күчүчеләргә ярдәм итәр өчен, үзе белән алып барган 93 миллион сум акчаны һәм беркадәр азык әйберләрен өләшергә бер комиссиягә тапшырып калдырган. Хәзерге көндә андагы күчүчеләрнең һәммәсенә көн саен җан башына өчәр мең сум акча һәм беркадәр ашамлык нәрсәләр бирелә.

Бер атна эчендә Богородский пристанен күчүче ачлардан бушатырга уйланыла. Хәзер дә һәркөн бишәр йөз кеше озатыла. Алар Петроград, Әстерхан һәм Томски якларына җибәреләләр. Кайсылары, хөкүмәт тарафыннан чәчүлек орлык бирелгәнен белеп, кире авылларына кайталар.

Хәзерге көндә Соколка һәм Пьяный Бор пристаньнәрендә күчүче халыклар юк. Казандагылар да тиз көннән җибәрелеп бетәчәкләр.

Комиссия, доклады тыңлаганнан соң, мәзкүр күчүчеләрне бер атна эчендә күчереп бетерергә тиешле чаралар күрергә һәм аннан калганнарына ярдәмне дәвам иттерер өчен, кирәк кадәр сумма табуны комиссиянең президиумына тапшырырга карар бирде.

30 августта Богородский пристанендәге авыруларны алыр өчен табиблар белән бергә ике барак баркас *(зур лодка)* җибәрелде.

Татарстан. – 1921. – 2 сентябрь.

---

[1] Хәзерге Кама Тамагы.
[2] Рабкрин – Рабоче-крестьянская инспекция.

Богыруслан шәһәрендәге мөселманнарның ач балаларын кабул итү пункты

40 мең пот балык килә

Әстерханнан Татарстан Мәркәз Башкармасы хозурындагы ачларга ярдәм комиссиясе исеменә 40 мең пот балык җибәрелгәнлеге хакында телеграмм алынды. Бу балык иганә тарикынча җыелган.

Татарстан. – 1921. – 2 сентябрь.

Ачларны Төркестанга күчерү

Сентябрь ае эчендә Казаннан Төркестанга атна саен 3 мең кеше күчерелеп торачак.

Татарстан. – 1921. – 2 сентябрь.

«Күп халык ачлыктан гаҗиз булгач, хөкүмәт ярдәме белән Сибирьгә күчә башлады. Ләкин күчкән вакытта станса, пристаньнәрдә күчүчеләрнең җәфа чигүләрен сөйләп торасы да юк.

Кырымда

Керченски төбәгендәге балыкчылар үз араларыннан 14 атаман сайлап, аларга зур балык көймәләре белән диңгезгә балык тотарга чыгу эшен оештыруны тапшырдылар. Бу сәфәрдә тотылган бөтен балык ачлар файдасына биреләчәк.

Татарстан. – 1921. – 2 сентябрь.

Мамадыш кантонында

Бу ел җәй коры килеп, ике басудагы ашлыкның да корып бетүе сәбәпле, кантоннардан халыкларның ачлыктан җәфа чиккәннәре һәркемгә мәгълүм булса кирәк. Яңа ашлык өлгергәнче, ач халыклар төрле үлән тамырлары, агач кайрысы һәм имән әкәләсен ашарга мәҗбүр булганнар иде.

Ниһаять, яңа ашлыкның бар кадәресен тиз генә ашап бетергәч, тагын яз көнендәге кебек төрле үләннәрне ашарга калды. Күп халык ачлыктан гаҗиз булгач, хөкүмәт ярдәме белән Сибирьгә күчә башлады. Ләкин күчкән вакытта станса, пристаньнәрдә күчүчеләрнең җәфа чигүләрен сөйләп торасы да юк. Шуларны рәтләп, билгеләнгән урыннарына җибәрү, әлбәттә, халыкны тук губерналарга күчерү комиссияләренең эшедер.

Тук губерналарга күчми калган кешеләр хөкүмәт тарафыннан бирелә торган чәчү орлыкларын көтеп яталар. Яңа ашлык өлгереп, халык беразга булса да чәчәргә калдыра алмады. Өлгерү белән барын ашап бетерде. Урыннардагы иптәшләр, бар кадәр орлыкларыгызны чәчегез, ашарга бирербез, дисәләр дә, халык урган берсен ашап бетерә барды. Башка елларны беренче спастан чәчүгә чыксалар да, 2-3 нче спаслар үтте, чәчүгә чыккан кеше күренмәде. Инде халыкның бар өмет иткән нәрсәсе – хөкүмәт тарафыннан бирелә торган чәчү орлыкларында. Чәчү орлыклары тизрәк килеп җитсә, халыкның киләчәк көннәренә бераз өмет белән карарга ярый.

Хөсәен Габидов. Дусай, Мамадыш кантоны.
Татарстан. – 1921. – 2 сентябрь.

Балаларны күчерү

31 августта Казаннан Петроградка 104 баланы алып китәр өчен, махсус поезд килде. Бу поездда балалар үзләренең мондагы тәрбияче мөгаллимәләре белән баралар. Һәр 25 балага үзләренең милләттәшләреннән бер тәрбияче билгеләнә. Тәрбиячеләре балаларны кире алып кайтканчы бергә торырга тиешләр. Бу поезд балаларны бүген алып китәчәк.

Татарстан. – 1921. – 23 сентябрь.

Ач балаларга ярдәм бирелә

Балигъ булмаган балаларны социальный һәм хокукый саклау шөгъбәсе, урамга ташланып калдырылган балалар өчен, Казан каласында 8 йорт ачты. Хәзерге вакытта шул йортларда, бөтен нәрсә белән тәэмин ителеп, 800 бала тәрбияләнә. Шушы көннәрдә, читкә җибәрү өчен, бу шөгъбә карамагына Чистай кантонынннан 250 бала килде. Тагын башка кантоннардан да мондый микъдарда киләчәк: Тәтеш кантонынннан – 100 бала, Мамадыш кантонынннан – 100 бала, Лаеш кантонынннан – 50 бала, Зөя кантонынннан – 50 бала.

Татарстан. – 1921. – 23 сентябрь.

Ачларга ярдәм атнасында авыллар

25 сентябрьдән башлап 25 октябрьгә кадәрле Русиянең һәммә җирләрендә ачларга ярдәм атналары ясалачак. Бу ачларга ярдәм атнасында игенле губерналар һәм җөмһүриятләрендәге эшче-крестьяннар Волга буендагы ачлык җәфасын чигүче кардәшләренә ярдәм итү өчен икмәкләр, акчалар, киемнәр һәм башка мөмкин булган тормыш әйберләре җыялар. Шаять, алар ач туганнарына кирәгенчә кул сузуда кимчелек китермәсләр, шаять, алар өстләренә төшкән бурычларын җегетләрчә үтәрләр.

Салкыннар җитте, кыш якынлашуы сизелә. Ачлар өчен тагын бер Газраил артачак. Менә шушы дошманның каһарләреннән саклану өчен, хәллерәк крестьяннар бүген ялангач булганнар өчен кулларыннан килгәнчә киемнәрен, тән капларлык чүпрәкләрен арттырсыннар.

Ачлык сәбәпле атыннан, терлегеннән язган ярлылар басуларындагы печәнсаламнарын, урмандагы утыннарын китерә алмыйлар. Авыллар бергә оешып, бу атнада шундый кулсыз, ярдәмчесез калган ачларның утыннарын, печәнсаламнарын килтерешеп бирергә тиешләр.

Бик күп зәгыйфь гаиләләрнең кышлык өчен пичләре төзәтелмәгән, нигезләре куелмаган, ирләре, балалары Кызыл Армиядә булып, карт-корылардан, хатынкызлардан гыйбарәт гаиләләрнең хуҗалыклары таралган, бернәрсәдә дә кышлык хәзерлеге күрелмәгән. Менә авыллар, калдык көчләрен сарыф итеп булса да, шуларны карарга, бер-беренә ярдәм итешергә тиешләр.

Кыскасы, хәлле хәленчә кулында булган әйбере, идарәсендә булган терлектуары, күкрәгендә булган көче белән бер-берсенә ярдәмгә ашыксын.

Ачлыкның дәрәҗәсе артканнан-арта бара. Аңа булышлыкка тиздән суыклар, авырулар килү ихтималы бар. Без, ач эшче-крестьяннар, алар белән көрәшкә иң элек үзебез оешып чыгарга тиеш.

Фәтхи.
Татарстан. – 1921. – 26 сентябрь.

Текстны басмага ***Рәйсә Шәрәфиева*** *һәм* ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №12 декабрь 2021

Батый хан архивы: ике көн мичтә яндырылган

(Археографик көндәлек. IX сәфәр)

Миркасыйм Госманов

Әстерхандагы Кызыл мәчет. ***1981 елгы фото***

План буенча һәр елны, Татарстаннан тыш, берәр чит өлкәдән татарлар арасына барып, эзләнеп кайтырга тиеш идек. Быел шундый өлкә сыйфатында Әстерхан сайланды. Ләкин миңа берүземә генә барырга туры килә. 10 августта, көчкә алган билет белән самолетка утырып, юлга чыгам. Бу иртәгә булачак. Теләк-максат шул бер – кулъязмалар...

10.08.1968.

Көндезге сәгать 3тә 50 минутта самолет белән «Хаҗитархан хәзрәтләре»нә таба очып киттем. Юл яхшы гына узылды. Шәһәргә кичке 8дә генә җиттем. Мөсафирханә мәсьәләсе бик кыен икән. Көч-хәлгә дүрт кешелек бүлмәгә урнаштым. Иртәгә күз күрер. Бу да төнге 10да гына мөмкин булды.

11.08.1968.

Бүген якшәмбе булганга, беркая да барып булмас, шуңа күрә су буена барып коенырга һәм кызынырга гына кала. Әйе, ял начар булмады. Бүлмәдә бергә яткан Касыйм Әхмәтов дигән бер татар егете (Бакудан, подполковник) белән бергә төшкә кадәр кызынып, аннары өйдә ял итеп, кичен бик озак саф һавада йөреп кердек.

Кояш бик шәп иде. Бу минем быелгы беренче кызу кояшым бугай...

12.08.1968.

Төштән соң Солтан Таһиров дигән кешегә барып чыктым. Газета редакциясе тирәләрендә эшләгән кеше икән. Охо, табыш: Солтан абзыйдан Мәхтүмколый(!) шигырьләренең бер җыентыгы!

Әстерхан өлкәсендә 70тән артык татар авылы бар! Охо, бу 2-3 еллык экспедиция өчен эш!

13.08.1968.

Иртәнге якта тагын Өлкә башкарма комитетына бардым. Аннары Канеев Кәрим абзый дигән кешеләргә кердем. Көн бик бөркү иде. 1918 елны Әстерхан Кремлендә табылган борынгы кульязмаларны яндыру булган... Крупская исемендәге үзәк китапханәдә татарча китапларны өләшү, тарату булган, имеш.

1930 нчы елларда Әстерхан музеенда шактый әйберләр булган. Аларны Алимов Сабир караштырган, кайберләрен Мәскәүгә җибәргән, ул 1939 елда үлгән.

Мәхтүмколый әсәрләренең беренче китабын бастыручы Ниязидан калган кульязма китапларны Төрекмән Фәннәр академиясе кешесе 1966 елны сатып алып, Ашхабадка алып киткән – Таимов дигән кеше. Ниязи төрекмән булган!

Шәһәрдә Гатаулла Әхтәмов – һәвәскәр тарихчы, этнографик әйберләр җыйган. Шиһаб Мәрҗанинең шәкерте Гомәров Габдерахман – «Идел» газетасын чыгартучы, аның көтепханәсе бик бай булган. Хәзер балалары читтә.

Зариф Кәримов – мәчет мөтәвәллияте рәисе. Сөйләштек, килештек... Мәчетнең икенче этажына менеп, китапларны актарып чыктым. 30-40лап кульязма аерып куйдым. Арада шәп кенә әйберләр. Мине бигрәк тә бер «Йосыф китабы»ның нөсхәсе җәлеп итте. XVII-XVIII гасыр әйберләре шактый! Аерып куйдым. Җибәрер көнне килеп алырмын.

Кичен һава иснәргә чыккан идем. Әбрар Кәримуллинны күрдем. Ул хатыны белән пароходта килгән икән. Бергә озак кына шәһәрдә йөрдек. Касыйм шәһәрендәге сәяхәтне искә төшердек...

«Төрекмән авылларының балалары, нигездә, татарлардан укыганнар!

14.08.1968.

Көн бик матур иде. Төшкә кадәр кояшта кызынып, су кердем...

Төштән соңгы якта Гатаулла абзый Әхтәмов дигән кешегә килдем. Озак кына сөйләшеп утырдык. Респондент булырга каршы түгел кебек. Солтан абзыйлардан алган Мәхтүмколый әйберләре шушының кулыннан чыккан икән. Ул аны мәчеттән алган булган... Димәк, татарлар арасында булган бу кульязма!

Әминә һәм Гатаулла Әхтәмовлар. 1960 нчы еллар. 1980-1990 нчы елларда М.Госманов Әхтәмовлар гаиләсе белән дусларча аралашып яши.

Тагын ишеттем: архив яну. 1918 елны Кремльнең Артиллерия манарасы эченнән бик күп китаплар чыккан булган, ләкин аны ике көн мичтә яндырып бетергәннәр. Хан Батый архивы дип сөйләгәннәр... Яндыручы кеше Воронцов дигән бер егет, старшина. 1936 елларны утиль кәгазьләре җыйган вакытта бик күп кульязмалар җыелган булган. Аларның кая китүләре нәмәгълүм. 1966 елны Ниязи китапханәсеннән калган ике сандык әйбер Төрекмәнстанга киткән.

Гатаулла абзыйлардан чыккач, Нугай мәчетенең имамы Тәлгать Әхмәтшин белән танышып чыктым. Әле генә 40ка кергән чибәр генә яшь егет, чәч үстергән, кечкенә генә мыеклы. Хәйләкәр күзле, елгыр сүзле бер шомабай (бәлки, шомбайдыр?!). Хәзергә вәгъдәләре зур. Иртәгә сәгать икедә очрашабыз...

Өйгә соң гына, арып кайттым. Кульязма күтәреп кайтмасам да, бүген бик канәгать. Бигрәк тә Гатаулла абзый белән танышу өчен.

15.08.1968.

Төшкә кадәр кызынып яттым. Көн бик шәп иде. Аннары Нугай мәчетенә кереп китаплар карадым. Бернәрсә дә юк. Аннан соң Тәлгать Әхмәтшин белән бик

озак сөйләшеп утырдым. Гаҗәп: әллә чынлап ышана, әллә бик нык икейөзле, паразит? Һәр икесе дә бар бугай... Ә төштән соң көн бозылган иде...

Автостанциягә барып, маршрутлар белән танышып йөрдем.

16.08.1968.

Мәчеттәге кульязмаларның берничәсен (15-16) сайлап алып, почтага илтеп, биш посылка итеп салдым. Арасында бер кульязма Корьән 4,5 кг булды. Төштән соң бераз кояшта кызынып, су кердем. Көн бик эссе иде. Бөркү. Бая шабыр тиргә баткан идем.

Мәчет канцеляриясендә утыра идем: шау-шу, милиция килгән. Мәчет әһелләре арасында җәнҗал чыкты, шуңа чакыртканнар. Мөтәвәллиләр арасында кәсеп бүлү!

Күзем эленеп торган бер җәдвәлгә төште: бу, янәсе, муллаларның кунакка чакырылуын күрсәтә торган «җәдвәл» икән. Көннәр, числолар, сәгатьләр күрсәтелгән. Ярар иде дә, тик мондый гыйлемлек мине шаккатырды: дәгъват мәҗлескә көннәр, сәгатьләр. Менә сиңа гыйлемлек!

17.08.1968.

Көн болытлы гына һәм тынчу иде. Татар Абиловкасына киттем. Анда бер мәчет булырга тиеш. Мәчет имамында булдым: әзер әйберләре булмаса да, киләчәктә кайгыртырга вәгъдә итте. Бикмөхәммәт Зарипов. Бу кеше белән киләсе елны күрешергә...

Хәлилула Евлаев дигән абзыйдан сораштым: бу Татар Абиловкасы авылын 1902 елны Сталинград янындагы Каменный Ярдан күчеп килгән татарлар нигезләгән. Җирне Абилов дигән помещиктан иҗарәгә алганнар. Авыл исеме шуннан калган. Ләкин бу Абилов әрмән булган.

Хәлилула абзый – гел урысча кушып сөйли торган чын мишәр. Волга янындагы иң карт авыл – Кучергановка (Каңга). Хәлиулла абзый Тукай белән бергә төшкән группа рәсемен күргән. Хәзер ул кешенең адресы онытылган... Эзләп карарга вәгъдә итте!

Кичен Гатаулла абзый Әхтәмовларга килеп, озак сөйләшеп, кайбер кульязмаларны карап утырдым. Хәзерге Чуваш АССРдагы Батыр районының Сорил авылында (русча Иш-Суринский) бер чуашның аты урамда җиргә бата. Бу баз була. Базга аркан белән төшәләр, төшкән кеше чыккач, анда әллә нинди төргәкләр, аңлаешсыз әйберләр булуын әйтә. Халык, куркудан, базны күмеп ташлый. Моны шул авылдагы Сәлахиев Гатаулла абзыйдан сорашып белергә була. Бу урын якынча Әхәт Сөнгатуллин йорты каршында...

Гатаулла абзыйларда бик озак, бик шәпләп кунак булгач (кайнар пәрәмәч, карбыз, алма, йөзем белән), соң гына өйгә кайттым...

18.08.1968.

Автостанциягә барып, Кымызак автобусына утырып, Каргалык авылына килдем. Шәһәрдән ерак түгел – 20 минутлык юл. Байкин Сәлах абзый дигән картка килдем. Ишегенә «Почетный гражданин Сәлах Байкин» дип язып куелган. Авылны нигезләүче халык, нигездә, нугайлар. Килеп утыручы Казан татарлары да шактый.

Моннан төрекмән авылы Атал ерак түгел – 6 км. Анда, Сәлах абзый Байкин әйтүе буенча, тарих белүче Халка Җанморатов дигән пенсионер белән

очрашырга кирәк, ул күп еллар Төрекмәнстанда торып кайткан!.. Төрекмән авылларының балалары, нигездә, татарлардан укыганнар!

Нугайларда ыруглык әле дә сакланган. Борынгылыкны саклаган авыллардан: Ярлы Түбә (Осыпной Бугор) бар, Киләче, Җәмәле…

«Ләкин бик укымышлы пенсионерлардан ераграк тору яхшырак кебек: акыллары күп, материаллары юк...

Кызан (Татарская Башмаковка) авылында яшәгән Гомәр мулла дигән кешенең энесе – Җәли. Йосыф мулла һ.б.га мөрәҗәгать итәргә – язма әйберләр булырга тиеш. Кызанның мулласы Ваһап мулла! Монда да бик күп китап яндырулар булган…

Нугай һәм татар авыллары руслар белән аралаш. Бары карагачлар гына бераз аерылып торалар. Карагач авыллары: Сәетләр, Кушамтай, Җанай.

Атал авылына килдем. Халка абзый өендә юк икән. Җама абзый Нурмөхәммәтов дигән бабайга килдем. Авыл «архитектурасы» ярты сахра. Бакча, виноград яклары бик сай. Күчмә тормыш исе килеп тора… Куралар тулы тизәк…

Аманов Таха дигән пенсионерда борынгы җырлар, китаплар һ.б. әйберләр бар… Бу Таха белән сөйләшеп утырган чакта, Корбан Динмәмәтов дигән берәү үзе килеп, миндә кайбер әйберләр бар, дип алып китте. Барып карагач, аның китаплары арасында Мәхтүмколый шигырьләренең ике китабының өлешләре чыкты. Тагын берничә төрекмән әйберләренең текстлары бар!

Мөсафирханәгә соң гына кайттым һәм алып кайткан әйберләрне рәтләдем. Мәхтүмколыйның 4 китабыннан фрагмент булды!

19.08.1968.

Бүген иртәдән көн матур гына иде. Шуннан файдаланып, су кереп алырга булдым.

Төштә Ярлы Түбә авылына бардым. Якуб абзый Кәримуллин өендә юк иде, ләкин карчыгы китапларны күрсәтте. Ике кулъязма алдым.

Фунтов авылына килеп, Җомамөхәммәт дигән төрекмәннән Сәгъдинең «Таһир-Зөһрә» поэмасын алдым.

Хәзер юл уңае машина белән Әстерханга кайтырга кирәк. Автобуслар туктаган иде. Уңае белән бер машинага утырып, Ярлы Түбәгә, аннары автобус белән шәһәргә кайттым.

20.08.1968.

Көн яхшы иде. Төшкә хәтле су буенда булдым. Бер-ике җиргә барып чыктым. Рәт юк. Кичен Гатаулла абзыйда тагын кунак булып утырдым. Әлеге медицина буенча дигән китабын табып куйган. Шәп әйбер. 1755 елда күчерелгән. Шәп сакланган. Гатаулла абзыйның киңәше: экспедиция белән килгәндә ялгыз гына килергә, студентлар көтүе белән йөрүдән максат һәм файда юк!

21.08.1968.

Төштән соң, эзләп, Сөләйман Коләхмәтовка килдем. Озак кына сөйләшеп утыргач, түбәндәгеләр ачыкланды: 1920 нче елларда педучилищеның китапханәсе булган…

Көне буе йөреп, әллә нинди мәгънә чыкмады. Ләкин бик укымышлы пенсионерлардан ераграк тору яхшырак кебек: акыллары күп, материаллары юк...

22.08.1968.

Иртүк килеп (Тат. Абиловога), Хәлиулла абзый белән бик күп йортларга йөреп чыктык. Күп җирдә бернәрсә дә юк. Ләкин Зәкәрияев Әҗмөхәммәт (Кучерган авылы) дигән кешедә атасы Хаҗи Галидән калган бер язмалар дәфтәре игътибарны тартты. Хаҗи Гали язган шигырьләрдән тыш, анда кайбер тарихи язмалар да бар! Эчендә шигъри язылган Әмәт хикәясенең «Мөкаддимә»сеннән китерелгән фрагмент исә бөтенләй яңа нәрсә! Хәзер бирергә хуҗа риза түгел, шуңа күрә аны киләсе ел эләктерергә кирәк!

Хәлиулла абзыйдан караган әйберләрдән исә, аерым документлар һәм хатлар игътибарга лаек. Ә «Форпост тарихы» исә бик шәп, кыска гына, яшь кенә булса да!

25.08.1968.

Нугайлар элек ыругларга бүленгәннәр: Алаш, Куңгырай, Ойгыр. Бу – Кызандагы ыруглар. Алашның тамгасы – Λ, аерым семьялар шушы тамганың төрле ягына төрле таяклар, сызыклар куеп, бер-берсеннән аерылганнар. Бу бабай шактый аңлы һәм укымышлы булганга охшый. Борынгы нугай җырлары язылган дәфтәрен алып чыкты.

Киләче авылы. Ибраһим Мәхмүдев – бик белдекле карт... Бабайның үзе соңгы вакытларда күчергән дәфтәрендә хушавазлар шактый иде. Фәхреддин, Садыкбай һ.б. җырчыларның әйберләре бар.

Төштән соң Тат. Абилово авылына килдем. Хәлиулла абзый тагын берничә кульязма әзерләп куйган икән. Әһәмиятсез. Ләкин 4-5 кг виноград бирде – күчтәнәч итеп. Менә бусы ярады – яхшы сорт, әйбәт сакланачак.

Шулай итеп, экспедиция очланып килә. Иртәгә юлга әзерләнәчәкмен...

26.08.1968.

Иртәнге якта Казанга кайтып җиттем. Рәхәт самолетта: 2 сәгать 15 минут. Ә Казанда яңгыр, салкынча шул, искечә...

Нәтиҗәләр:

Разведка сыйфатында оештырылган бу сәфәр ярыйсы гына тәмамланды. 25тән артык әһәмиятле генә кульязмалар алып кайту өстенә, иң мөһиме – җирле халык белән контакт урнаштырып кайттым. Киләсе елны эшләргә җирлек бар! Бу минем төп максат иде. Димәк, ул үтәлде.

Алып кайткан әйберләр арасында Мәхтүмколый әсәрләре, медицина буенча трактат, «Йосыф китабы», Форпост авылы тарихы кебек әһәмиятле әйберләр дә бар.

Халык эчендә эшләү бигүк җиңел түгел. Бары танышлар ярдәмендә генә уңышка ирешеп булачак, шуңа күрә киләсе елны, студентлар төяп барасы урынга акча гына алып барып, шуннан бер-ике пенсионерны эшкә ялларга кирәк булыр.

Китап сатып алу өчен дә акча алырга кирәк. Нәтиҗә әйбәт. Өмет тагы да зуррак. Вәссәлам!..

*Көндәлекне басмага **Диләрә Госманова** әзерләде.* ■

Безнең мирас №12 декабрь 2021

Гәүһәршад

(Тарихи хикәя)

Фирдәвес Зариф

«Гәүһәршад». ***Зөфәр Хәкимов рәсеме***

Гәүһәршадның бүлмә ишеген шакыдылар.

– Әйе, керегез.

Бикә бүлмәсенә, сулуы кабып, карачы йөгереп керде:

– Ханбикә, шомлы хәбәр китерүем өчен алдан ук кичерү сорыйм! Урыслар...

Гәүһәршад аны сабыр-ипле генә бүлдерәсе итте:

– Ханбикә дип әйтмәү хакында мин сине кисәткән идем шикелле, Тугыш карачы.

– Кичерегез, бикә! Алтын Урда ханнары нәселеннән булган Ибраһим хан кызына мин башкача эндәшә алмыйм.

– Казанда нәселгә карап түгел, ә тәхет биләүгә карап баш ияләр, Тугыш карачы.

– Анысы шулай, бикә. Әмма ул тәхет хуҗалары соңгы вакытларда килмешәкләрдән генә тора башлады шул. Килмешәкләр басты Казанны!..

– Хак сүз сөйлисең, Тугыш карачы. Мәҗлес әһелләренең, бәкләр, морзалар һәм угланнарның күпчелеге – килмешәкләр. Килмешәкләр хәзер Татар Иле, Казан, Ватан язмышы белән сату итә! Сер сакларлык, киңәшерлек кеше дә бетеп бара Казанда. Кемне алма – шул шымчы... Сүз сөйләрлек кешеләрдән сәед белән син генә калдың.

– Ышанычыгыз өчен рәхмәт, бикә. Сүзегез – хакыйкать! Аксөякләрдән ил язмышын кайгыртырлык кеше калмады шул.

– Ярый, читкә киттек, карачы. Хәбәреңне әйт.

– Урыслар Зөя кирмәненнән Казанга яуга кузгалган, бикә. Алар белән Шаһгали, качкын ханнар һәм морзалар гаскәрләре дә бар, ди.

– Шаһгали... Казанны алып, хан буласы килә, димәк. – Гәүһәршадның йөзе ачу-нәфрәттән алсуланып чыкты. – Бу хакта хан хәзрәтләре беләме?

– Юк әле, бикә. Җиткерергә өлгермәдем.

– Кичекмәстән җиткер. Берочтан, Шәрифкол сәедкә дә сугылып чык.

– Баш өсте, бикә, баш өсте.

Тугыш карачы, түбәнчелек белән баш иеп, ишеккә таба арты белән чигенде дә юк булды.

***

Шартлау тавышлары тынып, җимерек дивар тузаннары басылырга да өлгермәде, Шаһгали һөҗүм башларга әмер бирде. Җимерелүдән хасил булган аралыкларга, җанлы дивар булып, Казанны саклаучылар басты. Җанлы калканга бәрелеп, «маңгаен авырттыргач», Шаһгали Нугай капкасына юнәлде. Әмма казанлылар, капкадан чыгып, аларны чигенергә мәҗбүр иттеләр. Шуннан соң Шаһгали, каберләр өстендәге агачларга яшеренеп, Болакны кичте һәм Арча тарафына үтте. Арча капкасы буендагы бәрелештә, сан ягыннан өстенлек һәм зур югалтулар исәбенә ул, ниһаять, ныгытма эченә үтеп керүгә ирешә. Һәр адым коточкыч кыйммәткә төште сатлык татарларга. Берничә сәгать дәвамында алар бер адым да алга китә алмадылар. Инде көн төшкә авышкач, алар артыннан калага, аяк атларлык ара калмый түшәлгән җансыз гәүдәләргә басып, урыс гаскәрләре тулды. Хәер, биредә аларга да эш калган икән әле. Беришләре, ыңгырашу авазларын ишетеп, яралыларны сөңге белән чәнчеп чыкса, икенчеләре инде, сакчыларсыз калган йорт, мәчет ишекләрен ватып кереп, биредә яшеренеп торган хатын-кыз, карт-карчык, бала-чагаларга ташланды. Кычкырыш, елаш китте. Урыслар олы яшьтәге ир-атларны, арба көпчәгеннән калкуырак булган ир балаларны суя башладылар. Аларны яклап арага кергән хатын-кызларны да аяп тормадылар. Гүзәл хатын-кызларны һәм мал-мөлкәтне, патша әмерен үтәп, дивар аръягындагы лагерьга озата бардылар. Кулга эләккән алтын-көмешне, патша малы исәбенә кертмичә, изүгә генә шудырдылар...

Ә кала үзәгендә аяусыз кырылыш бара иде. Шаһгали сугышка өстәмә көчләр кертте. Кенәз Курбский аңа ярдәмгә кенәз Воротынскийны һәм, патша рөхсәте белән, Иоанн запас полкының бер өлешен җибәрде.

Ядегәр хан яугирләре белән акрынлап төньякка таба чигенә башлады һәм Таҗик чокыры аша аргы якка чыкты. Шулчак аларга ярдәмгә Шәрифкол сәед җитәкчелегендәге дин әһелләре һәм шәкертләр кушылды. Ядегәр хан ярсулы һөҗүмгә күчте. Сирәгәйгән Шаһгали гаскәриләре тәртипсез рәвештә чигенә башладылар. Алар артыннан килгән урыс полклары да куркып-каушап калды,

Редакциядән: *Прозаик һәм шагыйрь, журналист, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррир урынбасары Фирдәвес Зарифның (Фирдәвес Забихулла улы Зарифуллинның) 25 декабрьдә гомер бәйрәме. Хезмәттәшебезне юбилее белән котлап, сәламәтлек, иминлек, тигезлек белән хәерле озын гомер һәм иҗат уңышлары теләп калабыз!*

чигенү җаен карады. Тора-бара чигенү качуга әйләнде. Качучылар талаучы башкисәрләр белән тигезләшкәч, тегеләр, таланган әйберләрен ташлап, куркудан күзләрен акайтып, төрле якка сибелделәр:

– Каравыл, бетерәләр!

– Татарлар килә, качыгыз!

Котылу юлын таба алмагач, күпләр дивар коймасыннан аска ташланды.

Урысларны җиңелү ачысын татудан Шаһгалинең поскында торган атлы гаскәре генә коткарып калды. Алар Ядегәр хан яугирләренең сирәгәйгән сафларын чигенергә мәҗбүр иттеләр. Әмма Шәрифкол сәед җитәкчелегендәге дин әһелләре һәм шәкертләр һәр адымны үтә тәвәккәллек белән сакладылар һәм һөҗүм итүчеләрне мәчеткә якын җибәрмәделәр. Бары сәед һәм аның тарафдарлары һәлак булгач кына, Ядегәр хан яугирләрен хан сараена кысрыклауга ирештеләр. Сарай капкалары янындагы аяусыз сугыш сәгатьтән артыкка сузылды. Капка сакчылары һәлак булгач, урыслар, капкаларны ватып, Шаһгали татарлары белән эчкә бәреп керделәр. Алар күзенә бер якта – дәрәҗәле татарлар һәм җансакчылары белән хан, икенче якта затлы киенгән берничә мең гүзәл зат күренде. Һөҗүм итүчеләр Ядегәр хан яугирләренә ташландылар. Калку урынга менеп басып, сарайны саклаучылар белән җитәкчелек иткән Гәүһәршадны Шаһгали шундук танып алды:

– Бирелегез, бикә! Хан кызы булганга, мин олуг патшадан Сезгә ярлыкау сорармын.

– Мин этләрнең кызгануына мохтаҗ түгел, Шаһгали! Кяферләр патшасына койрык болгап йөрдең, үлемең дә баскыч астында булыр...

Бу сүзләр Шаһгалинең йөрәгенә хәнҗәр булып кадалды. Ул бер агарынды, бер күгәренде. Аннары, исенә килеп, үзен уратып алган яугирләргә: «Алыгыз аны!» – дип боерды.

«Гәүһәршадның соңгы алышы». ***Зөфәр Хәкимов рәсеме***

Гәүһәршад, янында басып торган җансакчысының кылычын алып, үзе үк Шаһгалигә таба ыргылды. Шуны гына көткән гүзәл затларның кулында хәнҗәр һәм кыска кылычлар пәйда булды.

Хатын-кызларның батырлыгын күреп, Ядегәр хан яугирләре гайрәт белән дошманга ташландылар һәм аны сарай капкаларыннан кысрыклап чыгардылар. Әмма шулвакыт дошманга ярдәмгә яңа көчләр килеп җитте. Гүзәл затларның барысы да, дошман кулына бирелми, сарай капкалары янында ятып калды. Гүзәллекләре белән илчеләрне дә сокландырган чәчәктәй гомерләр шулай өзелде. Алар арасында егылганда да кулыннан кылычын төшермәгән, Казан халкының йөз аклыгы, намусы булган ватанпәрвәр – Ибраһим хан кызы Гәүһәршад та бар иде.

Гәүһәршадның сөттәй ак күлмәгенең күкрәк турысы шәфәкъ кызыллыгы төсенә кергән. Коеласы татар канының әле азагы күренми, ә татар дәүләтчелегенең кояшы баю ягына авышкан иде... ■

МИФТАХЕТДИН АКМУЛЛАНЫҢ ТУУЫНА 190 ЕЛ

Туксанбайда – Акмулла авылында

Ләбиб Лерон

«Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин шагыйрь Мифтахетдин Акмулланың (1831-1895) Туксанбай авылындагы (Миякә районы) музее каршында. 18 октябрь, 2021 ел. ***Л.Лерон фотосы***

Быел миңа, «Мәдәни җомга» газетасының һәм «Казан утлары» журналының баш мөхәррирләре Вахит Имамов һәм Рөстәм Галиуллин белән бергә, Башкортстанга дүрт мәртәбә сәфәр кылырга туры килде. Дүртенче сәфәребез вакытында, кичке караңгылык төшүгә карамастан, Миякә районындагы Туксанбай авылына да кереп чыгасы иттек. Әлбәттә, кичкә калуыбыз сәбәпле, шушы авыл тумасы саналган Мифтахетдин Акмулла (1831-1895) музеена керү, андагы экспонатлар белән танышу мөмкин булмады. Шулай да, авыл өйләрен күздән кичерә-кичерә, Туксанбайның кичке тынлыкка төренгән урамнарыннан үтәргә туры килде. Авыл кешеләре белән сөйләшеп-гәпләшеп тору насыйп булмаса да, без Акмулланың рухы белән беркадәр очрашкандай булдык.

Әлбәттә, без: «Кем ул Акмулла: татармы, башкортмы, әллә казакъмы?» – дигән сорауга җавап эзләп йөрмәдек. Җырдагыча әйткәндә, билгеле бит инде болай да…

Сүзне, озакка сузмастан, мәшһүребез **Ризаэддин Фәхреддин**гә бирик әле.

Р.Фәхреддин Мифтахетдин Акмулла белән аның фаҗигале үлеменә бер ел чамасы калганда, ягъни 1894 елның сентябрендә Уфада күрешә. Бу турыда ул соңыннан болай дип яза: *«...Уфа шәһәренә килде. Күрештек. Бу вакытта бу кешенең Мәрҗани хакында басылган мәрсиясене күргән вә шул васита берлә үземне ерактан торып, беркадәре генә булса да белгән идем. Моны казакъ акынларының берәрсе булыр дип йөридер, ләкин, мәзкүр мәрсия эчендә үземезнең шивәмезчә тәртиб ителгән шигырьләр булганлыктан, бу гөманымның тугъры булуына шөбһә берлә карыйдыр идем...*

Егерме биш яшендә вакытында үзенең ватаныны калдырып чыгып киткән вә казакъ арасына барып кергән (...), вә казакъ угылы казакъдан аерып алмаслык бер дәрәҗәгә ирешкән. Үзендә шигырь сөйләүгә истигъдад (сәләт, куәт. – Л.Л.) барлыгыны вә шуңар әһәмият биреп, шуның берлә шөгыльләнүне ошбу көндән башлаган булуы зани ителәдер...

Үземездән элек аның дөньядан күчүене хәтеремә китермәгәнем, һәрвакыт үз гомерем кыска булуны уйлаганым сәбәбендән, бу адәмнең тәрҗемәи хәленә мөнәсәбәтле мәгълүмат хакында бернәрсә дә сорашмадым вә язмадым. Мәгәр дә үзе сүз арасында ата-анасының берсе Казан кешесе булганы хәлдә, икенчесе халис башкорт икәнлекне сөйләгән иде; шул нәрсә хәтеремдә калган».

«Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Л.Лерон Туксанбай авылына илтә торган юл читендәге М.Акмуллага куелган стела турысында

Инде бу урында сүзебезне икенче мәшһүребезгә – **Миркасыйм Госманов**ка бирик. Р.Фәхреддинне дәвам итеп, ул болай ди: *«Бу мәгълүматны «өлешчә җавап» дип билгеләүнең сәбәбе шунда ки, күп кенә документларга караганда, Акмулланың тудырган атасы Мөхәммәдьяр асылда Сырдәрья якларыннан килгән казакъ кешесе булып, яшьли татар һәм башкортлар арасында торган, татар мәдрәсәсендә укыган һәм, башкорт җирендә татар кызы Бибигөлсем Сәлим кызына өйләнеп, шуннан 1831 елның 14 декабрендә Туксанбай авылында (Р.Фәхреддин буенча – Дүсәндә) булачак шагыйрь (Мифтахетдин) туган. Мөхәммәдьяр яшьли үлеп киткәч, анасы Бибигөлсем Камалетдин Ишмөхәммәд угылы исемле башкортка кияүгә чыга. Моны шагыйрьнең үз сүзләре үк раслый:*

«Акмулла алты яшендә ятим калган,
Әкәсе үлеп, чичәсен истәк алган...»

Туксанбай авылының бер урамы

Әгәр казакъча «әкә» – безнеңчә «әти»гә, «чичә» «әни»гә туры килсә, «истәк» дигән тарихи атаманың элек башкортларны аңлатуы күптән мәгълүм факт (Акмуллада «истәк мулла», ягъни «башкорт мулла» дигән гыйбарә дә очрый).

Мифтахетдиннең чын атасы кем булу мәсьәләсен аның кабере өстенә куелган таштагы язу хәл кыла. 1980 елның җәендә, археографик экспедиция вакытында, Миасс шәһәренә кереп, моңарчы тексты төгәл басылмаган әлеге ташны яңадан тикшереп укып чыктык. Таш шәһәр белән тимер юл арасында «кысылып» калган татар зиратында саклана, иңе – 42, җир өстендәге буе – 70, калынлыгы – 10 см. Текст пөхтә почерк белән башкарылган җиде юлдан гыйбарәт:

«Къәтле шәһидән
Сәнәти 1313 нче фи сәманийәти
Җөмали-ел-үля фи ләйләтиул-җомга
Мелла Мифтахетдин әлмәгъруф
Би Акмулла ибне Мөхәммәдьяр хәлфә
Нәсәбән вә ибне мелла Камалетдин
Тәрбиятән. Тәммә, тәммә».

Татарча юлга-юл күчермәсе: «Шәһидләрчә үтерелгән, 1313 (һиҗри) елда сигезенче җөмадиел үләдә, җомга көнне кичен (Милади буенча 1895 елның 26 октябрьдән 27сенә каршы төнгә туры килә. – М.Г.), Акмулла исеме белән билгеле Мифтахетдин, нәсел буенча атасы Мөхәммәдьяр хәлфә, тәрбия буенча атасы мелла Камалетдин. Тәмам, бетте».

Шагыйрь үз анасының кем булуы хакында да шактый ачык әйтә, мәсәлән, казакъ укучыларына мөрәҗәгать итеп, үзенең ата нәселе буенча казакъ икәнлеген расларга теләгән бер шигырендә ул болай ди: «...агалар, хәүф итәмен: анасы нугай кызы димәсәңез».

Нугай дип, киң мәгълүм булганча, казакълар татарларны атаганнар һәм хәзер дә шулай атыйлар.

Әмма булачак шагыйрьгә үз анасыннан да яшьли аерылырга туры килә:

«Үгәй ана кулында йәтим калдым,
Андан да бик эрәтем китеп калдым», –

ди ул соңрак, көрсенеп.

Шулай итеп, шагыйрьнең моңарчы тиешле дәрәҗәдә җәлеп ителмәгән үз сүзләре аның тудырган атасы буенча – «чала» казакъ, тәрбияләгән әтисе һәм, ихтимал, үги әнисе ягыннан – өлешчә башкорт, туган, ак сөт имезгән анасы тарафыннан исә ярты татар булуын раслый икән.

Булачак шагыйрьнең мәктәп-мәдрәсәдә алган тәгълим-тәрбия якларына игътибар итсәк тә, шундый ук нәтиҗәгә килер идек.

Акмулланың теле турындагы хәбәр дә игътибарга лаек: «Үзе... – дип дәвам итә Р.Фәхреддинов, – яхшы гына казакълашкан булса да, сүзендә артык казакълашмый: бөрҗан вә үстергән башкортларыннан аермасыз рәвештә сөйләшер иде». Әгәр моңа өстәп, Мәрҗанигә багышланган Акмулла әсәрләренең, нигездә, әдәби татарча, ә башка кайбер шигырьләренең шактый өлеше казакъча язылган булуын игътибарга алсак, шагыйрьнең аңсыз рәвештә әллә нинди катнаш телдә түгел, бәлки, төрле аудитория өчен махсус тел-стильдә язарга омтылганлыгын аңларбыз.

Безнең көннәргә хәтле килеп җиткән шигырьләренең иҗтимагый яктан иң тирәннәре Шиһабетдин Мәрҗани эшчәнлегенә бәйләнгән булуын, шулай ук башка әсәрләрендә дә Болгар-Казан тематикасы күтәрелүен, «казакъча яздым» дигән әсәрләренең зур өлеше татарча яңгыравын исәпкә алганда, Акмулланың тирән тамырлы татар поэзиясе чишмәсеннән мул һәм даими су эчкәнлеге бәхәссез».

Мәшһүрләребездән узып артык сүз сөйләп тору кирәкмидер, шәт, барысы да аңлашыла.

«Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире Вахит Имамовның Мифтахетдин Акмулланың аянычлы язмышы хакында уйланып торган мәле. 18 октябрь, 2021 ел. ***Л.Лерон фотосы***

Туксанбай авылы зиратының капкасы

Безнең мирас №12 декабрь 2021



Шагыйрь Мифтахетдин Акмулланың Миасс шәһәре зиратына куелган кабер ташы. 1980 ел. *М.Госманов фотосы.*


دملا شهاب الدين حضرتنك مرثيه سى

Дозволено Цензурою. Казань. 1892 г. Октября 17 дня.

Казань, Типо-литографія Университета.

Мифтахетдин Акмулланың үзе исән чакта басылып чыккан бердәнбер китабының – «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе» тышлыгы. – Казан, 1892 ел


آقمللا

افندينك انشاد ايتديكي منظوماتيله،
باشقه بر قلج مشتاقيني، وكنديسينك
ترجمهٔ حاليني مشتمل مجموعه‌در.

Акмулланың 1904 елда Казанда басылып чыккан шигырьләр җыентыгының титул бите (И.Н.Харитонов матбагасы)



Мифтахетдин Акмулланың 1981 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан китабының тышлыгы ■

Мифтахетдин Акмулла шигырьләре

***

Бирелдем мин яшьлегемдә угърылыкка,
Бу очратды мине бик зур ким-хурлыкка...
Нәтиҗәдә, Акмулла дип исем алдым,
Бу исем бүләк булмыш тугърылыкка.

***

Бер үлем мөселманга зурлык кылса,
Тиңлек бар мөселманга хурлык кылса;
Китаб сүзен бозып айткан бозык мулла
Артык чыгар уңдан да, орлык кылса!

***

Һәр җәүһәрнең асыллыгы – алтын ташы,
Берәүнең милиун сумлык кара башы;
Сөягең сөягемдән ким димәймен,
Затыңыз – затымызның сәдакасы!

***

Бер миһман өеңезгә булып китдек,
Җортыңызны аралап күреп китдек;
Кадер белмәк – адәмгә кыен сәүдә, –
Аман-сау исәнләшеп йөреп китдек.

***

Яхшының ләфзы татлы баллы майдан,
Килтерер сүз мәгънәсен әллә кайдан;
Кирелү ут башында киңәш имәс,
Билгеле ир-егетнең булсын мәйдан! ■

Безнең мирас №12 декабрь 2021

Иске Сәфәрдә – китап бәйрәме

Быел 28 августта Актаныш районының Иске Сәфәр авылында төбәк тарихына нисбәтле «Сәфәрем» дигән китапны тәкъдим итү чарасы булып узган иде. Әлеге 618 битле саллы хезмәтне нәшер итүгә бик күп шәхесләрнең өлеше кергән: идея авторы, китапны чыгаруда булышлык итүче – Разил Сәетов, авторлар һәм мөхәррирләр – Рәис Сәетов һәм Инсия Хаҗиева, бизәлеш мөхәррире – Җават Ризаетдинов, компьютерга кертүче – Рәйсә Бәширова, корректор – Ләйсән Әминева.

Иске Сәфәр авылының тамырлары Бүләр ханга, Болгар кабиләләренә барып тоташа. Моны авылда табылган кульязма шәҗәрәләр дә, нәсел тамгалары да раслый.



«Сәфәрем» китабының тышлыгы

«Сәфәрем» китабының мөхәррире, авыл тарихына кагылышлы язмалар авторы Рәис Сәетмөхәммәт улы Сәетовның Иске Сәфәрнең мәдәният йортында урнашкан музейда иске кульязмалар белән танышкан мәле

Иске Сәфәр авылына (Актаныш) нисбәтле стенд

Ләбиб Лерон фотолары

***Дамир ИСХАКОВ,** тарих фәннәре докторы:*

«Авторлар-китап төзүчеләр күптөрле чыганакларга таянганнар. Иң кадерле материалларның берсе булып, билгеле, «Бүләр йорты бабаларының шәҗәрәсе» тора. Шушы шәҗәрәдә күренгән борынгы болгар бабаларының дәвамчылары Актаныш районының Иске Сәфәр авылы кешеләре булып яши.

Китапта күпләгән документлар, фоторәсемнәр, таблицалар тупланган. Алар укучыга тарихи вакыйгаларны еллар буенча, темалар яссылыгында чагыштырырга, өстәмә нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә».

Иске Сәфәр авылына нисбәтле саллы китапны чыгаруда катнашкан шәхесләр мәдәният йорты сәхнәсендә

Иске Сәфәр авылы музеендагы кадерле экспонат – агач тарак ясау станогы

«Сәфәрем» китабын тәкъдим итү чарасына кайткан кунакларны Иске Сәфәр авылы баянчылары каршы алды. Рәсемдә уңнан беренче – Иске Сәфәр авылы мәдәният йорты җитәкчесе Илдус Һарунов. ■

«Безнең мирас» котлый!

Танылган шәхесләребез – галимнәр, язучылар, журналистлар, дин һәм сәнгать әһелләре декабрь аенда үзләренең гомер бәйрәмнәрен билгеләп үтә. Менә алар:

2 декабрь – кинооператор, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Россиянең шәрәфле кинематографисты **Әмир Таһир улы Золондинов**ка 70 яшь (1951);

15 декабрь – шагыйрә **Гөлзада Хаҗи кызы Әхтәмова**га 80 яшь (1941);

13 декабрь – язучы, Г.Державин исемендәге республика премиясе лауреаты **Рөстәм Рәис улы Сабиров**ка 70 яшь (1951);

23 декабрь – актер, Татарстан Республикасының халык артисты **Рамил Гаяз улы Минханов**ка 60 яшь (1961);

26 декабрь – язучы **Әхәт Хафизулла улы Сафиуллин**га 85 яшь (1936).

Олуг затларыбызның барысын да юбилейлары белән ихластан котлыйбыз һәм аларга саулык-сәламәтлек, иминлек, иҗат уңышлары теләп калабыз!

безнең мирас №12 декабрь 2021

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов

Кытай авылы. XX гасыр башы

Буддизм

Өченче һәм дүртенче бүлекләрдә буддизм хакында кайбер мәгълүматлар бирелгән иде. Бу юлы Япониядәге буддизм турында кайбер фикерләрем белән уртаклашырга телим.

Японнарга пәйгамбәр килгәнме икән? *«Без, бер рәсүл җибәргәнчегә кадәр газапламаячакбыз»* (Исра: 15), – дигән бөек аять дәлил булып тора: японнарга да пәйгамбәр килгән. Тик кем, кайчан килгән? Бу безнең өчен билгесез, шуңа күрә, әлбәттә, бу хакта берни әйтә алмыйбыз. Шулай да, фикеребезне белдермичә дә үтмәячәкбез.

Японнарның 2500 елга якын тарихы теркәлгән. Бу вакыт эчендә берәр пәйгамбәр килгәнме-юкмы – японнар моны белми.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

Инде килеп, японнар дин дип кабул иткән буддизм нәрсә икән соң? Кем ул Будда? «Безнең Ислам китапларында бу хакта берни юк», – дип әйтә алабыз.

Бездә, гомумән алганда, дин дип беленгән ислам, христианлык һәм яһүдилек, ягъни иудаизм бар. Болардан башкасына гел «мәҗүси» дибез. Ул мәҗүсиләр арасында ниләр бар? Болар турында һич мәгълүматыбыз юк. Югыйсә хәзерге вакытта дөньяда яшәгән халыкның күпчелеген шулар тәшкил итә. Аларга пәйгамбәрләр җибәрелдеме икән соң? Яисә аларны дингә чакыру кирәкме? Әгәр кирәк икән, кем чакырырга тиеш? Борынгылар болар турында уйламаган. Мөселманнар, нигездә, гафләт эчендә тәгәрәп барганнар һәм әле дә тәгәриләр. *«Синең аша Аллаһның бер кешене һидаяткә ирештерүе синең өчен көтү-көтү кызыл сарыкларыңнан хәерлерәк»,* – дигән изге хәдисне «мондый нәрсә очраса» мәгънәсендә аңлатканнар, «бу юлда иҗтиһад итсәгез, ягъни тырышсагыз, көч куйсагыз» мәгънәсен башларына да китереп карамаганнар.

Икенче яктан: *«(Хәзрәте Мөхәммәд) соңгы пәйгамбәр һәм моннан соң инде пәйгамбәр килмәячәк»,* – дип белдерәбез, диелә. Алай булгач: *«Без бер рәсүл җибәргәнчегә кадәр газапламыйбыз»* (Исра: 15), – дигән бөек аятькә нинди мәгънә бирергә? Безнең голәмә бу хакта фикер йөртергә тиеш дип уйлыйм. Әгәр без уйланмасак, соңыннан безгә бик яхшылап хәтерләтерләр. Болай да динебезнең дошманнары мондый нәрсәләрне гел тикшереп кенә торалар.

Инде биредә мин башта шуны әйтергә телим: Тибетта ламалар өйрәтә торган буддизм башка, Япониядәге буддистлар өйрәтә торган буддизм башка. Күп кенә яктан хәтта берсенең икенчесе белән һич кенә дә бәйләнеше юк кебек. Бигрәк тә гамәли нәрсәләрдә бик зур аермалар бар. Гыйбадәтләрендә дә, потханәләрендә дә бик зур аерма булуы күренә. Хәтта диннең нигезе дә бер үк түгел. Мәсәлән, Тибет ламаларының инанулары болай: «Табынырга лаеклы бер зат була, аны эзләргә кирәк, колның вазыйфасы – аны эзләү». Моңа тәүхид дип әйтергә була. Пот табу, потлы булу – таләпләрендә булган хаталары ул. Ислам голәмәсе моны төзәтсә, бик төз юлга салыначагын өмет итәргә була.

Япон буддистлары илаһилекне инкяр итәләр. Әмма могҗизаларны раслап, үзеннән берәр могҗиза барлыкка килгән кешене шунда ук илаһи зат дип саныйлар. Могҗизалары да без белгән нәрсәләр түгел, элек булмаган берәр нәрсә уйлап табып, аны бар халыкка кабул иттерү дә бер могҗиза булып санала. Менә Микадоның илаһилеге дә шулай барлыкка килгән. Башта: «Аерым булган милләтләрне бергә җыйган, димәк, куәте бар. Менә шул куәт илаһилек кодрәте инде», – диләр. Боларда да кодрәтле дип тану бар. Кеше мөмкинлекләреннән өстен берәр нәрсә булса, ул табынырга лаеклы дип таныла. Һиндстанда брахманың да һәр яңалыкка илаһилек бирүе шушы ук мәгънәдә дип уйлыйм. Борынгы заманнардан бирле брахма сихерчеләрнең илаһилеген таный торган булган. Бу соңгы вакытларда хәтта телеграфны, телефонны, поездны да илаһи дип саный башлаганнар.

Боларның бөтенесен игътибарга алып яхшылап уйлансаң, Имам Газали әйткәнчә, максат гел бер үк, хаталар бары тик таләптә генә булып тоела.

Менә шуларны исәпкә алып, мин Япониядә дин мәсьәләсенә бераз артыграк та әһәмият бирдем һәм моңа бик күп япон шәхесләренең игътибарын җәлеп иттем. Акыл ияләренә боларны сөйләп-аңлатып бирүгә үк, кызыксынуларын күреп ала идем.

Омихара белән күрешү

Омихара – японнарның дини рәисләренең берсе. Мин бу кеше белән башта очраклы гына танышкан идем, аннан соң күп тапкырлар күрешеп сөйләштек, арабызда дуслык-якынлык хасил булды. Беркөнне әңгәмәбез арасында ул миңа болай диде: «Буддизм бүгенге көндә нигезен югалткан. Бигрәк тә безнең Японниядә динне тәмам чыгырыннан чыгарганнар. Бездә илаһи затлар шулкадәр күбәйгән ки, санап бетерерлек түгел. 50 елдан соң Принц Ито да, Може̇хито да илаһ булачаклар. Боларны уйлап, чымырдап куям. Сез биредә бераз озаграк калсагыз, бу дин мәсьәләсен ныклы бер нигезгә утыртыр идек. Бүгенге көндә минем ун меңнән артык фикердәшем бар, мин ни дисәм дә: «Яхшы, шулай булсын!» – дип кабул итәчәкләр. Мин, гомумән, үземнән күбрәк алар өчен борчылам. Шулкадәр кеше үзләрен минем вөҗданыма ышанып тапшырганнар. Ә мин үзем дә икеләнеп кабул иткән динне ничек итеп башкаларга «хак дин» дип тәкъдим итим, инандырыйм, нәсыйхәт бирим?! Боларны уйлап, минем вөҗданым бик газаплана».

Менә карагыз сез бу хәлгә һәм бу вөҗданга! Үзе уйланып, үзе борчылып, вөҗдан җаваплылыгы хис итә.

Мин бу шәхес белән бик самими аралаша идем. Беркөнне Токио шәһәрендәге Кандабаши дигән җирдә оештырыласы бер конференциягә мине чакырып, дин һәм милли әхлак турында бераз булса да мәгълүмат бирүемне үтенде. Ул көннәрдә минем башка очрашуларым да бар иде, шул сәбәпле бу конференцияне бераз күчереп торуларын сораган идем дә вакытын күчергәннәр иде.

Сарай министры Хиҗиката җәнаплары белән күрешү

Хиҗиката – император сарае министры һәм императорның бик күптәнге дусты булганга, гаять мәгълүматлы һәм «Японниянең аяклы тарихы» дип аталырга лаеклы шәхес. Бу мөхтәрәм зат белән дә берничә тапкыр күрештем, Дәүләт йортында кунакта да булдым, үзеннән шактый бай мәгълүмат алдым. Бу шәхес, Японниянең бик күптәнге дәүләт кешесе булуы белән бергә, япон милләтенең иң бөек хезмәткәре дә иде. Моннан тыш, Микадо җәнаплары шәхсән бу кешенең өенә килеп кунак булган, Микадоның дусты икән.

Микадо җәнаплары үз халкы арасыннан бу кешедән башка берәүнең дә өендә кунак булмаган, шуңа күрә дә әлеге шәхеснең япон халкы арасында үзенә аерым бер урыны бар.

Беркөнне дәүләт йортында бу шәхес белән күрештем, кунак булдым. Башта ул мине Аурупа ысулында кабул итте. Аурупадан килгән кунаклар өчен билгеләнгән бүлмәдә бер 15 минутлап утырдык. Берәр чынаяк чәй эчкәннән соң, Хиҗиката җәнаплары миңа болай диде: «Мин рәсмилекне үтәдем. Безнең бу бүлмә Аурупадан килгән кунаклар өчен. Рөхсәт итсәгез, үзебезнең залга күчик, анда озаклап сөйләшеп утырырбыз. Бакчада да йөрербез».

Аурупа ысулы белән әзерләнгән бүлмәне калдырып, бакча уртасындагы кечкенә генә япон өенә килдек.

Монда җиһаз дип әйтерлек бер мангал һәм утырыр өчен ике-өч миндәр генә бар иде. Өй эче иң фәкыйрь бер японның өеннән берни белән дә аерылмый, шулкадәр гади иде.

Бирегә килеп җитүгә, Хиҗиката җәнаплары болай диде: «Гафу итегез, без балачактан биредә яшәдек, үстек, тәрбияләндек һәм башка җирдә үзебезне рәхәт хис

итә алмыйбыз. Шуңа күрә Сезне, ардырып, монда кадәр алып килдем. Без Сезнең белән – Көнчыгыш халыклары, әңгәмәбезне дә Көнчыгыш ысулында корыйк».

Японнар, гомумән, күп уйлый, аз сөйләшә торган милләт. Бервакытта да уйламыйча сүз сөйләмәсләр, шаян сүз әйтергә уйлаганда да, япон кешесе башта уйлар, аннары гына әйтер. Хиҗиката җәнаплары японнар арасында бик күп уйланучы, фикер йөртүче булуы белән танылган. Йөзенә игътибар белән карасагыз, фикер кешесе икәне аңлашыла. Сөйләшкәндә өздереп-өздереп сөйли, сүзләрен тулысынча аңлап барырга мөмкин, чөнки сөйләгәндә дә уйлый-уйлый сөйли.

Игътибарыгызга бу мөхтәрәм зат белән өендә утырганда арабызда булып үткән сөйләшүне тәкъдим итәм.

Хиҗиката җәнаплары өйгә кергәндә миңа болай диде:

– Үз гомеремдә бер генә тапкыр да Русия эчендә яшәгән татарларны күргәнем булмады, менә беренче тапкыр Сезне күрәм. Тик татар тарихын күп укыдым, элек-электән татарларга карата аерым бер мәхәббәт хисем бар. Бигрәк тә Тимурга олы ихтирамым бар. Ул кеше – җир шарындагы иң бөек кешеләрнең дә иң бөеге. Шул нәселдән бер кешенең минем өемдә кунак булуы һичбер вакыт онытылмаячак вакыйга, истәлек булачак. Мине бәхетле иттегез, бик рәхмәтлемен. Мин заманыбыз татарлары турында берни белмим, тик өмет итәм: үткәне бөек булган милләтнең киләчәге дә бөек булачак. Бик нык өшәнгәннән соң бер торгынлык чоры килә – зыян юк, арыслан ул һәрвакыт арыслан. «Зынҗырга төшү арысланга гарь түгел», – диләр. Хәзер мин Сездән татарларның бүгене һәм киләчәге турында бераз мәгълүмат бирүегезне сорыйм, Русиядә татарларның саны бик күптер, шулаймы?

– Русиядә татарларның саны бик күп, утыз миллионга якын дип санала. Ләкин озакка сузылган әсирлектән, золым һәм тиранлыктан бик нык яньчелгәннәр. Урыслар татарларга сулыш алырга да мөмкинлек бирмәгәннәр. Белем һәм мәгарифтән



Император сарае. Пекин. XX гасыр башы

мәхрүм итәр өчен кулларыннан килгәннең барысын да эшләгәннәр. Үзләрен бетерергә тырышканда, табигый сәләтләрен дә бетәр дәрәҗәгә китергәннәр, өмет тудырачак берни калдырмаганнар. Тик татарларга өметсезлек килмәгән, табигый эшчәнлекләре элеккечә үк диярлек дәвам итә. Шулай бара торгач, әгәр күңел төшенкелеге килмәсә, тырышыр-тырмашыр, киләчәктә үзен тагын бер тапкыр исбатлар. Әлбәттә, урыслар да тырышачаклар, тезгенне кулларыннан ычкындырырга теләмәячәкләр.

– Кеше бар нәрсәне дә аулый ала, тик арысланның вазыйфасы зынҗырны өзү. *(Елмаеп куйды.)* Русиядәге татарларның тормышлары ничек бара? Бай, чиндәрәҗәсе булган, җитештерү җитәкләгән татарлар бармы? Думада күпме татар вәкилегез бар?

– Гомумән алганда, татарлар ярлы-фәкыйрь. Тик тормыш итү рәвешләрендә электән килгән үзенчәлекләрен саклаганнар һәм саклыйлар. Татар авылына читтән карасаң, аның татар авылы икәнлеге шунда ук аңлашыла. Урыс авылларына бөтенләй охшамаган. Өй эчендә дә, иң ярлы татар кешесенең өендә иң бай урыс кешесенең өендә булган кадәр арулык була. Кыскасы, тормыш-көнкүреш, гадәт һәм әхлак ягыннан һич кенә дә җиңелгәннәр дип әйтеп булмый. Мөселманнар сан ягыннан шактый күп булган төбәкләрдә, саннары урыслар кадәр үк булмаса да, бик күп яктан урыс үзе татарга җиңелгән дип әйтеп була. Уфа, Казан якларында татарлар рус телен белмиләр, киресенчә, руслар татарча өйрәнгәннәр һәм татарча бик яхшы сөйләшәләр. Әйе, беренче карашка, татарларның рус телен белмәүләре зур кимчелек, тик әйләнә-тирәдәгеләрне үз телләрендә сөйләшергә мәҗбүр итү, әлбәттә, җиңү көче булып тора. Кайбер төбәкләрдә хәтта урыс халкының зур бер өлеше үз гаиләсе эчендә дә татарча сөйләшә. Кыргыз далаларында татар теле җәелгән. Моннан соң ел үткән саен татар теле киңәячәк һәм киңәя бара. Кайбер җирләрдә

бу телнең йогынтысы астында исламга килүчеләр дә бик күп. Байлык һәм дәрәҗә ияләренә килсәк, кызганыч, болар бик аз. Капитал ияләре бөтенләй юк дияргә мөмкин. Берничә фабрика тотучылар, берничә миллионы булган сәүдәгәрләр бар. Моңа ирешкәннән соң, сәүдә идарәсендә үз сүзләрен тыңлата ала торган булалар. Чин-дәрәҗә ияләре бөтенләй юк, дисәм дә, дөрес булыр. Дөресен генә әйткәндә, була да алмый, чөнки Русия хөкүмәтенең кануны моңа рөхсәт итми. Хәрби хезмәттә булса, иң зур дигән чины – полковник. Паша дәрәҗәсендәге иң зур хәрби чинга ирешә калса, шунда ук лаеклы ялга озаталар. Җәмгыять тормышында ирешә алачак иң зур дәрәҗәсе – прокурор. Шуннан да югары күтәрелә алмый, күтәрелә калса, лаеклы ялны сайларга мәҗбүр калачак. Дәүләт кануннары шундый. Шуның белән бергә, татарларның үзләрендә дә ул кадәр чин-дәрәҗә һәвәсе юк.

– Татарларның хәлләре һәм холык-табигатьләре турында әллә ни белмәсәм дә, офицерларыбыздан ишеткәнем бар: рус-кытай сугышында да, рус-япон сугышында да сугыш кырларында татар сугышчыларының файдалары күп булган. Рус хәрби отрядларында татар кешеләре сугышчанлыклары белән шөһрәт казанган, сугышта һәрвакыт кыю хәрәкәт иткәннәр. Шулай булгач, бу куәтне, бер вакыты килеп, үз милләте мәнфәгатендә сарыф итәргә теләсә, кыска гына вакыт эчендә гаять зур уңышларга ирешәчәге шик тудырмый. Билгеле булганча, әсирлек рухи яшәешкә тәэсир итсә, ул милләттән киләчәк өмет ителә алмый. Менә мисал. Тагын да шул ук кытайлар белән булган сугышта Һиндстан гаскәре дә бар икән. Атланган атлары сөлек кебек, корал-фәләннәре дә искиткеч, киемнәре яхшы, башларында исең китәрлек чалмалар, тик сугышның кайсы җиреннән генә керсәләр дә, күп дигәндә ике-өч сәгать каршылык күрсәтә алалар икән. Биш сәгать буе сугышканнары бик сирәк булган, шунда ук чигенәләр икән. Моны безнең сугышчыларыбыз һәм офицерларыбыз алар белән бергә булган вакытларында сынаганнар.

– Әйе, ул яктан татар сугышчысы һәрвакыт өстенлек казанган. Башка сугышларда да күп тапкырлар сыналган. Татарлар, һичшиксез, табигый яратылышлары белән сугышчан милләт. Моны беркем дә инкяр итә алмас. Әмма золым күреп бик яньчелгәннәр. Шулай булса да, өметебезне өзмәячәкбез.

– Татарларда уку-язу һәвәсе ничек? Уку һәм язу сәнгате дә олы киләчәк дигән сүз.

– Бу яктан да урыслардан күп тапкырлар өстен торалар. Моннан 20-30 ел элек уку-язу бик артта калган иде. Әмма бу елларда мәктәп саны бик күпкә артты һәм әле дә арта бара. Мәктәбе булмаган авыл бик аз калыр. Урыста исә хөкүмәт ачкан мәктәпләр генә бар, халык тарафыннан ачылган бер генә мәктәп тә юк.

– Бу – күңелгә хуш килә торган, бик матур һәм зур өмет. Безнең Япониядә алга китүнең иң беренче чарасы да бу булды. 6 ел мәҗбүри белем канун белән ныгытылгач, шул көннән башлап мәдәният һәм алга баруның нигезләре салынды. Милләтнең акылы да әлеге нәрсәне аңлап алды, шул көннән башлап нәтиҗәләре күренә башлады. Ул хәлдә татарлар урысларның җаһиллегеннән файдалана белсәләр, алга китеш булыр. Бигрәк тә Госманлы төрекләре дә тәрәккъый итсәләр, татарлар өчен ныклы арка булырлар. Татарларның тиешле хокукларын саклаганнан соң, Русияне дәвамлы тикшерү, шүрләтү астында тота алырлар. Минем фикеремчә, төрекләр дә күп файда күрерләр, бигрәк тә Балкан мәсьәләсендә уңайлык туар. Руслар христианлык, славянлык хакына Госманлы хөкүмәтенә даими рәвештә һөҗүм итеп торалар. Без бу мәсьәлә турында үз арабызда гел сөйләшәбез, ләкин хәлнең чын дөресен белми идек. Бары шундый бер фикер килә иде башка: татарларның төрекләр белән бер үк тамырдан булуларын һәм диннәре дә уртак

булуны исәпкә алып, бервакыт кардәше белән кулга-кул тотынышып, мәйдан уртасына чыкмаслармы?

– Һич шик юк, төрекләр белән татарларның бер үк тамырдан, бер үк нәселдән булулары, уртак дин тотулары зур өмет уята. XX гасырда раса мәсьәләсе дә гаять зур мәсьәләгә әйләнде. Шул ук вакытта Көнчыгыш мәсьәләсен дә игътибарга алганга күрә, без япон халкының да үзебезгә таяныч була алачакларына өмет итәбез. Ник дигәндә, бу хәлдә иң мөһим мәсьәлә булып яшәү мәсьәләсе тора һәм ул яктан безнең японнар белән бәйләнешебез булачак. Аурупалылар үз яшәешләрен безнең һәлакәтебездән эзләгән кебек, японнарның да бүгенге яшәешләренең шулай дәвам итеп китүен бик теләмиләр. Менә шул яктан сезнең белән дә берләшә алуыбыз мөмкин булып күренә.

– Гомумән дә, бер кавем булуыбыз мотлактыр, мәнфәгатебез һич берләшмәсә дә, үзебез берләшә алырбыз. Бу теләк татарларда булган кадәр, японнарда да булачак. Япон кешесе һичбер вакыт татар кешесен рус белән бер итеп күрмәс, йөрәгендә аларга карата дәвамлы яратмау, кабул итмәү хисе яшәткән кебек, татарларга карата йөрәгендә мәхәббәт яшәтер. Мин бик күп рус кешесе белән күрешеп сөйләштем, дәүләт йортыбызга рәсми күрешүгә килгәннәр күп булды. Тик мин аларның берсен генә дә менә шушы өемә алып килмәдем. Сезнең белән беренче күрешүдә үк сөйләшүебезнең бу рәвешле самими була алуын рухи бәйләнешебез булганга дип уйлыйм.

Чәйләр эчтек, җиләк-җимешләр ашадык. Хиҗиката җәнаплары болай диде:

– Бакчабызны да күрергә теләсәгез, әйдәгез, бераз бакчада йөрик. Безнең бакчабызның Япониядә тиңе юк. Мин бакчага элек-электән агачларның һәм җимеш куакларының бөтен төрләрен утырттым һәм ничек бар, шулай калдырдым. Өстәмә карау, тәрбия бирмичә, табигатьнең үз тәрбиясенә тапшырдым. Монда үзгә бер матурлык бар.

Бакчага чыктык, йөрибез. Хиҗиката җәнаплары сүзен дәвам итте:

– Игътибар итегезче, биредә кеше кулы белән матурайтылган бер генә агач та юк. Мин болар белән тәҗрибә үткәрдем: кискечләр, кайчылар белән бирелгән матурлык агачларны озак яшәтми, җимешләрнең табигый тәменә зыян китерә. Табигатькә тыкшынып тәрбия бирүнең тискәре йогынтысы аркасында агачларның гомере дә кыскара. Безнең күршедә финанслар министрының бакчасы бар. Бакча караучылар тота, болар бакчаны бик нык тырышып карыйлар-тәрбиялиләр, ләкин җимешләрендә минем бакча җимешләремдә булган кадәр тәм-ләззәт юк. Моҗохито Тенси Сама – бик табигать яратучы кеше, мин бәндәгезнең бу өенә кунакка килгәч, бөтен бакчаны карап йөрде. Аннары менә шунда килеп утырды, аның хөрмәтенә, ядкяр дә булсын дип, әнә теге ташны куйдырдым, күрәсезме? *(Биредә дүрт аршын биеклегендә таш утыртылган иде.)* Ул да: «Синең бакчаңдагы матурлык безнең бакчаларыбызда юк», – дигән иде. Бу сүзләрне шул ташка чокып яздырттым. Телисезме, бирегә җиләк-җимеш китерсеннәр, Сез дә биредә бераз ял итеп алыгыз. Моҗохито да менә шушында утырып җиләк-җимеш ашаган иде.

Бик зур горурлык белән шунда утырып, бераз бакча җимешләре ашадым. «Бик күркәм истәлек булды. Фотограф та чакыртыйм әле, безне биредә рәсемгә төшерсен», – дип, чакырырга кеше җибәргән иде, ләкин ни кызганыч, фотограф килә алмады, аннан соңгы вакытларда да җае чыкмады.

Хиҗиката җәнаплары белән күңелгә хуш килә торган шундый күрешеп сөйләшүдән соң, саубуллашып китеп бардым.

*Төрекчәдән **Асия Рәхимова** тәрҗемәсе* ■

Безнең мирас №12 декабрь 2021

«Тәбәнәк Бохаралы»ның бөек эшләре

Ильяс Җиһаншин

Профессор Наил ага Таиров, Мөхәммәдсадыйк Галикәевнең оныгы Динә ханым Сакаева һәм атаклы Әҗемовлар нәселеннән профессор Йосыф ага Әҗемов Яңа Татар бистәсе зиратының карта-схемасын карыйлар. 2018 ел

Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе 1998 елдан бирле Ал мәчет һәм элекке тарихи 10 нчы мәхәлләдәге «Якубия» мәдрәсәсе гөрләп эшләгән биналарда шәкертләргә тәрбия һәм гыйлем бирә. Кайбер рәсми чыганакларда бу мәчетнең икенче исеме – «Зират яны мәчете». Анда Хәмит һәм Мөхәммәд хәзрәт Мортазиннар, Шаһиәхмәт хәзрәт Иманколов, Габделкаюм һәм Мөхәммәдгабдулла хәзрәт Габделбадыйковлар, Салихҗан хәзрәт Галиев кебек иң алдынгы мөдәррисләр гыйлем биргән. Мәчет вә мәдрәсәдәге эчке тормышны Муса Апанаев, Мөхәммәдҗан Галиев, Мөхәммәдсадыйк Галикәев кебек шәрәфле затлар карап-тикшереп торган. Тарихыбызда үзенчәлекле урын тоткан Яңа Татар бистәсенең, аның зиратының да мәдрәсәбезгә бәйләнеше бик зур.

Хәсәнҗан хәзрәт Әхмәровның туганнары Галиевләр нәселе каберлеген зиярәт кылалар. 2018 ел

Шуңа күрә дә, шәкертләр белән берлектә, татар зыялыларының каберләрен барлауны, зираттагы ташларны өйрәнү, анда өмә ясап җыештыру эшләрен даими башкара-

٥٨١- عن بُرَيْدَة -رضي اللَّه عنه-، قَالَ: قَالَ رسول اللَّه صلى الله عليه وسلم:

﴿كُنْتُ نَهَيْتُكُمْ عن زِيَارَةِ القُبُورِ فَزُورُوها﴾ رواه مسلم.

وفي رواية: ﴿فَمَنْ أَرَادَ أَنْ يَزُورَ القُبُورَ فَلْيَزُرْ؛ فَإِنَّهَا تُذَكِّرُنَا الآخِرَةَ﴾.

Мөхәммәд (с.г.в) әйтә: «Мин сезне каберләрне зиярәт кылудан тыйган идем, хәзер аларны зиярәт кылыгыз. Чөнки алар сезгә дөньяга бирелмичә яшәргә ярдәм итә һәм ахирәтне искә төшерәләр».

быз, каберләрнең өсләрен чистартып, дога кылып кайтабыз. Шул ук вакытта күренекле дин әһелләренең, мәдәният һәм фән эшлеклеләренең, сәүдәгәр һәм эшкуарларның каберләрен табу, торгызу һәм теркәү бурычын да алга куйдык. Тупланган мәгълүматны картага төшердек, чөнки зиратта кемнең кайда җирләнгәнен бик азлар гына белә иде. Бу эштә безгә галимнәребез Марсель ага Әхмәтҗанов, Наил ага Таиров һәм Яңа Татар бистәсе зираты мәчете имамы Роберт хәзрәт Вәлиев зур ярдәм күрсәтте. Яңа Татар бистәсе зиратында Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты өлкән фәнни хезмәткәре Айдар Гайнетдинов белән берлектә дә эзләнү эшләре алып бардык. Хәзер каләм әһелләреннән Ләбиб кардәшебез Лерон да язучыларыбызның каберләрен барлауда зур тырышлык куя. Аларга Аллаһының рәхмәтләре булса иде.

Дин әһелләре яңадан торгызылган Шәйхелислам хәзрәт Хәмиди каберен зиярәт кылалар. 2019 ел

Соңгы елларда гына да Мөхәммәдсадыйк Галикәев, Шәйхелислам Хәмиди кебек дистәдән артык мәшһүр шәхесләрнең каберләре тәгаенләнде, мәрхүмнәрнең баш очларында Коръән укып дога кылынды. 2020 елда 10 нчы мәхәллә мәчетенең имамнары – «Якубия» мәдрәсәсенең мөдәррисләре булып торган Шаһиәхмәт хәзрәт Иманколов һәм Габделкаюм хәзрәт Габделбадыйков каберләре һәм кабер ташлары табылды.

Шаһиәхмәт Иманколов: Мәрҗани белән бәхәскә кергән

Шаһиәхмәт хәзрәт Иманколов (1803-1878) – Яңа Татар бистәсенең «Тәбәнәк Бохаралы» дип аталган 10 нчы җамигъ мәчетнең имам-хатыйбы, мәдрәсә мөдәррисе

булып 1834-1877 нче елларда хезмәт итә. Шакирҗан Хәмидинең «Голяма тарихы» китабында Шаһиәхмәт хәзрәтнең ата-бабалары хәзерге Татарстанның Әтнә районындагы Мамыш авылыннан икәнлеге әйтелә. Казан төбәге мәдрәсәләрендә гыйлем җыеп, Бохарага укырга китә ул. 1834 елда Бохарадан кайтып, Кышкар имамы, мәшһүр мөдәррис Фәиз бине Габделгазиз кызы Газизәгә өйләнә. Каенатасы Фәиз – Каюм Насыйриның әнисе ягыннан бабасы, Габденнасыйр Курсави каенатасы С.Шорданиның энесе була.

Шаһиәхмәт хәзрәт 1834 елда Яңа Татар бистәсендәге 10 нчы җәмигъ мәчетенең имам-хатыйбы итеп билгеләнә. Ул укымышлы хәзрәт була, мәдрәсәдә укыту белән шөгыльләнә. Шаһиәхмәт Иманколов 1860 елның 11 сентябрендә Диния нәзарәте тарафыннан Казанда Коръән басмаларын тикшерүче итеп билгеләнә. Ул ике тапкыр – 1858 һәм 1870 нче елларда хаҗга барган. Замандашлары аны хаҗ сәфәрләреннән алып кайткан бай китапханә җыючы дип атыйлар. Имам үзе дә берничә әсәрнең авторы буларак мәгълүм. Мәсәлән, ул – Шиһабетдин Мәрҗанинең «Нәзурат әл-хак» китабына җавап итеп язылган һәм күп бәхәсләр уяткан «Җәрүдә» китабының авторы.

Шаһиәхмәт хәзрәт Иманколовның табылып, өлешчә яңартылган кабер ташы. 2021 ел

Шаһиәхмәт хәзрәт 1870 елны Тәтеш өязенең Яңа Сала авылы (хәзер Кама Тамагы районына карый) мулласы Закир хәзрәт Халидиның кызы Нәфисәгә өйләнә. Бу аның икенче хатыны була. Менә шул никахтан инде 1870 елның 10 сентяберендә булачак шагыйрь, мәшһүр галим, «Тәсһилүл бәйән фи тәфсирел-Куръән» авторы Мөхәммәдсадыйк дөньяга килә.

Ил алдындагы хезмәтләре өчен Шаһиәхмәт хәзрәткә «Мактаулы гражданин» исеме бирелә. Шунысы кызганыч: ул гомер азагында гаиләсенә мирас калдыра алмый, 1878 елның 1 июнендә вафат була. Гаиләсе бөлгенлеккә төшә, булган милекләре бурычларын түләү өчен тотыла.

Мәрхүмнең кабере 23 нче аллеядан кергәч, уң яктагы 21 нче участокта урнашкан. Без тапканда кабер ташының өске өлеше ярылган һәм ул ауган, игътибарсыз, караусыз хәлдә иде. 2021 елда кабер ташы заманында үзе хезмәт иткән Ал мәчетнең җитәкчеләре тарафыннан торгызылды. Аны яңа фундаментка утыртырга, нигезен ныгытырга туры килде. Кызганыч, ташның өске фрагментының бер өлеше югалган.

Габделкаюм Габделбадыйков. Цензурага каршылык күрсәткән зат ул

1879 елда мәхәллә халкы Габделкаюм Габделбадыйковны (1838-1906) имам итеп сайлап куя. Аңа кадәр ул хәзерге Әтнә районындагы Олы Бәрәзә авылында имам вазыйфасын башкара. Аның ата-бабалары чыгышы белән Кайбыч районын-

дагы Олы Урсак авылыннан. Габделкаюм хәзрәт тә заманы өчен иң укымышлы руханилардан саналган, Казан мөселманнарының иҗтимагый тормышында актив катнашкан, Казан ахуны вазыйфасын башкарган. Россия империясе Халык мәгарифе министрлыгының мәдрәсәләрдә цензура үткән китапларны гына кулланырга ярый дигән циркулярына актив каршылык күрсәткән зат ул. Габделкаюм хәзрәт хакындагы мәгълүматны без «Якубия» мәдрәсәсе шәкерте Хәсәнҗан хәзрәт Әхмәровның истәлекләреннән укып беләбез: *«Булып үткән остазларымның һәм дусларымның кемнәр булуын язып үтүне тиеш күрәм. Беренче остазым Яңа бистәнең дәмелла Салихҗан Галиев, Габделкаюм хәзрәт Бәдигый, дәмелла Галимҗан Баруди...»* Ул Каюм хәзрәтнең холкын күркәм, ачык йөзле адәм итеп тасвирлый, хәзрәтнең гыйлеме тирәнлеге, шәкертләргә матур мөнәсәбәте турында яза.

2020 елда аның 19 нчы аллеядан кергәндә уң якта, 19 нчы участокта урнашкан каберен тапканда, ташы бөтенләй диярлек җиргә батып тигезләнеп беткән иде. Ташны, Роберт хәзрәт Вәлиев җитәкчелегендә, белгечләр казып чыгарды. Өч-дүрт кисәккә ярылган таш ябыштырылып төзекләндерелде, махсус состав белән эшкәртелде. Шулай итеп, кабер ташы 2021 елда Ал мәчет иганәчеләре һәм мәдрәсәбезнең остазы Зөлфәт хәзрәт Мингалиев гаиләсенең ярдәме белән торгызылды.

Габделкаюм хәзрәт Габделбадыйковның кабер ташы табылган чор. 2019 ел

Габделкаюм хәзрәт Габделбадыйковның яңартылган кабер ташы. 2021 ел

Салихҗан хәзрәт астрономия белән кызыксынган

Мәчетебезнең тагын бер имамы Салихҗан хәзрәт Галиевнең (1862-1931) кабере «Иске юл» аллеясының уң ягындагы 13 нче участокта Галиевләр нәселе каберлегендә урнашкан. Ул 1890 елда мәхәлләгә имам, мәдрәсәнең икенче бүлегенә мөдәррис итеп билгеләнгән һәм, Габделкаюм хәзрәт белән берлектә, мәдрәсәдә ысулы җәдит белән белем бирү тәртипләрен урнаштырган.

Салихҗан хәзрәт – фәнни гыйлемнәрне туплаган берничә китап авторы. Мәсәлән, «Фәтх-әт-тәҗвид» китабы (1892) Коръәнне дөрес уку турында. Аның тексты «Бәдәвам» үлчәмендә шигырь белән татарча язылган. Бу китапны хәзерге әдәби телгә күчерүче, безнең мәдрәсә остазы Җәгъфәр хәзрәт Мөбарәк (1940-2020) булды. Салихҗан хәзрәт астрономия белән дә кызыксынган. Аның бу фән буенча фәнни-

Салихҗан Галиевнең кабер ташы

популяр китабы «Әл-гыйльмел-мансур фил-гамәли бәробгыль-дәстүр» дип атала. Ул шәкертләргә дә астрономия нигезләре буенча дәресләр биреп, аларда зур кызыксыну уяткан. Салихҗан хәзрәт, абыйсы Галимҗан хәзрәт Баруди үрнәгендә, мәдрәсәдә белем бирүгә шактый үзгәрешләр кертә, дөньяви фәннәр укыта башлый. Үзе дә тирән гыйлемле зат буларак, хәзрәт дәрес бирүгә иҗат эше итеп карый, уку-укытуга багышланган методик кулланмалар яза. Салихҗан хәзрәт киң холыклы, бала җанлы, ачык чырайлы кеше була. Аның турында Җәвад Тәрҗеманов үзенең истәлекләрендә: *«Ул вакытта Фатих абый Әмирхан коляскада йөри һәм без аны Мөхәммәд һәм Мәхмүд Галиевләр кебек искиткеч педагогларның әтисе, Яңа бистәнең Ал мәчете имамы Салихҗан хәзрәтнең алмагач бакчасына йөрттек. Ул шат йөзле генә түгел, көр күңелле дә иде»,* – дип әйтә.

Мөхәммәдсадыйк Галикәев унлап мәчет төзетә

Заманында Ш.Мәрҗани хәзрәтләренең ярдәмчесе, беренче гильдия сәүдәгәр Мөхәммәдсадыйк Мөхәммәдсафа улы Галикәев (1847-1919) тарафыннан 1905-1906 нчы елларда безнең мәчет бинасы киңәйтелеп, шул ук нигезне өлешчә кулланып, өр-яңадан, кызыл кирпечтән ике катлы итеп салына.

Галикәевләр моннан тыш та Казанда бик күп игелекле эшләр башкара. М.Галикәев мануфактура белән сату итә, 1897-1917 нче елларда Казан шәһәр Думасы гласные, Казан шәһәре җәмәгать банкының исәп-хисап комитеты һәм Казан шәһәре мөселманнарының хәйрия җәмгыяте әгъзасы була. Ул унлап мәчет төзелешенә ярдәм итә, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең яңа бинасын коруга һәм мәдрәсәләр тотуга акчалата иганә кыла.

Мөхәммәдсадыйк Мөхәммәдсафа улы Галикәевнең кабер ташы

Мөхәммәдсадыйк Галикәевнең кабере «Иске юл» аллеясының сул ягындагы 17 нче участокта, күренекле имамнар – Әмирханнар каберлеге артында урнашкан. Без эзләп тапканда таш, фундаменты таркалу аркасында, йөзтүбән ауган иде. Ташны беренче мәл бастырып-турайтып куйдык. Ул бик уңайлы укыла, сыйфаты да яхшы дәрәҗәдә сакланган иде. Аллаһының рәхмәте, бу олуг шәхеснең оныгы – Санкт-Петербургта яшәүче Динә ханым Сакаева белән элемтәгә кердек. Алар иске кабер ташын асылдагы хәлгә китереп төзекләндерделәр. Шул вакытта кабер ташына язучы каллиграфның да исеме мәгълүм булды.

***

Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» хезмәтендә язылганча, мәхәлләбезнең икенче имамы Мөхәммәд хәзрәт Мортазин да Яңа Татар бистәсе зиратында җирләнгән. Беренче имамыбыз Хәмит хәзрәт Әлдермеш авылы янында күмелгән, дигән мәгълүматлар да кулыбызга керде. Аларның каберләрен эзләүне дәвам итәбез. ■

безнең мирас №12 декабрь 2021

Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре*

Әхмәдвәли Рәхими

1

Габдулла бине Гомәр разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәссәлам әйткән: «Ислам дине биш нигезгә корылган: «Ләә иләәһә илләллааһу Мухәммәдүр рәсүлуллаһ» («Аллаһтан башка иләһ юк һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәссәлам Аллаһның бәндәсе һәм рәсүле»), – дип шәһадәт бирү; намаз уку; зәкят бирү; рамазан аенда ураза тоту; хаҗ кылу».

Укы һәм исеңдә калдыр!

2

Габдулла бине Гомәр разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәссәлам әйткән: «Чын мөселман – аның теленнән һәм кулыннан башка мөселманнар сәламәт булган кеше; мөһаҗир – Аллаһ тыйган нәрсәләрдән күчкән (киткән) кеше».

Укы һәм исеңдә калдыр!

3

Әнәс разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәссәлам әйткән: «Сезнең һичберегез камил мөэмин булмас, мин аңа атасыннан, баласыннан һәм барча кешеләрдән сөеклерәк булганчы».

Укы һәм исеңдә калдыр!

4

Габбас бине Габделмотталиб разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәссәлам әйткән: «Кем Раббы буларак – Аллаһтан, дин буларак – исламнан, рәсүл буларак – Мөхәммәдтән (салләллаһу галәйһи вәссәлам) разый булса, ул кеше иман ләззәтен (тәмен) татыды».

Укы һәм исеңдә калдыр!

5

Суфьян бине Габдулла Сәкафи разыйаллаһу ганһү әйткән: «Бервакыт мин: «Әй, Аллаһның илчесе, миңа ислам турында синнән соң башка беркемнән дә сорамаслык сүзләр әйт», – дип сорадым. Ул: «Аллаһка иман китердем дип әйт тә шәригатьтә тугры тор», – дип җавап бирде.

Укы һәм исеңдә калдыр!

6

Гобадә бине Самит разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәссәламнең болай дип әйткәнен ишеттем: «Кем: «Ләә иләәһә илләллааһу Мөхәммәдүр рәсүлуллаһ», – дип шәһадәт бирсә, Аллаһ аңа утны (утка табынуны) хәрам кылыр». ■

*Хәдисләр Шәех әл-Камил Вәли әд-Динмөхәммәд бине Габделхатыйб әт-Тәбризинең «Мишкәтуль мәсабих» китабы буенча әзерләнгән һәм 1913 елда 3 китапта басылып чыккан.

*Текстны басмага **Айсылу Вәлиева** әзерләде.* ■

Безнең мирас №12 декабрь 2021

САБЫЙЛАР ӨЧЕН ДИНИ МИРАС

Дин дәресләре

Сөнгатулла Бикбулат

Алтынчы дәрес

Рух. Гөнаһ. Изге гамәл. Әҗер вә савап. Җәза вә газап

Мөгаллим: Бездә бер гәүдә генәме, әллә гәүдәдән башка да берәр нәрсә бармы?

Шәкерт: Бар. Бездә, гәүдәдән башка, җан дип аталган бернәрсә дә бар.

Мөгаллим: Без җанны күрә алабызмы?

Шәкерт: Юк, күрә алмыйбыз.

Мөгаллим: Алай булгач, юктыр ул. Каян беләсең син бездә җан барлыкны?

Шәкерт: Чөнки үлгән кешенең җаны чыга. Ул җансыз кала.

Мөгаллим: Бәлки, үлгән кешенең дә җаны бардыр. Аның җаны чыкканлыгын каян беләсең?

Шәкерт: Үлгән кеше бер дә селкенми, тик ята.

Мөгаллим: Шулай, афәрин. Бездә гәүдәдән башка җан барлыгын үзебезнең селкенүебездән беләбез. Бездә җан булганга күрә, без йөри, утыра, ашый-эчә, ни теләсәк, шуны эшли алабыз. Әгәр дә бездә җан булмаса, без таш вә агачлар кебек булыр идек. Үлү ул – тәннән җан чыгу дигән сүз. Шулай түгелме?

Шәкерт: Шулай.

Мөгаллим: Безнең гәүдәләребез мәңге шулай торамы, әллә бервакыт бетәме?

Шәкерт: Бетә. Үлгәч бетә.

Мөгаллим: Әлбәттә, бетә. Үлдең исә, тәннәребез чери, туфрак була. Җан ул һичвакыт бетми. Ул, безнең гәүдәләребездән аерылса да, һаман кала. Ул мәңге кала. Аңа бетү юк.

Мөгаллим: Әле без бая фәрештәләрне нинди мәхлуклар дигән идек: яхшылармы, яманнармы?

Шәкерт: Яхшылар, дигән идек.

Мөгаллим: Әлбәттә, яхшылар. Чөнки алар Аллаһы Тәгаләнең кушкан эшләрен бер дә карышмый башкаралар. Аңа гел гыйбадәт кылган, изге эш эшләгән кеше, әлбәттә, яхшы була. Ә Иблис вә шайтаннар яхшылармы, яманнармы?

Шәкертләр: Яманнар.

Мөгаллим: Алар ник яманнар соң?

Шәкерт: Чөнки алар Аллаһы Тәгаләгә карышканнар, шуңа күрә яманнар.

Мөгаллим: Дөрес, бик дөрес әйттең. Алар – бик явызлар, бик яманнар. Алар, Аллаһы Тәгаләгә карышканга, икенче төрле әйтсәк, гөнаһ кылганга күрә, яман, явыз булып киткәннәр. Ә фәрештәләр, Аллаһы Тәгаләнең боерыгын тотканга, икенче төрле әйтсәк, изге гамәл кылганга күрә, яхшы булганнар. Йә, Габдуллаһ, әйт әле: безгә фәрештәләрдән үрнәк алырга кирәкме, шайтаннарданмы?

Шәкерт: Фәрештәләрдән үрнәк алырга кирәк.

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2021) санында.

Мөгаллим: Әлбәттә, фәрештәләрдән үрнәк алырга, шайтаннарны дошман күрергә кирәк. Алар бит бездән гел явызлык гына кылдырырга тырышалар. Алардан Аллаһы Тәгаләгә сыенырга кирәк. Ә фәрештәләр гел изгелек кенә кылалар. Алар безгә һәрвакыт хәерхаһлар. Фәрештәләрнең бит безне явызлыкка, һәлакәткә төшүдән саклаучылары да бар. Безгә менә, алар кебек, Аллаһы Тәгаләгә буйсынырга, Аллаһы кушкан нәрсәләрне эшләргә, Аллаһы тыйган нәрсәләрдән тыелырга кирәк. Аллаһ кушкан нәрсәләрне эшләү, Аллаһы тыйган нәрсәләрдән тыелуны изге гамәл кылу диләр. Аллаһыга карышу, Аллаһы тыйган нәрсәләрне эшләү гөнаһ кылу була. Безгә, әлбәттә, фәрештәләрдән үрнәк алып, изге гамәл кылырга, шайтаннар кебек гөнаһ кылмаска кирәк. Шулай түгелме, шәкертләр?

Шәкертләр: Шулай, хәлфә, шулай.

Мөгаллим: Фәрештәләр әнә, гел Аллаһы Тәгалә кушканча йөргәнгә, изге гамәлләр генә кылганга күрә, Аллаһы Тәгаләгә бик якыннар. Ә шайтаннар, Аллаһы Тәгаләгә карышканга, гөнаһ кылганга күрә, Аның хозурыннан сөрелгәннәр, бәхетсезлеккә очраганнар. Шулай ук без дә, фәрештәләрдән үрнәк алып, яхшылык кылсак, Аллаһы кушканча торсак, Аның әмерләреннән чыкмасак, бәхеткә ирешәчәкбез, үлгәннән соң җаннарыбыз шат булачак. Әгәр, шайтаннар кебек, Аллаһы Тәгаләнең боерганыннан чыксак, гөнаһка батсак, без дә алар кебек явыз, бәхетсез булачакбыз. Йә, Кәрим, әйт әле: әгәр дә син гел әти-әниең кушканча йөрсәң, аларның сүзләрен гел тыңласаң, аларга бер дә карышмасаң, алар сиңа ничек карыйлар?

Шәкерт: Бик яхшы карыйлар, мине яраталар.

Мөгаллим: Шулай шул. Ул вакытта син аларга бик кадерле буласың. Алар шулай сине бик сөяләр, сиңа тәти киемнәр алып, тәмле нәрсәләр ашаталар. Әгәр дә син аларның сүзләрен тыңламасаң, аларга карышсаң, алар әйткәнчә йөрмәсәң, алар сине нишлиләр?

Шәкерт: Орышалар, тиргиләр.

Мөгаллим: Шулай шул, орышалар, тиргиләр, ачуланалар. Алар синең гел яхшы булуыңны телиләр, яман булып китүеңнән куркалар. Шунлыктан, начар эштән кайтсын, дип, сине шелтәлиләр. Менә шулай ук Аллаһы Тәгалә дә Үзенең әмерләрен үтәгән, ягъни изге гамәл кылган кешеләргә дөньяда әллә никадәр нигъмәтләр биргән кебек, киләчәгебездә, үлгәч тә, аларга бүләк бирә. Икенче төрле әйтсәк, әҗер вә савап бирә, аларның җаннарын шат кыла. Ә Үзенең боерыгын тотмаган, ягъни гөнаһ кылган кешеләргә җәза вә газап бирә. Шулай булгач, безгә нишләргә кирәк?

> «Изге гамәл кылып, саваплы булырга, үлгәч рухларыбызның шат булуына ирешү өчен тырышырга кирәк. Яман эшләр эшләп, гөнаһ кылып, үлгәннән соң рухларыбызның бәхетсез, кайгылы булуыннан саклану тиеш.

Шәкерт: Әлбәттә, изге гамәл кылырга кирәк.

Мөгаллим: Дөрес, шулай эшләргә кирәк. Изге гамәл кылып, саваплы булырга, үлгәч рухларыбызның шат булуына ирешү өчен тырышырга кирәк. Яман эшләр эшләп, гөнаһ кылып, үлгәннән соң рухларыбызның бәхетсез, кайгылы булуыннан саклану тиеш. Менә ата-ана, хәлфәләр гел шулай яхшы эшләр эшләргә, яман эшләрдән тыелырга кушалар. Сезгә шулар кушканча йөрергә, шулай итеп, киләчәктә бәхет-сәгадәткә ирешергә кирәк.

*Текстны басмага **Мәдинә Әбделганиева** әзерләде.* ■

МӨҺАҖИРЛЕКТӘГЕ ТАТАР КИТАБЫ

Татар мөһаҗире Рәсәйнең элеккеге башкаласында

Хатыйп Миңнегулов, филология фәннәре докторы

Хәсән Хәмидулла

1900 елда Нижгар төбәгенең атаклы Яңапар (Актук) авылында туып, шунда ук мәдрәсәдә укып, 15 яшьләрендә, ягъни Октябрь революциясе алды елларында Финляндиягә күчеп, әүвәл бу мәмләкәтнең төньягындагы Кеми каласында, 1950 елдан башлап Хельсинкида гомер кичергән һәм 1988 елның 6 ноябрендә шунда ук вафат та булган Хәсән Низамеддин углы Хәмидулланың исеме, күпкырлы эшчәнлеге татар дөньясында күптәннән мәгълүм. Ул – әдип, шагыйрь, галим (тарихчы, этнограф, филолог, фольклорчы…), журналист, нашир – кыскасы, универсаль, энциклопедик эшчәнлеккә ия булган, Г.Утыз-Имәни, К.Насыйри, Р.Фәхреддин шикелле мәшһүр зат, чын мәгънәсендә олуг мәгърифәтче.

Хәсән Хәмидулла – төрле характердагы 50дән артык китап авторы, «Шималь очкыннары», «Мәгърифәт» һәм кайбер башка газета-журналларны чыгарган шәхес. Аның наширлегендә, үзенекеннән тыш, йөзәрләгән китап дөнья күргән. Болар арасында 1943 елда «Коръән»не үз хисабына 20 мең данә бастырып, Скандинавиядәге мөселман әсирләренә таратуы үзе генә дә зур батырлык-фидакярлек!

Хәсән Хәмидулла хакында без фәкыйрегезнең дә шактый гына язмалары бар. Алар һәм әдипнең күп кенә әсәрләре безнең китапларда [мәсәлән, «Чит илләрдәге татар әдәбияты» монографиясе (К., 2007), «История Актукова» (К., 2008)], төрле газета-журналларда дөнья күрде. Әле 2020 елда гына да «Безнең мирас»та (11-12 нче саннар) Хатыйп Йосыф углының «Олуг мәгърифәтчебез Хәсән Хәмидулла» исемле мәкаләсе һәм бу каләм әһеленең дистәләгән шигырьләре журнал укучыларына тәкъдим ителде.

Гадәттә, бай иҗат мирасын бай биографияле шәхесләр тудыра. Хәсән ага – дөньяны күп күргән, күпне кичергән зат. Башыннан кичкәннәрен, гомер юлын ул шактый дәрәҗәдә үзенең язмаларында да гәүдәләндерә. Бу яктан аның «Тәрҗемәи хәлем» дип исемләнгән кызыклы гына язмасы аеруча мөһим. Анда авторның биографиясе, күпкырлы эшчәнлеге генә түгел, башка кайбер шәхесләрнең язмышлары, милләтебез, иҗтимагый-мәдәни тормыш вакыйгалары да теркәлеп калган. (Бәлкем, Алла боерса, бу «Тәрҗемәи хәлем»нең аерым өлешләре белән хәзерге укучыларны таныштыру насыйп булыр.)

Әлегә исә Х.Хәмидулланың «Совет Русиясендә кунакта» дип аталган сәфәрнамә төрендәге бер язмасы хакында кыскача гына сүз алып барырбыз. Бу сәяхәтнамә 20 нче елларның ахырларында язылган. Ул Берлинда Г.Исхакый мөхәррирлегендә нәшер ителүче «Милли юл» (бераздан «Яңа милли юл») журналының 1929 елгы саннарында басылып чыккан. Гарәп язуында. Хәсән Хәмидулла журналның үз мәкаләсе басылган 9-10 нчы саннарындагы өлешләрен үзенең «Ник алай?» [(5.Финляндия мөселманнарының тарихи материаллары) (Хельсинки, 1977. – 234 б.)] дигән китабында теркәгән. Анда «Совет Русиясендә кунакта» әсәренең журналның тәүге ике санында чыккан текстлары гына урнаштырылган. Аларда, язманың дәвамы бар, диелгән һәм, шуңа өстәп: «Дәвамы миндә артык табылмады, Төркиядәге китапханәләрдә бар, имеш» – дигән сүзләр кулдан язылган. Үкенеч ки, «Яңа милли юл»ның 1929 елдагы башка саннары (11, 12…) хәзергә кулыбызда юк. Шуңа күрә биредә, нигездә, 9-10 нчы саннардагы текстларга таянып кына фикер йөртергә туры килде. Аларда авторның Ленинградка килүе, бу шәһәрнең кайбер җирләрендә булуы, кемнәр белән очрашулары, биредәге мәшәкать-борчылулары, элеккеге башкала, аның кешеләре, аерым гореф-гадәтләре, йолалары, күренешләре хакында сүз бара.

Мәгълүм ки, Петербург (Ленинград) белән Хельсинки арасы бик якын – берничә сәгатьлек кенә юл (аннан минем дә узгалаганым бар). Алар элек-электән үк аралашып торганнар. Суоминың – 1809 елдан Октябрь инкыйлабына кадәр бер үк дәүләт – Рәсәй империясе составында булуы да аларны якынайта. Бу калаларда охшаш йорт-биналар, архитектура корылмалары да шактый. Хәтта Хельсинки үзәгендә хәзергә кадәр урыс патшасы Александр Iгә мәһабәт һәйкәл дә тора. Финляндиядәге һәм Петербургтагы милләттәшләребез шактый тыгыз мөнәсәбәттә яшиләр. Моны без Г.Исхакый һәм кайбер башка шәхесләребез мисалында да ачык күрәбез. Хәсән Хәмидулла Октябрь инкыйлабына кадәр үк әлеге калада берничә мәртәбә була. Ленинградка бу килүендә дә биредәге танышлары – милләттәшләре белән очраша.

Финляндия мөстәкыйльлек алгач, ике арадагы мөнәсәбәтләр бик йомшара, төрле сәяси-иҗтимагый каршылыклар, киртәләр туа. Сәфәрнамәдә дә алар шактый ачык күренә. Авторның бу сәяхәте 20 нче елларның аралыгында була (1927-1928 нче елларда булса кирәк). Аның бу шәһәргә килү максаты ачык әйтелми. Мөгаен, сәүдә, сатып алу тармаклары белән бәйледер. Авторның әйбер-багажларының күп булуы да шул хакта сөйли.

Х.Хәмидулланың әлеге язмасы берничә яктан игътибарга лаек. Аның үзәгендә – тәҗрибәле, зирәк, сәүдә эшләреннән бик тә хәбәрдар булган шәхес. Ул күргән-ишеткән вакыйга-хәлләргә тәнкыйди карый, аларга үз мөнәсәбәтен ачык белдерә. Автор кием-салым, гореф-гадәт, тәртип-кануннарга аеруча игътибарлы. Аның язмасы шул чордагы совет тәртипләрен, Ленинградның һәм андагы халыкның нинди леген аңларга да шактый ярдәм итә. Язмада, мәсәлән, рәсми хакимиятнең чиркәүләргә хәерхаһлы булуы, ә мәчетләргә негатив мөнәсәбәттә торуы искәртелә.

Хәсән Хәмидулла язмасы, әйткәнебезчә, «Милли юл»да басыла. Мәгълүм ки, журналның баш мөхәррире Г.Исхакый элек-электән үк Финляндиядәге милләттәшләребез белән аралашып тора, үзе дә анда күп мәртәбәләр була. Суомидагы татарларыбыз бөек әдипне бик тә хөрмәт итә, мөмкин вакытта аңа ярдәмнәре дә тиеп тора. Болар арасында, әлбәттә, милләтпәрвәр Хәсән ага да бар. Шунысын да искәртик: Г.Исхакый үз журналына материалларны бик сайлап, милләт мәнфәгатенә туры килешлеләрен генә урнаштыра. Финляндиядәге коллегасына «Милли юл» кебек дәрәҗәле басмада урын бирелүе дә шактый мәгънәле.

Кыскасы, Х.Хәмидулланың «Совет Русиясендә кунакта» язмасы милли-мәдәни, иҗтимагый-сәяси яктан, танып-белү җәһәтеннән бүгенге укучы өчен дә билгеле бер әһәмияткә ия. Без аны, нигездә, оригинал язылышында, аның тел-стиль үзенчәлекләрен саклап бирергә тырыштык. Гарәп язуындагы текстны хәзерге графикага күчергәндә, сүз-гыйбарәләргә аңлатмалар биргәндә, аерым төгәлсезлекләр, кимчелекләр дә булырга мөмкинлеген дә һич инкяр итмибез. Һәм моның өчен укучыдан алдан ук гафу да үтенәбез.

Сәфәрнамәнең 9-10 нчы саннарындагы хәл-вакыйгалар, нигездә, Ленинградта бара. Аның безгә мәгълүм соңгы өлеше авторның, поездга утырып, «Мәскәүгә хәрәкәт итүен» язу белән төгәлләнә. Алга таба нәрсәләр булгандыр – анысын хәзергә әйтә алмыйбыз. Журналның алдагы саннары кулга керсә, сәфәрнамәнең дәвамын да, бәлкем, укучыларга тәкъдим итәрбез.

Ахыры киләсе санда ■

безнең мирас №12 декабрь 2021

Хәсән Туфан һәм Сирин

Әнвәр Шәрипов, филология фәннәре докторы

Хәсән Туфан



Сирин

1926 елның көзендә Сирин, Казанга килеп, Көнчыгыш дәүләт педагогия институтына укырга керә. Нәкъ менә шул чакта ул Һ.Такташ, Г.Кутуй, Ә.Исхак һәм Хәсән Туфан белән таныша. Шуннан соң Сирин белән Туфан үзара аралашып яши башлыйлар. Бу танышлык, бу аралашу гомер буена сузыла: алар арасында бервакытта да фикер каршылыклары булмый.

Сөргеннән кайтканнан соң очрашу

Сөрген чорында үз башларыннан язмышның тетрәндергеч тирән фаҗигаләрен кичергән ике аксакал шагыйрь – Туфан белән Сирин, инде иреккә чыккач, ниһаять, 1959 елның 19 декабрендә Казанда Бауман урамындагы Тукай клубында үткәрелгән бер кичәдә очрашалар. Бу турыда Сирин белән 1930 нчы елларда ук танышкан Локман Бадыйкшан үзенең «Шагыйрь белән очрашулар» дигән истәлегендә болай дип яза: *«1959 елның 19 декабрендә миңа Казанның Бауман урамындагы Матбугат йортының Габдулла Тукай исемендәге клубына олы әдибебез Нәкый Исәнбәтнең бөек галим Риза Фәхреддингә багышланган чыгышын тыңларга туры килде. Нәкый Исәнбәт сөйләп бетергәч, халык тарала башлады. Шулвакыт ишектән миннән алдарак чыгып барган шагыйрь Хәсән Туфан*

чандыр гына, йөзен җыерчыклар баскан бер картны кочаклап алды. Минем белән янәшә атлаган язучы һәм тәнкыйтьче Гази Кашшаф абый: «Локман, алар кемнәр, таныйсыңмы?» – диде. «Хәсән Туфанны таныйм. Аны сугышка кадәр дә күргәнем булды. Ә икенчесен беренче тапкыр күрүем», – дип җавап бирдем. «Шагыйрь Сирин ул», – диде Гази Кашшаф...

Матбугат йорты төбендә, ишектән бераз читкәрәк китеп, шактый вакыт шагыйрь Сиринне көттем. Күрәсең, ул яшьлек дусты Хәсән Туфаннан тиз генә аерыла алмаган...

Матбугат йортыннан килеп чыгуына, шагыйрь Сирин белән күрешергә ашыктым. Бераз сөйләшеп алдык. Шагыйрьнең яшь вакытын күреп белгәнгәдерме, ул миңа бик тә якын иде. Фатирыма чакырдым, шагыйрьне кунак итәсем, үткән тормышы турында тыңлыйсым, иҗаты белән якыннан танышасым килде. Сирин минем чакыруымны кабул итте». («Татар иле» газетасы, 1996 ел, декабрь, №48.)

Ике аксакал әдипнең сөргеннән кайтканнан соң беренче очрашуы була бу. Шуннан соң алар арасындагы элеккеге эчкерсез дуслык яңадан кабынып китә һәм Сириннең вафатына – 1969 елга кадәр бара.

Хатлар алышу, кунакка йөрешүләр

Хәсән Туфан белән Сирин 1960 нчы елларда хатлар да алышканнар, хәтта бер-берләренә кунакка да йөрешкәннәр. Шул очрашуларның берсендә Хәсән Туфан Сиринга үзенең 1958 елда Татарстан китап нәшриятында чыккан «Җырлар. Шигырьләр» китабын бүләк иткән. Китапның беренче битенә ул яшел кара белән болай дип язып куйган: *«Сирин! Дөньяда икенче кат яшәгән кабатланмас матур көннәребез истәлеге булсын бу сиңа. Ихтирам белән, Х.Туфан. 27.XI.61.»*

Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Мирасханәсендә саклана торган Хәсән Туфан фондында (133 нче фонд, 3 нче тасвирлама, 128 нче эш берәмлеге) ике шагыйрьнең үзара язышкан хатлары саклана. Анда, нигездә, Сириннең Хәсән Туфанга язган хатлары тупланган. Бу хатларда Сириннең Казаннан читтә яшәвенең, шагыйрьләр, язучылар белән аралашу мөмкинлеге юклыгының аның иҗатына уңай йогынты ясамавы һәм инде реабилитацияләнгәннән соң да әле авыр шартларда (эшчеләр барагында) гомер кичерүе күренә. Шул хатларның берсенә тукталып китик.

1961 елда Хәсән Туфан Баулыда Сириннәрдә кунакта булып киткән икән. Сирин бу хатны шуннан соң язган. Ул гарәп хәрефләре белән язылган, шактый авыр таныла. 1956 елда ук реабилитацияләнгән булса да, Сирингә 1961 елга кадәр пенсия бирмиләр. Сирин, берәр ярдәме тимәсме, дип, Туфанга мөрәҗәгать итә. Ул болай яза:

«Туфан! Сәлам сиңа киң кырлардан, урманнардан, гөлләрдән, чылтырап аккан чишмәләрдән, Фәһимәдән, үземнән!

Исән-сау кайтып җиттеңме? Сине озаткач, безгә шактый күңелсез булды. Аерылу хисләрен кичердек. Ф.Кәрим: «Мин бүген сугышка керәм. Әгәр анда үлеп калсам, мин бүген кояшны актык мәртәбә күрәм», – дигән иде. Мин дә шундый халәт кичердем. Актык күрүем булмасын дип шүрләдем.

Син миңа Дәрдемәнд сеңлесенең сәламен тапшырган идең. Мин шунда: «Аларга минем сәламемне әйт!» – дип тә әйтә белмәдем кебек. Әгәр әйтмәгән булсам, зинһар, аларга минем сәламне тапшыр. Дәрдемәнд кебек зур шагыйрьнең сеңлесен белү – зур бәхетең ул. Аның урынын беркем дә алмаштыра алмый.

Мин сиңа Миргалимнең адресын җибәрмәкче булган идем (Миргалим Шакиров). Ул пенсия законнары белән бик таныш кеше. Мин аңарга да хат яздым. «Әгәр синең Татиздатта эшләгән урыныңнан окладың турында справка да бирелсә, мин бу мәсьәләне (пенсия) тәэминат бүлегендә эшләүче Гали Сафиуллин белән сөйләшеп хәл кыла алам», – дигән иде ул.

1930-1935 елга кадәр мин Татиздатның авыл хуҗалыгы секторында әдәби-техник редактор булып эшләдем.

1960 елда, реабилитация соңында, ике айлык зарплатаны түләргә булгач, ул сектордан... (бер сүз танылмый. – Ә.Ш.) күпме эшләдем. Айлык окладым күпме булуы турында справка биргән иде. Ул справка буенча, миңа шунда 1600 сум (тиен акча белән) акча бирделәр. Справканы да алып калдылар. Бу түләү буенча минем окладым 800 сум булган була.

Мин эшләгән вакытта эшләгән Гыймадиев, Кадыйров хәзер дә шул секторда эшлиләр. Әгәр Кадыйровка: «Сирингә менә шундый айлык оклады турында справка кирәк, менә шуны эшләп бирсәгез иде» – дисәң, Кадыйров моны эшләп бирер иде. Шул справканы Миргалимгә бирсәң, ул, Гали Сафиуллин белән сөйләшеп, бу мәсьәләне хәл итәрләр иде.

Итекченең итеге булмый, читекченең читеге булмый, язучының вакыты булмый. Шунлыктан бу эшне дә сиңа йөкләү бик надир инде. Әгәр Миргалимне күреп сөйләшә алсаң, бәлки, аңа тапшыра алсаң, синең киңәшең бик зур.

Миргалим Шакировның адресы: г.Казань, ул.Татарстан, дом №10, кв.№10. Шакирзянов Галим (Миргалим)».

Кәгазьнең икенче ягына ул болай дип язган: *«Бөек Октябрь бәйрәме җитә. Сине шушы зур бәйрәм белән котлап, һәрбер эшеңдә зур уңышлар теләп калабыз. Сиңа озын гомер, исәнлек-саулык телибез. Фәһимә бер җыр җырлый. «Миннән сәлам әйт. Шул җырны яз», – ди.*

Иртән торып тышка чыксам,
Зәңгәр күрәм җир шарын.
Үз гомеремдә онытмамын,
Җир шарында Сез барын.
Хөрмәт белән, Сирин дускаең. 6/XI – 61».

Кәгазьнең икенче ягына Хәсән Туфан яшел кара белән язып куйган: *«Бу хат менә бары бүген генә кәгазьләр арасыннан килеп чыкты. Үзем өйдә (Казанда) юк чакта килгән булган, күрәсең. Хат ачылмаган иде. Бу пенсия мәсьәләсе хәл кылынды инде. Сирин пенсия ала. Аз ләкин. Ничек яшиләр икән алар анда? Хат язарга кирәк.*

Миндә калган шигырьләрен яңадан «Совет әдәбияты»на биреп карарга кирәк. 17 – XII.62».

Сириннең хаты 1961 елның 9 нчы ноябрендә җибәрелгән. Кайтарма адресы конвертка: «Бавлинский р-н, СМУ-4, барак 5, кв.5», – дип язылган. (Бу әле Сириннең фатир алмаган, баракта яшәгән чагы була. – Ә.Ш.)

Сирин белән Хәсән Туфан хатларында әдәби иҗат, осталык, шигърият темалары да күтәрелә. Ул, нигездә, Сириннең Туфан белән киңәшләшүенә – аңардан киңәш соравына кайтып кала.

Сирин белән Хәсән Туфанның дистә еллар буена сузылган дуслыгы татар әдәбияты тарихының матур бер истәлеге булып тора. ■

Безнең мирас №12 декабрь 2021

Сүз шатлыгы

(Парчалар)

Фәиз Зөлкарнәй

Табып алдым юлдан бер ялгыз сүз...

Марсель Галиев

Шагыйрь, тәнкыйтьче
һәм мөхәррир
Фәиз Зөлкарнәй
(1951-1997)

Шагыйрь бераз сабый бала да була алырга тиеш икән. Әгәр балага яңа уенчык бирсәләр, ул аны, кулыннан төшермичә, куанычыннан көне буе күтәреп йөри, башка балаларга күрсәтеп мактана, аларның да мактавын, хуплавын көтә. Шагыйрь дә шулай ук. Яңа сүз тапса яисә берәр сүз аның игътибарын көтелмәгән яңа ягы белән җәлеп итсә, шагыйрь, әйтерсең, ул сүзне кулында тотып, әйләндереп-әйләндереп карый, күңеленнән генә яки кычкырып әйтеп, кат-кат кабатлый, яңгырашына колак сала, мәгънә төсмерләренең һәммәсен күңеленнән уздырып, гүя татып карарга тели; шул бер сүзгә сокланып, шатланып озак йөри ул.

Шагыйрь

Ул – кешегә кагылышлы һәрнәрсәне хисләр матурлыгына, матурлык тойгысын рухиятебезнең бердәнбер теленә әйләндерергә тырышучы, шигъриятне бүгенге дөньяның уртак теленә, килер гасырларга бездән барып ишетелерлек иң саф аваз, тарих теле дәрәҗәсенә күтәрергә омтылучы замана хыялые.

Тарих һәм без

Тарих тойгысына ия булу кирәк. Бүген масаеп-кукраеп, үзен даһига санап йөрүчеләр, миңа калса, нәкъ менә шушы тойгыдан мәхрүмнәрдер сыман. Хәзерге тыныч тормышның тыйнак кешеләре арасында «даһилык» яулау җиңелдер дә, ә менә тарих алдында? Килер буыннар алдында? Алар бит сине тарихтагы бүтән шәхесләр белән чагыштырып карар, һичшиксез, шулай итәр. Йә, кем отар соң?..

***

Заманны аңлау ихтыяҗы туугa ук, үзеннән-үзе яңа мәсьәлә пәйда була: тарихны аңламыйча торып, бүгенге көнне аңлау мөмкин түгел икән!

Алыйк гасыр башындагы вакыйгаларны. Бишенче ел татар халкының милли аңын, милли горурлыгын уятып җибәрә, халык үзен бербөтен итеп тоеп, шул чактагы хәл-әхвәлен, перспективаларын аңларга омтылып хәрәкәткә килә. Бишенче ел әнә шул хәрәкәттән гыйбарәт. Ләкин бу аңлау процессы төгәлләнеш табарга өлгерми – реакция башлана: милләтнең иреген чикләү, башына сугып бик үк узынмаска кирәк икәнен искәртү вакыты килә. Кайнар кан суына төшә, уйланулар, анализ чоры җитә. Үткәнгә, ерак тарихларга карап үзеңнең кем икәнлегеңне ачыклау, шулардан чыгып бүгенгеңә бәя бирү башлана. Татар тарихы буенча бик күп китаплар (Г.Әхмәрев, Һ.Атласи, З.Вәлиди, Р.Фәхреддинов, Г.Баттал һ.б. хезмәтләре) нәкъ менә шул елларда дөнья күрә. 1908-1913 нче еллар – татар тарихын айкап-байкап сорауларга җавап эзләү, милләтнең үз бөтенлегенә, үзүзенә ышанычын ныгыту заманы. Һәрхәлдә, шуны ныгытырга омтылу. Әйтик, ул елларда күтәрелгән «Без татармы, болгармы?» дигән мәсьәләне хәл итү шуның бер билгесе була.

Хәзер тагын шул чаклар кайтты сыман.

Баш мөхәррир Фәиз Зөлкарнәй һәм «Идел» журналы хезмәткәрләре: сулдан – Рәфыйк Юныс, Ләис Зөлкарнәй, Нәбирә Гыйматдинова, Фәиз Зөлкарнәй, Роза Баубекова-Кожевникова, Фәридә Хасьянова, Ркаил Зәйдулла

Ф.Зөлкарнәй (рәсемдә икенче рәттә сулдан беренче) – мәктәп укучысы

***

Аңлылык, аң дигән нәрсә үзеңнең кем икәнеңне белүдән башлана. Татар халкын озак вакытлар буе үзе турындагы мәгълүматлардан мәхрүм итеп килделәр. Аны «аңсыз халык – аңгыра сарык» хәленә төшерү өчен махсус эшләнде бу. («Халыклар атасы» Сталин, мәсәлән, бәйрәм парадыннан соң, Кызыл мәйданга демонстрантларның шаулы колонналары керер алдыннан: «Сейчас бараны пойдут», – дип әйтә торган булган.) Татар тарихын өйрәнү туктатылды, татар тарихчылары йә законнан тыш дип игълан ителде (Г.Баттал, З.Вәлиди), йә үтерелде (Һ.Атласи, Г.Газиз, М.Худяков), йә булмаса, тәмам үгисетелде (Ш.Мәрҗани, Р.Фәхреддин). Мәктәпләрдә без үз тарихыбыз урынына урыс халкының дәүләтчелек тарихын укып үстек, безгә, шулай читләтеп кенә булса да, тарихсыз, нәсел-нәсәпсез халыкның бичара балалары икәнлегебезне «төшендерделәр». Мондый эшчәнлекнең аяныч нәтиҗәләре хәзер барыбызның да күз алдында. Туган җиреннән, гореф-гадәтләреннән кубарылган, тәмам «нәсел-нәсәпсез Иван»га әйләндерелгән ничәмә-ничә буын ил буйлап чәчелде. Революциягә тикләм үк 5 миллион булган (Г.Газиз мәгълүматы) татар халкы, үсә-ишәя алмыйча, һаман шул күләмдә кала килә. Милләтебезнең биштән бере диярлек (1 миллион 130 меңе) ана телен белми. Маңкортлар кавемен ишәйтүгә безнең кебек зур өлеш керткән тагын берәр милләт бармы икән?!

Ләкин кеше аңсыз яши алмый – табигать шулай яраткан. Иртәме-соңмы, кеше барыбер үзенең кем икәнен белергә тели. Ата-бабаларын, тарихын белергә тели ул. Мондый теләкне берничек сүндереп тә, юк итеп тә булмый. Бигрәк тә кимсетелгән халык күңелендәгесен. Нәкъ менә кимсетелгән халыклар күңел юанычын үткән тормышыннан эзләүчән була. Безгә дә хас бу сыйфат. Югыйсә кайдан чыгар иде «Без – болгар!» дип болганып йөрүчеләр? Фән менә ничә еллар буе инде тарихыбызның борынгы, Болгар чорында һәм туры, һәм күчерелмә мәгънәдә казынып ята. Әллә шуңа күрәме, әллә «поганый, го-

лолобый татарин» булып йөрүдән тәмам туйган милләттәшләребезнең түземлеге төкәнү аркасындамы, үз белдекләре белән халкыбызның милли шәҗәрәсен ачыкларга керешкән һәвәскәрләрнең: «Без болгар икән бит!» – дигән сөенечле авазы һаман саен ныграк яңгырый. Шагыйрь, әрнеп: «Үткән бөеклеккә кайтып булмый, табынып кына була», – дип әйткән хакыйкатьне онытып җибәрүдә генә түгелдер хикмәт (Р.Фәйзуллин). Мондый болгануларның, бер чиктән икенчесенә ташлануларның сәбәбе – һаман да шул мәгълүматсызлык. Тарихны тулы белмәү. Милли асылыңны аңламау. Аңсызлык.



Ф.Зөлкарнәй хатыны Иркә, кызлары Ләйсән һәм Ләйлә белән

***

Тарихтан бөтенләй хәбәре булмаган кешеләрне очратып җан әрни. Аларның әрсез оптимизмы да, мескен пессимизмы да бердәй тәэсир калдыра. Шәрәлек! Имәнеп китәсең. «Хәтер югалту – хыял югалту кебек үк куркыныч…» – Мостай Кәримнең шушы сүзләре күңелгә килә.

***

Чын сәнгатькяр тормышны төгәл чагылдыру белән генә канәгатьләнеп калмый. Дөньяны аңлату гына җитми, аны үзгәртергә кирәк! Шушы изге максатны үтәү өчен, сәнгать әсәре тормыштагы яңа тенденцияләрне, омтылышларны күрсәтергә, илдәшләрне дулкынландырырлык, дөнья турында, кеше турында уйга салырлык булырга тиешле…

Дөньяны үзгәртәбез, дигәч, аны ничек, кая таба үзгәртүебезне онытмау кирәк.

Мәңгелек учак

Борынгы заманда ыруг учагын карап-саклап торучы махсус кешеләр булган. Атасы үлсә, улы караган утны, улы үлсә – оныгы. Шулай буыннар алышынган, дәверләр алышынган. Учакны еллар, гасырлар буе сүндермәгәннәр. Учак утын гына түгел, цивилизация утын, бабалары, әтиләре калдырган акыл утын сүндермичә саклаган кеше.

Һәммәбез – шундый ук ут саклаучылар. Борынгылар кабызган ут, өлкәннәр саклап алып килеп тапшырган мәдәният уты бездә яна хәзер. Һәр буын, һәр йөрәк аңа үз ялкынын өсти.

1979-1989 нчы еллар
(Язма Ф.Зөлкарнәйнең «Чакма чакмый ут чыкмый» дигән китабыннан (1991) алынды.) ■

Безнең мирас №12 декабрь 2021

Зәки Нури шигырьләре

Синең җырың

Урманнарга барып карыйм,
Чыгып китәм кырларга:
Бер ялгызым качып кына
Синең җырны тыңларга.

Ул – синең мине тибрәткән
Чактагы сүзең, әни.
Кушылып минем йөрәккә
Җырлыйсың үзең, әни.

Ул – синең назың яктысы,
Ул – синең түзем җыры.
Ул – синең караш чаткысы,
Ул – синең күзең җыры.

Ул – синең җылы сулышың,
Ул – синең ана булу.
Иң матур җыры тормышның –
Минемчә, ана булу!

Кайларда йөртмәде юллар,
Кайларга омтылмадым.
Күңелгә син салган җырлар
Юк, әни, онтылмады.

Көеңне ятлыйм-кабатлыйм
Синең сүз белән, әни.
Син – кояш. Синсез таң атмый! –
Мин шуны беләм, әни.

Зәки Нури (беренче рәттә сулда) каләмдәшләре һәм Язучылар берлеге хезмәткәрләре белән: Мирсәй Әмир (беренче рәттә сулдан өченче), аның янәшәсендә Разыя Әхмәдуллина (бухгалтер), Хәсән Сарьян, ...; икенче рәттә сулдан беренче Гариф Ахунов, Газиз Мөхәммәтшин (сулдан дүртенче), аның янында Ләбибә Ихсанова (иң уртада). 1966 ел. ***Ләбиб Лерон архивыннан***

Матурлык

Матурның да матурыдыр – дөреслек,
Кыска итеп оста әйткән сүз матур.
Матур була гаделлек һәм тырышлык,
Күңел күзен тарта торган күз матур.

Сөя белү – иң-иң матур матурлык,
Матурлыкның таҗы, диеп әйтерлек.
Матурлыкны сөеп яшәү – батырлык,
Матурлыкны аңлый белмәү – фәкыйрьлек.

Ишек белән бусага

Төртеп ача, тартып ача бар да,
Каеручылар хәтта табыла.
Ләкин ишек – ничек ачсалар да! –
Бусагага таба ябыла.

Юк, бүтәнчә әйтмә, мин ишетмим,
Аерылмабыз! – шуны ишет син:
Син бусага булсаң, мин ишекмен,
Мин бусага булсам, ишек – син! ■

Җыр белән атлыйбыз*

Шәкүрә Юзеева

Җәй көне картәти безне – мине, Сәлмән һәм Кәримә апаны Яңарус (Новотроицк) дигән рус авылына укырга-язарга өйрәнергә илтеп куйды. Без анда унбиш көн булдык. Укытучы безгә рус хәрефләрен укырга-язарга өйрәтте. Бик тиз өйрәндек. Укып кайткач, фатирның хуҗа хатыныннан өй эчендәге әйберләрнең атамаларын сорап, хәтердә калдырырга тырыштык. Безнең русча бар белүебез шул булды.

Картәти үз дәверендә, культуралы кеше буларак, газета-журналлар алдыра иде. Газетаның исеме – «Вакыт», журналныкы «Таң» иде кебек.

1917 елгы революциядән соң күп тә тормый, картәти үзе теләп муллалыгын ташлады.

Әтинең үскән авылы Агыйдел буенда, бик матур җирдә урнашкан булганлыктан, ул авылын бик сагынгандыр. Печәннәр, ашлыклар өлгергәнлеген белү өчен басуларга чыкканда мине дә үзе белән тарантаска утыртып алып чыга һәм мондый җыр җырлый иде:

«Аккош атасым килә,
Атсам, аласым килә.
Илегез ямьсез, суыгыз тәмсез,
Илемә кайтасым килә».

1917 елның сентябрендә әти мине укырга Уфага илтеп куйды. Анда Абызгильдин фамилияле мөфти карамагында кызлар мәдрәсәсе бар иде. Мине өченче сыйныфка алдылар. Укытучыбыз Рәсимә Акбирдина дигән яшь кенә апа. Ул өстенә ал кофта, кара итәк кигән, башына ак батист яулык бәйләгән килеш күз алдымда тора. Анда да уку, матур язу, хисап дәресләре бар иде. Нигәдер, башка фәннәр хәтеремдә калмаган. Дәрестән соң югары класслар челтәр бәйләү (тастымал башларына, простыняга куяр өчен), кәрестән (йон җебеннән) кофта бәйләү кебек кул эшләре белән шөгыльләнәләр. Мин дә өйдә генә Мөхәррәмәдән (әтинең сеңлесенең кызы) тастымал башына челтәр, кесә сәгате өчен сәгать савыты кебек вак-төяк нәрсәләр бәйләргә өйрәндем.

Әкълимә апа да шул мәктәптә укыта иде. Мин Агыйдел яры буендагы Бельская дигән урамда, почмактан икенче йортта тордым. Хәмит ул вакытта Уфада, Әкълимә апаларда торып, рус мәктәбендә укый иде. Мин торган өйдән чыккач та Иделгә төшәр өчен агач баскыч эшләнгән.

Өй хуҗасы Әхмәт абый үзе урам ягындагы өйдә тора һәм өенә терәп салган кечкенә кибетендә сату итә иде. Аларның аскы катында авылдан килеп извозчик булып эшләүче бер кеше гаиләсе белән яши. Аның Хәмидә исемле кызы минем классташым иде.

---

*Шагыйрь Илдар һәм галим Нил Юзеевларның әнисе Шәкүрә Юзееваның Башкортстандагы Ямады авылы музеенда сакланып калган истәлекләреннән өзекләр. Дәвамы. Башы журналның 11 нче (2021) санында.

Язучы Гариф Ахунов һәм шагыйрь Илдар Юзеев

Шул йортның икенче башында минем хуҗа – Җәмилә апа яши. Әнисе, рус мәктәбендә укучы бер кызы, бер улы бар иде. Хуҗа Газиз абый кызыл гаскәрдә хезмәт итә иде.

> **«Безнең мәдрәсәдә укулар да үзгәреп тора. Аклар кергәндә дин дәресләре укытыла. Кызыллар керсә, туктатыла.**

Шәһәрне башлап кына күргәнгә, болай да юаш, куркаграк булганга, мин олы урамнарга һәрвакыт Хәмидә белән йөри идем. Менә Кәримовлар кибете. Аның башына «Борадәран Кәримовлар» (Братья Каримовы дигән сүз) дип гарәпчә язылып куелган. Ул ике катлы, анда төрле нәрсәләр сатыла, безнеңчә универмаг дияргә була.

Өстенә кара костюм, башына кара кәләпүш кигән приказчик абыйлардан кечкенә генә, матурлап эшләнгән кәгазь тартмалар сорап ала идек. Аларны балачак истәлеге итеп техникумны укып бетергәнче саклаган идем.

Шуңа каршы «Хөсәения» дигән китап кибетенә кереп, китап, дәфтәр, төрле каләмнәр алабыз. Дәфтәрләргә иптәшләрдән истәлекләр яздырабыз, үзебез ишеткән җырларны да язабыз.

Бер мәртәбә «Туманная картина» карадык. Эчтәлеген хәтерләмим. Толчок базарына барып курчак театрын карыйбыз. Ул урамда койма башына менеп утыра да таягы белән янымдагы кешеләрнең баш киемнәрен эләктереп ала. Исеме Петрушка була.

Русча белмәгәнлектән куркып, иң элек: «Мин русча белмим – я по-русски незнаю», – дигән сүзне өйрәндем. Урамда бер рус хатыны нәрсәдер әйтте. Мин: «Я по-русски незнаю», – дим, ә аның: «Әнә ич, беләсең!» – дигәнен аңлап торам.

Базарда чәчәк сатучы кытайларны карыйбыз. Кәгазьдән сырлап, төрләп ясаган чәчәкләрен өйгә дә алып кайткан идем.

Бу 1918 елның кышында Уфада булган хәлләр.

Тагын бер вакыйганы искә аласым килә. Аңа хәзер ярты гасырдан да узып киткәнгә, хәтерем таркалган, онытылган. Вакыйганың елын, кай вакытта булганын ачык кына әйтә алмыйм. Үземчә 1918 елның март ае булырга тиеш дип уйлыйм.

Башка бервакытта да эш кушмаган Җәмилә апа, беркөнне миңа Иделдән су алып менәргә кушты. Мин, су алып, баскычка менәргә юл аша чыгам дип торганда, борылышта атлы солдатлар чабып килгәнне күрдем. Күрү белән йөрәгем купты. Һәм мин бернәрсә дә белмим. Мин уянганда үзебезнең өй кырындагы почмак өйнең йорт уртасында ята идем. Буш бидерә, көянтәм янымда тора. Мин торып өйгә кайттым, Җәмилә апаның бик кайгырып, сөйләнеп йөргәне хәтердә калган. Шуннан йөгереп урамга чыктым. Сугыш, ату тавышлары юк. Күрше йорттагы яр башына пулеметлар корганнар. Без шуларны балалар белән карап йөрдек. Шул көннеме, икенчесендәме Җәмилә апаның ире Газиз абый кайтып, хатыны, балалары белән күрешеп кенә чыкканы истә калган.

Безнең мәдрәсәдә укулар да үзгәреп тора. Аклар кергәндә дин дәресләре укытыла. Кызыллар керсә, туктатыла. Мөфтинең хатыны Гайшә абыстай һәм аның янында карт Мәрьям абыстай, классларга кереп, дәрес барышын карап йөриләр иде.

Безнең күршедә сатучы Кәримовларның туганы яши иде. Аның Наҗия, Фоат исемле балалары янына хуҗаның кызы Нурдидә белән уйнарга керә идек. Аларның чын самавыры, чынаяк-тәлинкәләре, чын сыйлары белән чәйгә чакы-

рышып уйный торган идек. Без, әдәпле кызлар булганга, әнисе безне бик ярата, һәрвакыт безнең кереп уйнавыбызны тели иде. Җәмилә апаның кызына күлмәк тегеп бирә идек.

1918 елны июнь аеның иң матур көннәренең берсендә безнең өйгә зур кайгы килә. Уйламаганда әти үлеп китә. Әни 33 яшендә кечкенә 5 бала белән ятим кала. Миңа – 12 яшь ярым, Әминәгә – 10, Гарәбигә – 4, Мөшфикага – 2, Зөфәр 4 айлык булып, бишектә ятып кала. Әтине зиратка озатканда, Әминә, үкереп елап, аның артыннан иярә. Мин картинәй кочаклаган килеш капка төбендә елап торам. Гарәбине хәтерләмим. Мөшфика карбаз өстендә йоклап кала. Әнинең ничек елаганын күрмәдем. Ул соңыннан еламады. Ул, нинди зур кайгысы булса да, күзеннән яшь чыгарып елый алмый иде. Бөтен кайгысын йөрәге белән кичерә. Ачы кайгы-хәсрәтен тышка чыгару өчен, Тукайның җырын: «Шунда тамсын күз яшенең иң ачы һәм татлысы», – дип ярсып-ярсып җырлый иде. Әнинең никадәре әрнегәнен, эченнән өзгәләнгәнен мин аңлый башлаган идем. Шулай җырлаганда бик ямансу була иде.

Менә шул сәгатьтән башлап минем бәхетле балачагым тәмамланды. Алда мине балачагымның икенче төрле язмышы көтә иде.

1918 елның сентябрендә, Хәмит, Сәлмән һәм мине утыртып, картәти Бирскига укырга илтеп куйды. Хәмитләрнең кайда укыганын әйтә алмыйм. Мине татар мәктәбенең 3 нче классына бирделәр. Анда төпле белем алырлык укулар булмады. Чөнки ул вакытта укытучылар җитешмәгәч, әле берсе, әле икенчесе алмашынып тора иде. Шуның аркасында укылмаган көннәр бик күп булды. Шул кышны каникулга Падлубка кайттым. Анда Байкыбаш волость хезмәткәрләреннән һәм кайбер укытучылардан төзелгән агитбригада белән, Гыйльми апа мине дә толыпка төреп, чанага утыртып алып барды. Башта волость үзәге Байкыбашта сәяси темага доклад сөйләгәннән соң, концерт бүлегендә шигырь сөйләү, җырлаулар булды. Мин «Ятимә кыз ана кабере янында» дигән җырны җырладым. Тагын берничә авылда булдык. Мин җырлаганда кешеләр күз яшьләрен сөртеп, елап утыралар иде. Сәфәребез тәмамлангач, шунда катнашкан хезмәткәрләр, бакыр, көмеш акчалар җыеп, миңа тоттырдылар. Ул акчалар бер сумга җиткәндерме – белмим.

«

Мин җырлаганда кешеләр күз яшьләрен сөртеп, елап утыралар иде.

1919 елның язындамы, җәендәме мине апалар Бирскидагы Вострецовская урамындагы татар-башкорт балалары өчен ачылган «4 коммуна» дип йөртелгән балалар йортына бирәләр.

Тәрбиячеләр иртән сәяси темаларга әңгәмәләр үткәрәләр, шигырьләр сөйләтәләр, җырлаталар һәм төрле уеннар уйнаталар. Кайсы көннәрне тегү мастерскоена тегү тегәргә өйрәтү өчен алып баралар. Орчык эрләргә оста кызлардан йон эрләтәләр. Кухняда дежур тору, бүлмәләрне чиратлап җыештыру, юу кебек эшләрне үзебез башкара идек. Безне бик яхшы ашаталар, бик матур киендерәләр. Урамга алып чыкканда малайларга да, кызларга да яшел күлмәк, башка кызыл түбәтәй, аякка шыгырдап торган күн ботинка бирәләр. Стройга икешәр рәт тезелеп, җыр белән атлыйбыз.

*Текстны журналга **Гөлнара Халморадова** һәм **Ләйсән Данилова** әзерләде.* ■

Үткәннән хатлар

Зәки Зәйнуллин

Быел, Башкортстанга сәфәр вакытында – 18 октябрьдә Эстәрлебаш районындагы Тормай авылында булырга туры килде. Шул авылда яшәүче һәм иҗат белән шөгыльләнүче каләмдәш дустым Хисаметдин Исмәгыйлев миңа быел 4 мартта вафат булган могтабәр язучыбыз Зәки Зәйнуллинның (1933-2021) архивын тапшырды. Хат авторлары Фаил Шәфигуллин (1939-1982) һәм Мәгъсум Хуҗинның (1930-2008) ул вакытта – «Чаян» журналында, ә Җәүдәт Миңнуллинның «Казан утлары»нда эшләгән чаклары. Бу хатлар шул архивтан алынды.

Ләбиб Лерон

Фаил Шәфигуллин – Зәки Зәйнуллинга



«Казан. 16/IV – 80 ел.

Исәнмесез, Суфия һәм Зәки әфәнде *(әлеге һәм башка хатларда авторларның орфографиясе сакланды. – Л.Л.)!*

Төрекләр шулай башлыйлар хатны.

Берничә китап җибәрәм.

Ә.Еники – Татарстанда иң шәп прозаик. *(Бәясен белеп җиткермиләр ләкин.)*

М.Мәһдиев – галим, фәннәр кандидаты. Бик тә үзенчәлекле, яңача яза. Мәскәүдә ике китабы чыкты.

М.Юныс диңгездә йөзә. Капитан ярдәмчесе. Фикергә бай, күпне күргән кеше. Әле һаман диңгездә бугай. Очучы булып хезмәт иткән кайчандыр.

«Карбыз сугышы» хәл ителмәгән әле.

Кыска хикәяләрнең берсе барыр кебек. Тегеләре кабатланган кебек. Икенче һәм кушамат турындагысы.

Машинкада басканда интервал аша басарга тырышыгыз әле. Болай укуы да, редакцияләүе дә читен.

Теге летчикка *(сүз ике мәртәбә Советлар Союзы Каһарманы, кырым татары Әмәтхан Солтан (1920-1971) турында бара булса кирәк. – Л.Л.)* Кырымда Судак шәһәрендә һәйкәл бар бугай.

Безнең хәлләр әйбәт. Сезне дә шулай дип белеп, ышанып калабыз.

Фаил һәм Эльмира».

Мәгъсум Хуҗин – Зәки Зәйнуллинга



«Зәки туган!

«Җир исе» һәм Сәйти бабай турындагы хикәяләреңә тамга сугылды. Берсен 10 нчы яки 11 нче санга куярбыз. «Җир исе» дигәнен русчага тәрҗемә итәргә тиешләр. Хикәяләрең белән эш тәмам.

Повестеңны укыдым. Миңа ошады. Әлбәттә, шомартырга-кырыккаларга кирәк. Иң ахырда салмаклана. Алдарак туктатырга яки иң соңгы өлешен үзгәртеп эшләргә кирәк булыр. «Казан утлары» журналы редакторы белән сөйләшеп карармын (әле ул командировкада). Нәтиҗәсен хәбәр итәрмен.

Үзебездә иминлек. Сәламнәр.

Гаиләңә сәлам.

Повесть турында соңыннан тулырак язармын.

Һәр тарафта уңышлар теләп, сәлам белән Мәгъсум абзый. 23 март, 1984 ел».

Җәүдәт Миңнуллин – Зәки Зәйнуллинга



«Исәнмесез, Зәки абый!

Сезгә күп сәламнәр белән хат язучы «Казан утлары» җегетләре. Зәки ага, хатыгызны һәм мәкаләгезне алдык, рәхмәт. Мәкаләгез кызыклы, ләкин әле миңа мәгълүм булган чыганаклар белән тулыландырсак, нур өстенә нур гына булыр дип уйлыйм. Киләчәктә, мәкаләне эшкәртеп чыккач, сезгә җибәреп, ризалыгыгызны алырбыз. Әфганстан турындагы хикәяләрегезне проза бүлеге җегетләре, өйрәнелү стадиясендә, диделәр. «Тарих Эстәрлебаш»ның фотокүчермәсен һәм М.Ш.Тукаевның фоторәсемен җибәрсәгез әйбәт булыр иде.

Зәки абый, сәламәтлегегез ничек? Госпитальдә ятасыз икән дигән хәбәрләр дә ишетелде, дөресме ул? Тизрәк сәламәтләнүегезне телибез. Сезгә бер үтенеч тә бар иде, Зәки абый. Чыңгыз Айтматовның 2 романы («Плаха» һәм «И дольше века длится день») 1986 елда Ригада 300 000 экземпляр булып басылып чыккан икән. Безгә, ягъни бүлмә җегетләре өчен дүрт китап табып җибәрә алмассызмы икән? Әлбәттә, госпитальдән сәламәтләнеп чыккач. Хат эченә акча тыгып җибәреп булмый инде, бәлки, наложенным платежом җибәрерсез.

Сезгә исәнлек, иҗат уңышлары теләп, Җәүдәт Миңнуллин. 25 февраль, 1987 ел». ■

Безнең мирас №12 декабрь 2021

«Бу дөньядан китеп барсам әгәр...»

(Фәнис Яруллинның көндәлек битләреннән)

Нурсөя һәм Фәнис Яруллиннар

30 май, 2011 ел

Мин төшкә кадәр, көндәлек булса да языйм, дип, ручкага тотынган идем, язып булмады, кул тыңламады.

Кызыклы вакыйгалар юк. Үзем әкрен-әкрен хәлсезләнә барам. Иҗат һаман артка чигенә...

26 июль, 2011 ел

Бу дөньядан китеп барсам әгәр,
Гаеп ташламагыз беркемгә.
Кайчагында түзү авыр була
Учка сыйдырырлык бер көнгә.

Соңгы вакытларда минем башка кара уйлар гына килә. Иҗат эшләре дә тукталды. Ахрысы, мин барлык гомер юлына сузылырлык эшләрне шушы яшәлгән 73 ел гомер эченә сыйдырып бетергәнмендер. Артык кызу барылды шул. Вакыйгаларны гел ашыктырдым. Шуның нәтиҗәсе буларак, туасы җаннар алданрак туды, кузгаласы җәнҗаллар алдарак кузгалды. Тамыры йөрәктә булган гауганы алып ташлау авыр.

Күкләрнең түбәсен ябып булмый –
Явасы яңгырлар барыбер ява.
Давылларга киртә корып булмый –
Тамыры чер(е)сә, зур имән дә ава.
Йөрәгемә әгәр ук кадасам,
Гаепләмәгез сез һичкемне.
Дөньядагы бик күп гаделсезлек
Суырып алды җаннан бар көчне.

17 сентябрь, 2011 ел

Озак вакыт чирләгәннән соң, өр-яңадан каләмгә тотыну. Бу әле нәрсә дә булса язу ниятеннән чыгып түгел, ә каләм тотып буламы икән дигән өмет белән. Менә беренче юлны язганчы, бер сәгать вакыт үтте.

Кеше туганнан башлап соңгы көненә кадәр үлем юлыннан бара. Ләкин юллар гына төрле-төрле: кемнеке – озын, кемнеке – кыска, кемнеке – борма-борма, кемнеке – тигез. Менә мин дә гомер юлымның соңгы адымнарын атлыйм. Шушы үлем юлының уртасында безнең кылган гамәлләр; әхлакый тәрбиябез; үкенүшатлыкларыбыз; күтәрелү яки төшүләребез; эшкә ашмый, бары тик уйда, хыялда гына калган уй-хисләребез ята...

(«Хәтер төпкелендә утлы күмер: көндәлекләр» дигән китаптан (Казан, 2013) алынды.)

Фәнис Яруллин

Хушлашу

Сау булыгыз, мин яраткан таулар,
Сау булыгыз, урман-кырларым.
Зәңгәр күккә йолдыз нуры белән
Язылыр, бәлки, соңгы җырларым.
Китәм инде, бик еракка китәм,
Болай да бик озак яшәлде.
Искән җилләр сиздермичә генә
Чупли торды баштан чәчләрне.
Агымсуда дулкын булып акты
Ак көннәрем, кара төннәрем.
Иң бәхетле мизгелләрне ләкин
Кара төннәргә дә бирмәдем.
Хәзинәне табу гына түгел,
Сакларга да кирәк һәрвакыт.
Мин аларны сөю кадерен белгән
Йөрәкләргә чыктым таратып.
Алар әле үзләре дә белми
Нинди байлык барын җанында.
Килер бер көн: ачылып китәр сандык,
Ут кабыныр алар канында.
Белмәс алар ләкин бу байлыкны –
Кем калдырган өеп көшелгә?!
Мин бәхетле барлык байлыгымны
Калдыруым белән кешегә.
Булды минем утлы яшен ташын
Учларыма кыскан чакларым.
Кайнарлыгы җанны өткәндә дә,
Мин аларны җиргә атмадым.
Яндым шундый яшен белән бергә,
Шулдыр, дидем, минем өлешем.
Суга салсаң, дөрләп янар иде
Шаулап аккан елга-инешең.
Туктыйм инде. Йөгем авыр булды,
Бара-бара тәмам өзлектем.
Авыр йөкне үргә сөйри-сөйри,
Үзәк сеңерләрне өздерттем.
Дошманнарым, әйдә, сөенсеннәр,
Ә дусларым? Алар бар микән?
Балачакта гына дөньялар киң,
Ә үскәчтен дөнья тар икән.
Кеше җирдә бары кунак кына,
Озак торса, кунак туйдыра.
Вакыт җиткәч, сиздермичә генә,
Китә алуларың ни тора!

2011

Редакциядән: Татарстанның халык шагыйре (2001), Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1995), 1968 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы, Баулы районының Кызылъяр авылы тумасы Фәнис Гатаулла улы Яруллин 2011 елның 8 декабрендә вафат булды. ■

Милләт гамьле Флера

Рәфыйк Шәрәфиев

Шагыйрә Флера Тарханова чыгыш ясый

Флера Габдрахман кызы Тархнованың «Язмышлар язылганда» исемле китабы (Татарстан китап нәшрияты, 2007), аның башка китапларына караганда да, авторның иҗат киңлеген, шул ук вакытта әдибәнең шәхесен, тамырларын тирәнрәк һәм тулырак ачадыр, мөгаен. «Әдипләребез» исемле мәгълүм белешмәлектә «шагыйрә һәм тәрҗемәче» дип кенә язылган Ф.Тарханова соңгы елларда үзе өчен проза жанрының да чит түгеллеген күрсәтте. Һәм нәкъ менә әлеге җыентыкта аның шигырьләре янында ике дистәгә якын эссе, парча һәм хикәяләре дә туплап бирелгән. 2012 елда басылган «Хисләр дәрьясында» исемле, зуррак күләмле китабы исә бер тарихи повестьтан, бәяннан, хикәяләрдән һәм бер музыкаль драмадан тора.

«Язмышлар язылганда» китабының иң башына урнаштырылган «Тамырлар» исемле шигырьдә мондый юллар бар:

«Инкяр итеп булмый: ни дисәк тә,
Мең кат үлеп, мең кат терелсәк тә,
Безнең тамырларда әле һаман
Болгарлардан кергән кан ага».

Әдибә, ихтимал, туган халкының ерак үткәне, дәүләт тоткан шанлы чорлары белән кызыксынуны үз нәсел тамырларын өйрәнүдән башлагандыр. Ә анда өйрәнер нәрсәләр булган шул. «Сагыш үрләде йөрәккә» исемле эссе, бер яктан, нәкъ әнә шул тамырларны ачып бирсә, икенче яктан, авторның үз нәселе киләчәгенә генә түгел, тулаем татар халкының киләчәгенә дә олы сагыш белән каравын күрсәтә һәм шуның белән укучыны да тирән уйларга сала. Уйланмаслыкмыни, Габдрахман Тархановның кайчандыр тугыз балага (Флера – өченчесе) очар канат, илгә хезмәт итәрлек белем, тормыш күнекмәсе биргән, әле тагын һәрберсен берәр яисә берничәшәр музыка коралында уйнарга, җыр-биюгә өйрәткән, әниләре һәм әниләренең әнисе аша кайберләренә шигырь язу сәләте дә өстәгән, күп еллар гөрләп торган оясы инде таралып бара икән ич. Болар бит нинди күренекле Тархановлар гаиләсе, болардагы тугыз баланың өчесе өч юнәлеш буенча фән кандидаты булу гына да ни тора! Алар бит татар халкын мәшһүр Гаяз Исхакыйлы иткән Яуширмә авылында яшиләр иде. Башка гаиләләрдә, бүтән авылларда тормыш кая бармас?! Әле кайчан гына алты йөздән артык хуҗалыгы булган Яуширмә инде бушап килә. Шул исәптән, Тархановлар оясы да буш. *«Балачакта бербөтен булып яшәгән балалар кайсы кая таралышып бетте,* – дип яза Флера ханым. – *Олыгайган, аралар ерагайган саен, балачактагы туганлык хисләре кими бара кебек тоела миңа. Туып-үскән йортта бергә туплап торучы кеше булмадымы, балалар шунда кайтып һәрдаим аралашып тормадымы, акрынлап бетә башлый икән ул якынлык».* Бик күпләр кычкырып әйтергә, ачыктан-ачык язарга җөрьәт итмәгәнне Флера ханым ике җөмлә белән ачкан да биргән.

Боларны язганда, Флера Тарханова үз нәсел-ыруын гына күз алдында тотмый, әлбәттә. Татар атлы зур гаилә бөтенләе белән дә үз тамырларыннан, туган йортларыннан ерагаеп, бүтәннәр арасында эреп-таралып бармый идемени? «Ник болай соң бу дөнья?» – дигән авыр сорау куя Флера ханым. Әмма ачык җавапны кем генә бирә алыр икән… Җәмәгатьчелек тә, милләт башындагылар да уйга килеп, авылларны тәмам таралып бетүдән саклап калу, аларны эшле, мәдәниятле, мәгърифәтле итү, тормыш шартларын шәһәрчә уңайлаштыру чараларын да күрә башладылар кебек үзе. Әмма шәһәрчәлектә татар өчен яңа хәтәрлек барлыкка килде: инде күпме гаиләләрдә фамилияләр татарча, бала исемнәре русча. Ана телләре дә – рус теле. Бу галәмәт Тархановларга кагылмагандыр да, бәлки. Ләкин ул татар милләтен күзгә күренеп сыегайта бара һәм әлеге тискәре хәрәкәтне беркем туктата алмый. Кемдер: «Татар кызлары һәм егетләре үз парларын үз милләтебездән тапсалар иде», – дип кенә чыгыш ясаса да, бу сүзләрне кырыкка төрләндереп, аның иясен әллә ниләрдә гаепләргә мөмкиннәр, моның мисаллары булды инде. Нәкъ шул сүзләрне Флера ханым ТНВ каналыннан да әйтте әйтүен, аңа мондый кыюлыкны йә мишәрлеге, йә «Зөләйха»ны язган Гаяз Исхакыйлы туган төбәге, йә горур Тархановлар нәселе биргәндер шул, башкаларга кая ул аңа тиңләшү! Үз дәүләтебез булса һәм ул татарча сөйләшсә, милләтнең «эрүе» һәм тел югалтулар беркадәр акрынаер да иде, бәлки. Әмма юкны каян аласың? Уфтанырга гына кала шул. Флера Тарханова «Упкын» исемле хикәясендә чып-чын милләт улы буласы бер яхшы хирургның, «әллә кайда үскән Рәсәй марҗасы» белән уртак тормышлары барып чыкмау аркасында, тормыш төбенә тәгәрәвен ышандырырлык итеп сурәтләгән. Бу катнаш никахлы гаиләләрнең һәммәсен шундый аянычлы язмыш көтә дигән сүз түгел, билгеле. Ул бер милләтле гаиләләрнең һәрберсе бәхетле

Флера Тарханова

Флера Тархановы каләмдәшләре котлый

яши дигәнне дә аңлатмый. Хирург Роберт та аңлый моны. *«Чит милләт кызлары арасында да тиешле тәрбия алганнары очрыйдыр. Алар белән дә бәхетле яшәгән татарлар бардыр. Дөрес, үз чибәрләребез дә меңтөрле. Әмма бер үк милләттән булган парлар арасында милли нигездәге каршылыклар, ызгыш-талашлар беркайчан да булмаячак та, тумаячак та. Ә иң авыры, йөрәккә барып кадалганның иң әрнүлесе – милләтеңне кимсетеп, хурлап әйтелгән сүз икән, сине тиңсенмичә, ким күреп яшәве икән»,* – ди хикәя каһарманы. Әдибә бу четерекле темага шигырьләрендә дә кат-кат әйләнеп кайта.

Филология фәннәре кандидаты Флера Тарханова «Югалган алтыннар» хикәясендә укучыны шактый чуалчык язмыш юлларыннан йөртеп, кыйммәтле тормыш сабагына өйрәтә: *«Кешегә белер-белмәс гаеп тагарга ашыкма! Ә инде күрәләтә яла ягасың, кешене рәнҗетәсең икән, моның «әҗере» үзеңә булмаса якыннарыңа да киләчәк, аң бул. «Урлаган бер гөнаһлы, урлаткан мең гөнаһлы»,* – дип өйрәттеләр безне борынгылар». Хикәядәге Мөхетдин дә, яшереп тот-

кан алтыннарын югалткач, бер гаепсез якыннарыннан шикләнеп тә, юха еландай яшь хатынына ышанып та гөнаһка батып кына калмый, көйле генә яшәп ятучы улы Сәләхетдин белән килене Бибиҗамалның тормышын чәлпәрәмә китерә. Җимерелгән тормышның ярчыклары тагын кемнәрнедер төзәлмәслек фаҗигага илтә. Шунысы да мөһим: автор бу хикәяне гыйбрәт өчен уйлап чыгармаган, аны, әтисенә аның абыйсы сөйләп калдыруы буенча, үз нәселләре тормышыннан алып язган. Гомумән, якын һәм ерак кардәшләре Флера ханымга «язарына азык» та, хәтта аз-маз язу күнекмәләре дә биргәннәр. Менә әтисенең олы абыйларыннан берсе – балалар «яшь бабай» дип йөрткән Нурулла, Гомәр Бәширов белән Балтач якларында мәгълүм органнарда эшләгәндә, булачак бөек язучы белән дуслашып кына калмый, үзе дә беркадәр иҗат белән шөгыльләнә (Гомәр Бәширов бер хатында аңа әсәрләрен «Совет әдәбияты» журналына җибәрергә тәкъдим итә). Флера ханым «яшь бабасы»ның кулъязмаларыннан икесен, кыска хикәяләргә әйләндереп, «Колдун» һәм «Шиһап мулла мәдрәсәсе» исемнәре белән, «Язмышлар язылганда» җыентыгына керткән.

Флера Тарханова колачларга омтылган әдәби жанрлар арасында шигърият барыбер беренче урында тора. «Язмышлар язылганда»дан чак кына элегрәк дөнья күргән «Яшьлек эзем калган сукмаклар» җыентыгына (Татарстан китап нәшрияты, 2005) шагыйрәнең шигырьләре, җырлары, поэмалары туплап бирелгән. Сиксәннән артык шигыренә композиторлар тарафыннан көй язылу үзе генә дә аның шагыйрә буларак зурлыгын күрсәтәдер. Кайбер әсәрләре өчәр-дүртәр композитор тарафыннан көйгә дә салынган, димәк, ошатканнар. Ә бит Флера ханым язган җырларны (һәм бүтән шигырьләрен) бик гадиләр дип булмый, аларның һәрберсен, мөгаен, үзләреннән-үзләре көйгә салынырга тора, дияр урын да юктыр. Нәкъ әнә шул тышкы яктан үтә гадәти булмаулары, тапталмаган формалары, тирән мәгънәләре, еш кына шәхес язмышларын милләт гамьнәренә бәйләп сурәтләүләре белән үзләренә тартадыр көй язучыларны аның шигырьләре. Флера ханымның робагыйлары да һәм форма, һәм эчтәлек җәһәтеннән бөтенләй үзгәләр, беркемне кабатламыйлар, беркемгә иярмәгәннәр:

«Күзләрем күрмәсен иде
телемнең җуелганын,
Ата-баба йоласының
җиремнән куылганын.
Милләтемнең үсүенә
ярдәмен бирсен Ходам –
Күтәрә алмам халкымның
корбанга куелганын».

Әдәбият галимнәре чыгарган «Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге»ндә («Мәгариф» нәшрияты, 2007) газәл хакында: *«Бу жанрның төп темасы – мәхәббәт, шуңа мөнәсәбәттә аны еш кына «гыйшык җыры» дип тә атыйлар»,* – диелә. Флера Тарханова газәлләрендә шушы классик тема, нигездә, сакланса да, алар өчен әдәп-әхлак темалары да ят түгел (үзеңне өстенгә санап, һаман кеше хурлыйсың...). Форма ягыннан да камил эшләнгән алар, әдәбият галимнәре боларны уңышлы татар газәленә өлге итеп күрсәтә алыр иде. Ләкин әле генә телгә алынган сүзлектә, ни сәбәпледер, замандаш

шагыйрьләрдән газәл жанрын яратып кулланучы дип бер Р.Гаташ кына телгә алынган. Шәрыкнең катлаулы үлчәмдәге классик шигърият формалары белән беркадәр мавыгып, Флера ханым «Язмышлар язылганда» китабына мөсәммән, мөстәзад, мөхәммәс, мөрәббәгъ, мөсәддәс, мөсәббә һ.б. кебекләрнең дә күп кенә үрнәкләрен керткән һәм һәр формага аңлатмалар биргән, димәк, шигырь язу белән бергә гыйльми вазыйфа да үтәгән. «Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге»ндә мондый шигырь формаларының бер-икесе генә аңлатыла. Шунысы аеруча игътибарга лаек: Флера ханым шәрыкча иске-яңа шигырь формасы белән язганда да милләт темасын, милли гамьне читтә калдырмый. Менә мөхәммәстән бер строфа:

«Милләтеңнең бөеклеген онытма,
Үз җиреңне каплаттырма «болыт»тан,
Сакла аны давыллардан һәм уттан,
Дошманнардан ябырылган мең уктан –
Бары шунда яшәп калыр милләтең».

«Яшьлек эзем калган сукмаклар» китабының «Багышлаулар» бүлегенә егермеләп әсәр кергән. «Багышлау» дигән шигърият төренең гаҗәеп бер үзенчәлеге бар: ул авторның шәхесен, тоткан кыйбласын ачыграк аңларга ярдәм итә. Флера ханымның «Син яшьлектән әле китмәгән» һәм «Килеп чыгарсың кебек тоела» исемле багышлаулары алдына «Н.С-кә» дип куелган. Шулардан алдагы «Фәтанәт кыйссасы» әсәрендә: «Сәйфиханымны үстердем Сыңар канатым белән», – дигән юллар бар. Нәкъ шулар әлеге хәрефләрнең серен ача: Татарстанның мөстәкыйльлеккә омтылышын хөкем итеп бастырудан баш тарткан мәшһүр прокурор Сәйфихан Нәфиев ләбаса бу. Шагыйрә менә нинди шәхесләргә йөз тотып иҗат итә!

«Җиңел тормыш белән яшәмәдең,
Хәсрәте дә булды, сагыш та.
Тезләндерер кебек тоелса да,
Җиңә алдың син бу алышта», –

диелә шигырьләрнең берсендә. Татарстанда мәрхүм прокурорның исемен мәңгеләштерү өчен ни дә булса эшләнгәне ишетелмәде кебек. Ярый әле аны шагыйрь-шагыйрәләр онытып бетерми (шагыйрь дигәнем Рәфыйк Юныс була). Ярый әле татар әдәбиятында милли гамьле милләттәшләребезне күрә һәм әсәрләрендә халыкка күрсәтә белгән, шул халыкның зурлыгын да һәм, катлаулы, фаҗигале язмышлар, гыйбрәтле хәлләр аша, милләттәшләребез кылган хаталарны да сурәтләп бирә алган шагыйрь-шагыйрәләр бар. Шуларның берсе – Флера Габдрахман кызы Тарханова.

2017 ел ■

Безнең мирас №12 декабрь 2021

ХӘМИТ КАВИНЫҢ ТУУЫНА 115 ЕЛ

Каһарман язучы

Равилә Мөбарәкшина



Хәмит Кавиев хатыны Мәрьям һәм уллары Илдар белән

Татар язучылары Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк илнең бәйсезлеген саклап калу өчен изге көрәшкә күтәрелә. Татар әдипләре һәм шагыйрьләре санынча корбан биргән бер генә милли әдәбият та юк. 34 татар язучысы сугыш кырларында ятып калды. Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Нур Баян, Рахман Ильяс үзләре генә дә дөнья бәһасе тора. Фашизмга каршы төзелгән яшерен оешма җитәкчеләре Муса Җәлил һәм Абдулла Алиш вәхшиләрчә үтерелде.

Прозада – Кәшфи Басыйров, Әхмәт Гыймадов, Хәмит Кави, драматургиядә – Мөхәммәт Әблиев, шагыйрьләрдән Демьян Фәтхи, Мифтах Вәдүт, Хәйретдин Мөҗәй, Әнәс Камал, Мансур Гаяз каләм белән дә, корал белән дә көрәште. Язучылар фронт газеталарына да мәкаләләр һәм очерклар яздылар, ялкынлы әсәрләре белән батырлыкка өндәп, җиңүне тизләттеләр. Алар арасында авылдашым Хәмит Кави (Хәмит Кавиев) да бар.

Ул 1906 елда Чуашстанның Козловка районындагы Әлмән авылында мәгърифәтле мулла гаиләсендә туган. Казанда педагогия техникумында, аннан Көнчыгыш педагогия институтының биология факультетында укыган. Аның 1936 елда физика-география кафедрасы аспиранты булуы турында белешмә бар. Хәмит

Хәмит Кави (икенче рәттә сулдан икенче) язучылар һәм галимнәр белән

Кавиев, география һәм геология фәннәрен өйрәнеп, илебезнең төрле почмакларына сәяхәтләр ясый һәм үзенең күргәннәре турында фәнни популяр очерклар, мавыгулы хикәя һәм повестьлар яза. Ул Советлар Союзының казылма байлыклар чыга торган урыннарында була, хәтта Арктикага да сәяхәт ясый. 1930 елда Хәмит Кавиның «Кавказ таулары аркылы җәяү» дигән китабы басылып чыга.

Аның 1932 елда дөнья күргән «Боз диңгезенә таба» исемле китабында Мурманск тимер юлы һәм шәһәре, ак төлкегә бай Кильдин атавы, балык тотучылар һәм болан асраучылар турында сөйләнә. Язучы авылдашым Казанда яши, барлыгы дистәгә якын китап чыгара. Шулар арасында «Идел буенда йөрү» (1931), «Балалар күмер өчен көрәшәләр» (1932), «Кузбасска сәяхәт» (1934), «Сәяхәт» (1939) һ.б. әсәрләр бар.

Татарстанның төрле районнарында йөреп, андагы табигый байлыклар, халыкның көнкүреше, мәдәнияте, районның географик үзенчәлекләре турында язган дистәләгән мәкаләләре республика матбугатында дөнья күргән.

Хәмит Кавиев Мех техникумында укыганда Әтнә районының Үртәм авылында туып-үскән Мәрьям исемле кыз белән таныша һәм гаилә кора. Казан-Мәскәү чаңгы сәяхәте оештырып, яшь буынга тәрбия бирүдәге зур хезмәте өчен Хәмит Кавига 1939 елда Мәскәүдә тышкы сәүдә халык комиссары имзасы куелган исемле сәгать бүләк ителә. Шул ук елны беренче балалары – Илдар, 1941 елда Илгиз туа.

Бөек Ватан сугышы башлангач, сентябрь аенда Хәмит Кави фронтка китә. «Исән-сау кайтсам, балаларыбыз күп булыр, «Ил»дән башланган исемнәр кушарбыз», – ди ул хатыны Мәрьям белән хушлашканда.

Лейтенант Хәмит Кавиев фронтта зур батырлыклар күрсәтә, медальләр белән бүләкләнә. Немец фашистларына каршы үз-үзен аямыйча көрәшкән язучы һөҗүмнәр вакытында, сугышчыларны рухландырып, алдан бара. Ул Бөек Ватан сугышында танк командиры булып, Идел буеннан көнбатыш чикләргә кадәр юл уза.

Язучы-танкист сугыш кырында да үзенең иҗат эшен дәвам итә, китаплары өчен материаллар туплый. Әмма бик күп әдипләребез кебек, хыялларын тормышка ашыра алмый кала.

Хәмит Кавиев хатыны Мәрьям, улы Илдар һәм туганнары белән

1944 елның 15 июнендә генерал-лейтенант Ватутин армиясе часте сугышчылары Көнбатыш Украинаның Волынск өлкәсендәге Дружкополь дигән урында ял иткән вакытта бендерачылар һөҗүм башлый. Өлкән лейтенант Хәмит Кавиев җитәкләгән танк тулы әзерлек белән көрәшкә керә. Сугыш барышында танкка ут каба. Экипаж әгъзаларының гомерен саклап, танк командиры Кавиев көрәштәшләрен аскы люктан чыгарып җибәрә, үзе, чыгарга өлгермичә, тереләй янып үлә. Танк дошман төркемен тар-мар итүгә зур өлеш кертергә өлгереп кала. Шушы батырлык хакында маршал Г.К.Жуков «Хатирәләр» китабында да искә ала. Кыю танкист өлкән лейтенант Хәмит Кавиевның исеме Дружкопольнең туганнар каберлегендәге ташка уеп язылган, улы – геология фәннәре кандидаты Илгиз Кавиев анда берничә тапкыр барган.

Язучы, педагог һәм сугышчы Хәмит Кавины, аның әти-әнисен, туганнарын зур ихтирам белән искә алабыз, алар белән горурланабыз. ■

Хәмит Кавиның улы, геология фәннәре кандидаты Илгиз Кавиев

Безнең мирас №12 декабрь 2021

КАРА ТӘКЪДИР

(Ачы язмышлы шәхесләр)

МАМИН МӨХӘММӘТША (1905-1943)

Мордовия төбәгендәге Зубова Поляна районының Горенка авылында хәлле игенче гаиләсендә туган. Татар әдәбияты тәнкыйтьчесе. «Һади Такташ поэзиясе» дигән хезмәт авторы.

1943 елның августында өлкән лейтенант Мамин Воронеж шәһәре тирәсендә барган сугышларда бик каты яралана һәм шул яраларыннан тернәкләнә алмыйча вафат була. Мөхәммәтша Мамин Воробьевка авылы зиратына җирләнә.

МАНСУРОВ БОРХАН (1889-1942)

Сарытау губернасының Хвалын өязендәге Иске Яшел авылында мулла гаиләсендә туган. Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты (ТатЦИК) рәисе. 1921 елның 25 июнендә «Татар телен гамәлгә кертү декреты»на кул куйган шәхес. 1937 елда ук каты авыруга дучар булган Борһан, НКВД тарафыннан гаепсезгә хөкем ителеп, Мәскәү өлкәсенең Ведогуща авылына урман кисү эшләренә сөрелә. Андагы эш шартлары каторгага тиң булып чыга. Ул, шунда салкын тидереп, 1942 елның 15 августында вафат була. Каберенең кайдалыгы билгесез.

Дәвамы. Башы журналның 10 нчы (2020) санында.



МАМУТ МУСА (1931-1978)

Кырымдагы Балаклава төбәгенең Узунчы авылында көтүче-чабан гаиләсендә туган. Кырым татары.

1944 елда, Муса унөч яшьтә чагында, Мамутовлар гаиләсен Кырымнан Урта Азия якларына сөрәләр.

1975 елда ул үз гаиләсе белән Ватанына – Кырымга кайта, йорт сатып ала, ләкин аны үзе сатып алган йортына теркәмиләр. Мусаны да, хатынын да зинданга ябалар. Иреккә чыккач та, аларны бик нык мыскыл итәләр. Муса, шул изүләргә чыдый алмыйча, үз өйләреннән куып чыгарырга килгән милиционерлар алдында үзен яндырып һәлак була. Аның кабере Биштирәк авылы янындагы зиратта.

МӘҮЛИТОВ ХӨСӘЕН (1893-1937)

Чистайда туган. Гаскәри. Ике тапкыр «Кызыл Йолдыз» ордены кавалеры.

Хөсәен Мәүлитовны 1937 елның 31 июлендә, гаепсез булса да, сылтау табып, зинданга ябалар. Каты җәзалаганнан соң, шул ук елның 30 октябрендә НКВД подвалында атып үтерәләр. Казанның бер урамы аның исемен йөртә.

МӨҖӘЙ ХӘЙРЕТДИН (1901-1944)

1901 елның 26 мартында Башкортстанның Туймазы районындагы Төрекмән авылында туган. Татар язучысы. Подполковник.

1942 елда Мөҗәй командалык иткән полк фашистлар камалышында кала һәм айдан артыкка сузылган авыр бәрелешләрдән соң, исән калган авыр яралылар, шул исәптән подполковник Х.Мөҗәй дә фашистлар кулына эләгә. Әсирлектә ул Мюнхен шәһәрендәге совет хәрби әсирләре лагеренда төзелгән антифашистик яшерен оешма җитәкчеләренең берсе була. Ләкин 1943 елның ахырында гестапо яшерен оешманың эзенә төшә, җитәкчеләрен Дахау концлагерена яба һәм, озак газаплаулардан соң, аларны үлемгә хөкем итә. 1944 елның 4 сентябрендә фашист палачлары атып үтергән туксан ике Дахау тоткыны арасында подполковник Х.Мөҗәй дә була.

Текстны басмага
***Рабит Батулла** әзерләде.* ■

Истә, һаман да истә!

Драматург Юныс Әминевнең туууна 100 ел

Драматург, язучы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, 1958 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Юныс Шәрип улы Әминев 1921 елның 1 декабрендә Татарстанның хәзерге Әгерҗе районындагы Салагыш авылында туган.

Ул 1936-1939 нчы елларда Минзәлә педагогика училищесында укый, аны тәмамлагач, бер ел Актаныш районында балалар укыта. Бала чагыннан ук әдәбият белән кызыксынган һәм үзе дә каләм көчен сынап караган Юныс Әминев 1950 нче еллар башында чынлап торып иҗат эшенә керешә: «Язылмаган законнар» исемле беренче күләмле әсәре (1956) аны сәләтле драматург итеп таныта.

Ул – 13 китап авторы: 30 еллык иҗат гомерендә 13 комедия, 6 драма, 6 бер пәрдәлек пьеса язган.

Ю.Әминев 1982 елның 3 декабрендә Әлмәт шәһәрендә вафат була.

Шагыйрь Сибгат Хәкимнең туууна 110 ел

Татарстанның халык шагыйре (1986), Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1960), Россиянең М.Горький исемендәге дәүләт бүләге иясе (1980), 1938 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе Сибгат Хәким (Сибгат Таҗи улы Хәкимов) 1911 елның 4 декабрендә Россиянең элекке Казан губернасындагы Царевококшайск өязенә караган (хәзер Әтнә районына керә) Күлле Киме авылында туган.

С.Хәким – «Юксыну» (Ш.Мәҗитов көе), «Фазыл чишмәсе», «Таң атканда» (Татар халык көйләре), «Күңелем Ленин белән сөйләшә» (Х.Вәлиуллин көе), «Башка берни дә кирәкми», «Кайда да йөрәктә» (М.Мозаффаров көе), «Өзелгәнсең сиреньнән» (Н.Җиһанов көе), «Бу кырлар, бу үзәннәрдә», «Кем уйлаган» (Җ.Фәйзи көе), «Әй язмыш, язмыш...» (С.Садыйкова көе), «Бер тауда ун чишмә» (Ә.Фәттах көе) кебек дистәләгән җыр авторы. Үзе исән чагында С.Хәкимнең Казан һәм Мәскәү нәшриятларында татар телендә һәм рус теленә тәрҗемәдә алтмышлап китабы басылып чыкты.

С.Хәким 1986 елда вафат булды һәм Казанның Яңа бистә зиратында җирләнде.

Тәнкыйтьче һәм шагыйрь Фәиз Зөлкарнәйнең тууына 70 ел

Әдәби тәнкыйтьче, шагыйрь һәм мөхәррир, 1985 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Фәиз Зөлкарнәй (Фәиз Мәүлит улы Зөлкарнәев) 1951 елның 4 декабрендә Башкортстанның Бакалы районындагы Сөендек авылында туган. 1964 елда Куштирәк урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, ул берничә ел колхозда клуб мөдире, мәктәптә лаборант һәм рәсем укытучысы булып эшли. Фәиз Зөлкарнәев 1970-1972 нче елларда Совет Армиясендә хезмәт итә. Армиядән кайткач, башта – колхозда механизатор, аннары Татарстанның Азнакай эшчеләр поселогында янгын сүндерүче хезмәтләрен башкара.

1974-1979 нчы елларда ул – Казан дәүләт университеты студенты. 1980-1983 нче елларда «Ялкын» редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1987-1989 нчы елларда исә Ф.Зөлкарнәй Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укый. 1990 елдан алып вафатына тиклем ул «Идел» журналының баш мөхәррире вазыйфасын башкарды.

Ф.Зөлкарнәй 1997 елның 18 июлендә юл фаҗигасендә һәлак булды.

Галимә Фирдәвес Гарипованың тууына 80 ел

Галимә, филология фәннәре докторы (1992), профессор (1993), ТРның (1995) һәм РФнең атказанган фән эшлеклесе (2003) Фирдәвес Гариф кызы Гарипова 1941 елның 7 декабрендә ТАССРның Биектау районындагы Кодаш авылында туган.

Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын 1965 елда тәмамлаганнан соң, ул Биектау районының Ямаширмә урта мәктәбендә укыта. Фирдәвес Гарипова ТР Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында 40 ел эшли, 1991 елда «Татарстан гидронимиясе» дигән темага докторлык диссертациясе яклый.

Фирдәвес Гарипова – ономастика, татар авыллары тарихы турындагы 900ләп мәкалә һәм ике дистәдән артык монография авторы.

Ф.Гарипова 2014 елның 4 ноябрендә Казанда вафат булды һәм Биектау районының Олы Битаман авылы зиратында җирләнде.

Җырчы Зиннур Нурмөхәммәтовның тууына 80 ел

Җырчы, ТАССРның халык артисты (1986), М.Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты (1978) Зиннур Закир улы Нурмөхәммәтов 1941 елның 11 декабрендә Әстерханда туган.

1967-1969 нчы елларда ул Әстерхан музыка училищесын һәм 1969-1970 нче елларда, төркемдәшләре Римма Ибраһимова һәм Клара Хәйретдинова белән бергә, Мәскәүдәге Бөтенроссия эстрада сәнгате иҗат остаханәсен тәмамлый. Зиннур Нурмөхәммәтов 1969-1991 нче елларда Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшли. Н.Җиһановның «Өзелгәнсең сиреньнән» (С.Хәким шигыре), С.Садыйкованың «Бөркет турында баллада» (Илдар Юзеев), «Уфа ни өчен матур?» (Н.Дәүли), Р.Яхинның «Җырланмаган әле безнең җыр» (Ә.Ерикәй), Р.Абдуллинның «Нигә, әни, нигә картаясың?» (Р.Вәлиев шигыре) дигән җырлары З.Нурмөхәммәтов башкаруында татар җыр сәнгате хәзинәсенә керде.

Җырчы 2003 елның 8 октябрендә Казанда вафат булды.

Шагыйрь Сириннең тууына 125 ел

Шагыйрь Сирин (Мөхәммәтсәйрин Хәниф улы Батыршин) 1896 елның 14 декабрендә Ютазы районының Кәрәкәшле авылында туган.

Башлангыч белемне туган авылында алганнан соң, ул Бәйрәкә авылындагы атаклы «Гобәйдия» мәдрәсәсен тәмамлый.

1922 елда Сирин Казанга килә һәм Татар рабфагына укырга керә. Яшь шагыйрьләр Һ.Такташ, Г.Кутуй, Х.Туфан, Ф.Кәрим белән таныша. Сирин 1927 елда кулга алына һәм Черек күл төрмәсендә утыз көн утырып чыга. Шуннан соң ул даими рәвештә күзәтү астында яшәргә мәҗбүр була. 1928-1929 нчы еллардан алып аның иҗатына совет чынбарлыгының кайбер якларын тәнкыйтьләү мотивлары килеп керә. Сирин җәмгыятьтәге тәртипләрне сатира утына алган «Паганини», «Ат кәмите», «Күтәрик бокалларны», «Сталинга эпиграмма» кебек шигырьләр иҗат итә. Әлбәттә, мондый әсәрләр ул чордагы хакимият вәкилләре игътибарыннан читтә кала алмый. 1935 елның 22 августында Сирин һәм тагын берничә язучы (Ә.Айдар, Г.Ризванов, И.Кули һ.б.) кулга алына, 1936 елның 31 гыйнварында, махсус киңәшмә карары нигезендә, Сирин биш елга Сиблаг лагерена озатыла. 1940 елның көзендә, сөрген срогын тутырып кайткач, бераз хәл алуга, үз теләге белән Бөек Ватан сугышына фронтка китә. Сирин 1942 елның көзендә, авыр контузия алып, Кәрәкәшлегә кайта, ә 1943 елның язында, үз теләге белән, яңадан фронтка җибәрелә. Шул ук елның ахырында ул, авыр яраланып, Ташкент шәһәренә госпитальгә озатыла. 1946 елдан башлап Сирин Баулы районының үзәге Акбуа поселогында яши.

Шагыйрь 1969 елның 23 ноябрендә Акбуада вафат була һәм шул поселоктагы татар зиратына җирләнә.

Шагыйрь Зәки Нуриның тууына 100 ел

Шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1983), 1951 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Зәки Нури (Зәки Шәрәфетдин улы Нуретдинов) 1921 елның 24 декабрендә Татарстан АССРның Чүпрәле районындагы Татар Төкесе авылында туган.

1957 елда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби Курсларны тәмамлап кайтканнан соң, З.Нури алты елга якын (1957-1963) Татарстан Язучылар союзының җаваплы секретаре, 1964-1971 нче елларда «Казан утлары» журналының баш редакторы, ә 1971 елның язынннан алып 1974 елның маена кадәр Татарстан Язучылар союзы идарәсе рәисе булып эшли. 1974-1982 нче елларда ул яңадан «Казан утлары» журналының баш редакторы хезмәтендә.

1945-1983 нче еллар арасында әдипнең татар телендә – 36, рус теленә тәрҗемәдә – 17, башка халыклар теленә тәрҗемәдә алты – барлыгы 59 исемдәге аерым китабы басылып чыга.

З.Нури 1994 елның 18 февралендә Казанда вафат булды.

Язучы Галимҗан Шәрәфнең тууына 125 ел

Тел галиме, язучы, җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче, татар дәүләтчелеген – Идел-Урал штатын төзү тарафдары Галимҗан Шәрәфетдин улы Шәрәф 1896 елның 29 декабрендә Казан губернасының Тәтеш өязенә (хәзер Татарстанның Буа районына керә) караган Аксу авылында туган.

Галимҗан Шәрәф 1917 елның 22 ноябрендә Уфада Милли Мәҗлес сессиясендә Идел-Урал штаты игълан ителүгә күп көч сала, әлеге җөмһүрият мәйданының картасын төзи. Идел-Урал штаты төзеләсе төбәктә 1920 ел урталарына өч административ берәмлек – Кече Башкортстан җөмһүрияте, Татарстан җөмһүрияте һәм Уфа губернасы барлыкка килә. Уфа губернасының язмышы референдум юлы белән хәл ителергә тиеш була. Ләкин 1922 елда Уфа губернасы Үзәкнең декреты белән генә Кече Башкортстанга кушыла. Татар халкының күп гасырлар дәвамында өметләнгән дәүләтчелеген торгызу теләге җимерелә барганын күреп, Г.Шәрәф сәяси активлыгын киметергә мәҗбүр була. Ул, гыйльми-фәнни эшчәнлеген көчәйтеп, 1919-1920 нче елларда Казан университетында Н.Ф.Катанов җитәкчелегендә – төрки телләр, Н.И.Ашмарин җитәкчелегендә – чуаш теле, В.А.Богородицкий җитәкчелегендә татар теле һәм гомуми тел белеме буенча тикшеренү эшләре алып бара.

Галимҗан Шәрәф 1937 елның 23 мартында кулга алына. 1940 елның 27 февралендә НКВД каршындагы махсус киңәшмә Г.Шәрәфне «Советка каршы милләтче оешма эшендә катнашкан өчен» 8 елга хезмәт белән төзәтү лагерена ябарга дигән карар чыгара. Хөкем мөддәтен Севердорлагта үткәреп, ул аннан 1945 елда кайта.

Г.Шәрәф 1950 елның 13 гыйнварында Казанда вафат була.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.*

Җуелмас хәзинә

«Кәләү Гайшә» җыры

«Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр».

Габдулла Тукай

Кәләү Гайшә

(Татар халык җыры)

Сак(ы)мар буйларында мин, ай, күп йөрдем
Бала(ы)выздай сары да ат(ы) берлән(е),
Бала(ы)выздай сары да ат(ы) берлән(е).

Үзеңне ләй күреп тә бер сөйләшми
Сүзем бетми язып та хат берлән,
Сүзем бетми язып та хат берлән.

Җаныкаем, сиңа да ни бирәем,
Мәкәрҗәдән килгән лә малым юк,
Мәкәрҗәдән килгән лә малым юк.

Җаннарымны ярып ла бирер лә идем,
Җандин үзгә йөрер лә хәлем юк,
Җандин үзгә йөрер лә хәлем юк.

Узган гасырның алтмышынчы-җитмешенче елларында радиодан «Кәләү Гайшә» көен, еш булмаса да, тапшыралар иде. Александр Ключарев белән Заһид Хәбибуллин башкаруындагы бу көй искиткеч моңлы яңгырый, тетрәндерерлек дәрәҗәдә тәэсирле иде. Берсе – пианинода, икенчесе скрипкада уйнап, бу ике зур музыкант көйнең бөтен асылын, үзәк өзгеч моңын тыңлаучының күңел түренә мәңге онытылмаслык итеп җиткерә белде.

Г.Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романын укыган булсагыз, хәтерлисездер: романның төп герое Зыя солдатка каралырга барган авылда искиткеч моңлы, күңелләрне, җанны тетрәндерерлек яңа көй ишетә. Бу көйне бер җүләр хатын гармунда уйный, көйне чыгаручысы да үзе, диләр. Җүләр хатын дигәннәре Гайшә

исемле икән. Үзе бер карчыкның бердәнбер кызы, бик моңаючан, җырчы кыз булган. Авылда җыр-биюдә, кубыз, курай һәм гармун уйнауда һичбер кыз аның кебек булдыра алмаган. Ул бик дәртле, хәтта чамадан артык дәртле булган. Матур егет, дәртле уенчылар күргәндә, үз-үзен онытырлык дәрәҗәдә ашкынып китә икән. Егетләр арасындагы иң матур һәм оста гармунчы егетне сөеп, шуңа ябышып чыккан. Ата-аналары моңа риза булмаган, аларны каргаган. Ләкин яшьләр, моңа карамыйча, күрше авыл мулласына барып никах укытканнар да бергә яши башлаганнар. Боларның мәхәббәт-яратулары шулкадәр көчле булган ки, баштагы вакытларда көннәр буе бер-берсенә карашып утыралар да, берсе уйнап, икенчесе җырлап гомер үткәрәләр, юньләп эшләмиләр дә икән. Авылда аларны гыйбрәт итеп тә, гайбәт итеп тә сөйләгәннәр, ләкин тегеләрнең моңа исе дә китмәгән. Беркөнне Гайшәнең ире Сәлахи тегермәнгә арыш тарттырырга киткән. Мөшкәгә арышын бушатканда, ничектер, аягы тегермән ташына эләгеп, барлык гәүдәсе тетелеп, үлгән. Гайшә, сөйгәненең үлемен ишетеп, тегермәнгә йөгереп килгән һәм, хәлне күреп, һушыннан язган. Әлеге фаҗигадән соң Гайшә акылын югалткан. Җиде төн урталарында урамнарга чыгып китә, бернәрсә дә эшләми, кеше белән сөйләшми, бик еш елый, гармунда уйный икән. Менә шулай уйный торгач, яңа көй чыгарган.

Әлеге көйне беренче мәртәбә ишеткән Зыя аны могҗизага тиңли: *«Моның музыкасында әллә нинди хисле йөрәк елый. Моның һәрбер авазында хәят трагедиясе, бетмәс күз яше, ачы күз яше белән тирән аһлар, тирән зарлар аңкый»,* – ди.

А.Ключаревның «Татар халык җырлары» китабында (1986) бу җыр «Оренбург татарлары җыры» дип бирелә. Разыя Тимерханова (1918-1997) – әлеге җырны беренчеләрдән булып өйрәнгән җырчы.



«Кәләү Гайшә» җырының нотасы

Сәхифәне, «Тәртип» радиосында яңгыраган «Саф вә раушан көзге» тапшыруы (авторы һәм алып баручысы – Гөлфия Мөхәммәтгәрәева) материалларына нигезләнеп, Ләбиб Лерон әзерләде. ■

Безнең мирас №12 декабрь 2021

Көлке куа килә...

Туфан Миңнуллин.
Н.Хаҗиәхмәт шаржы

Туфан Миңнуллин (1935-2012)

Ике робагый

Кичерегез, яшьтәш кызлар, сеңелләрем,
Нурияләр, Сәрияләр, Сөмбелләрем...
Гомер кыска – никадәрле ашкынсам да,
Барыгызны да яратып өлгермәдем.

Гарифҗан Мөхәммәтшин (1941)

Каз теле

(Арбор авылы мәзәге)

Түбән оч Габдерәшитнең кече малае армиядән русча өйрәнеп, татарчасын «онытып» кайта. Беркөн күрше-күлән шаулашып капка төбендә гәп сатып утырганда, бу егет, кемнеңдер сүзен аңламаганга салышып: «Как, как, как?» – дип сорап куя.

– И-и-и, берсеннән-берсе башлы булды Габдерәшитнең малайлары. Менә кечесе дә ике ел эчендә урыс телен генә түгел, каз телен дә ничек һәйбәт өйрәнеп кайткан бит! Ата казны уздырып, «как-как-как», дип утыра! – дигән күрше карты Хөрмәтулла абзый, кинаяле елмаеп.

Фаил Шәфигуллин
(1939-1982)

Ерак якларда

Туфан Миңнуллин вагон тәрәзәсеннән күз иярмәс тизлек белән артка шуышып торган карлы кырга карады да, үз алдына сөйләнгәндәй, әйтеп куйды:

– Семьялар ни хәлләрдә икән инде безнең?

– Безнең бәрәңге дә беткәндер инде, – диде Роберт Батуллин, – ачка тарып кына ятмасалар ярар иде...

– Шула-а-ай, – дип сузды Аяз Гыйләҗев, күзлек пыялаларын сөртә-сөртә. – Ни күрмәгәнне ат башы белән язучы хатыны башы күрә.

– Чыдарлар!.. – дип, урысчалап берничә суганлы-борычлы сүз кыстырды Барлас Камалов. – Кешеләр фронтта алтышар ел йөргәннәр...

Моңарчы әңгәмәгә катнашмыйча, биек маңгаен учына салып, уйга чумып барган Мөдәррис Әгъләмов тәрәзәгә күтәрелеп карады да, пассажирларны сискәндереп, кычкырып җибәрде:

– Җәмәгать, күрегез әле, бу якта да карама үсә икән!

Пассажирлар бу хәбәрне илтифатсыз гына кабул итте.

– Салам эскертләре дә бар! – дип сүзен дәвам итте Мөдәррис Әгъләмов.

– Рәсәй зур-р! – диде йодрыкларын яңакларына батырып уйланып барган Рәшит Әхмәтҗанов.

– Карама агачы Тау ягында да еш очрый...

– Дисеңме? – диде Мөдәррис Әгъләмов һәм тавыш килгән төшкә сузылып карады: югары киштәдә, йөзен «Огонек» журналы белән томалап, Әхсән Баянов ята иде.

– Карама үскән җиргә борчак чәчсәң, һәр гектардан уртача утыз җиде ярым центнер уңыш алып була, – диде Мөдәррис Әгъләмов.

– Сөйләмә тузга язмаганны! – диде кемдер.

– Агротехника чараларын җиренә җиткереп башкаргач, карама үскән җирнең һәр гектарыннан уртача кырык сигез ярым центнер борчак уңышы алган колхозлар бар, дустым, – дип, Мөдәррис Әгъләмов түш кесәсеннән тимер тешле тарагын тартып чыгарды һәм Рәшит Әхмәтҗановка күз кысып куйды.

– Авызыңны ерып барма әле, кабахәт, – диде Рәшит Әхмәтҗанов, еларга җитешеп, – синең семьяң юк, чортың юк, ә безнең хатыннар ач ята, өстәвенә, идән тулы бала-чага... Дөрес әйтәмме, Зөлфәт?!.

– Наплевать! – диде Зөлфәт һәм аяк өстенә торды. Кулларын кесәләренә тыгып, вагон тәгәрмәчләре тыкылдаган көйгә ниндидер көй сызгыра-сызгыра, әрле-бирле йөренә башлады. Аннары, нәрсәдер исенә төшкәндәй, кисәк кенә туктады, кулына соскы белән себерке күтәреп вагон буенча узып барган проводник агайның аркасына сукты:

– Простите, ресторан кайсы вагонда монда?

Проводник агай Зөлфәткә соңгы һөҗүм алдыннан матадорга баккан үгез сыман акаеп карады, әмма бер сүз дә әйтмәде.

Пассажирлар, ниндидер тамаша көтеп, тынып калдылар...

...«Казан-Арча» поезды Биектауга якынлашып килә иде.

(Язучыларның «Тынгысыз каләм» дигән дивар газетасыннан. 1978.)

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №12 декабрь 2021

Без барыбыз да – балачактан

«Балачак мирасы» сәхифәсе – иң әүвәл сезнең өчен, өлкәннәр. Халкыбызның күңел җәүһәрләрен – такмак-такмазаларны, табышмак-башваткычларны, әкиятләрне, әдипләребезнең хикмәтле һәм гыйбрәтле, мәгънәви һәм тәрбияви әсәрләрен хәтерегезгә сеңдерегез, аларны, озын-озакка сузмыйча, балаларыгызга һәм оныкларыгызга җиткерегез, нәниләргә бишек җырларын көйләргә дә онытмагыз. Кыскасы, укыгыз, уйланыгыз һәм бер нәтиҗә ясагыз да... һәрвакыт безнең «Балачак мирасы» белән бергә булыгыз!

Илдар Юзеев (1933-2004)

Самат хат яза

(Мәсәл)

Исәнме, Капчык бабай?
Сиңа хат яза Самат исемле малай.
Хәзер ул көйсезләнә, акыра.
Әти: «Алып китсен!» – дип сине чакыра.
Капчык бабай,
Мин инде елап туйдым бит,
Синең капчыгыңа сыймыйм бит.
Мин хәзер чиста да, тәти дә,
Шулай ди әни дә, әти дә.
Мин озак түзалмам,
Тагын елармын, акырырмын,
«Алып кит!» – дип, сине үземә чакырырмын.
Хуш, Капчык бабай!
Бу хатны язды Самат –
Әлегә тәти малай.

Җәвад Тәрҗеманов (1920-1995)

Йокы бабай

(Әкият)

Йокларга яратмый торган бер бала булган, ди. Кичен, караңгы төшкәч, әннәсе яки әттәсе, бабакае яки әбекәе аны караватка утыртуга, бала:

– Мин ятмыйм! Мендәр бә-ә-әк! Йокы бә-ә-әк! Бә-ә-әк! – дип акыра-бакыра елый башлый икән.

Бер кичне аның бу ямьсез сүзләрен ап-ак сакаллы Йокы бабай үзе ишетеп торган һәм, би-и-ик тә үпкәләп, тиз-тиз генә каядыр китеп барган.

Кич булган, төн җиткән. Ни хикмәт, берәү дә йоклый алмый икән. Мәчеләр мырылдаган. Кетәктәге әтәч-тавыклар, ишегалдына чыгып, арлы-бирле йөгерешә башлаган. Сарайдагы сыерлар өзлексез мөгрәгән, ә атлар тибенә-тибенә кешнәгән. Сыерларның шулкадәр мөгрәвенә, атларның туктаусыз кешнәвенә хәтта тр-р-рак-тор-р-р да чыдый алмаган: «Пыт-тыр-р-р, пыт-тыр-р-р…» – килгән.

Йоклый алмый интеккән кешеләр, нишләргә белмичә, әрле-бирле йөргәннәр. Бу хәлне күреп торган бала, йомшак мендәр кочаклап:

– Нәнәм… Йокы нәнәм… Нән-нә! – дип әйтүен үзе дә сизми калган.

Йокы бабай аның бу акыллы сүзен шундук ишетеп алган. Тылсымлы таягын нәзакәтле генә бер селтәп куюга, барча балалар, ә аннан соң әти-әниләр белән әби-бабайлар, кош-кортлар һәм җәнлек-җанварлар иртәгесе көнгә кадәр татлы йокыга чумган, ди.

Такмак

Иртән торып тышка чыксам,
Сыерлар кар көриләр.
Ә кәҗәләр, мылтык тотып,
Куян атып йөриләр…

Мөдәррис Әгъләмов (1946-2006)

Бүләк

Безнең туры атыбыз
Бер сылу колын бирде –
Басу аңа, сый итеп,
Бер тубал солы бирде.

Ә болын, бүләк итеп,
Бер арба печән бирде:
«Колының җаен миндә
Уйнаклап үсәр!» – диде.



Сәхифәне ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

НОЯБРЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● Ноябрьдә Татарстан китап нәшриятында, Татар ПЕН-үзәгенең 25 еллыгы уңаеннан, «Tatar PEN: Безнең юл. Наш путь. Our Way» дигән китап (проект авторлары – Разил Вәлиев һәм Ркаил Зәйдулла, китапны төзүчеләр – Әхәт Мушинский һәм Ленар Шәех) дөнья күрде.

● 7 ноябрьдә танылган шагыйрә, 1993 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты, Актаныш районының Иске Балтач авылы тумасы Фәйрүзә Әсгать кызы Мөслимова каты авырудан вафат булды. Җәсәде Самосыроводагы Мөселманнар зиратында җирләнде.

● 16 ноябрьдә «Татмедиа»да (Декабристлар урамы, 2 нче йорт) «Безнең мирас» журналының 30 еллыгына нисбәтле тантаналы чара узды. Әлеге күркәм юбилейда «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев, «Татмедиа» АҖ генераль директоры Шамил Садыйков, Татарстан Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, ТР Мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты рәисе Данис Шакиров, «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексының генераль директоры Әнәс Әскәров, Татарстанның халык шагыйрьләре Разил Вәлиев һәм Равил Фәйзуллин, «Безнең мирас» журналының редколлегия әгъзалары – академик Индус Таһиров, филология фәннәре докторы Хатыйп Миңнегулов, галимә Фәнзилә Җәүһәрова, җырчылар Ф.Каһиров, А.Тимершәех һәм Р.Бәдретдинова, Татарстанда нәшер ителүче газета һәм журнал редакцияләренең баш мөхәррирләре, «Безнең мирас» журналы һәм «Татар-информ» хезмәткәрләре катнашты.

● 17 ноябрьдә Минзәлә шәһәрендә С.Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театрының (директоры – Илнур Гайниев) 85 еллыгына багышланган чара үтте. Чарада ТР Мәдәният министры урынбасары Л.Хәкимҗанов, Татарстан Дәүләт Советы депутаты А.Хамаев, Минзәлә муниципаль районы башлыгы А.Сәлахов, драматурглар – Р.Батулла, Р.Сәгъди, Х.Ибраһимов, Л.Лерон һәм Р.Сабыр, режиссерлар – Ф.Ибраһимов (Чаллы), Р.Галиев (Түбән Кама)

һәм И.Гәрәев (Әлмәт), артистлар – И.Хәйруллин, А.Каюмова, Н.Нәҗмиев һәм И.Фәхретдинов, театр директорлары – Р.Садриев (Буа), Л.Зәйнуллин (Әтнә) катнашты һәм чыгыш ясады.

● 18 ноябрьдә балалар язучысы, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон Казандагы 369 нчы балалар бакчасында (мөдире – Дания Габдрахман кызы Исмәгыйлева) узган әдәби-музыкаль кичәдә катнашты.

● 19 ноябрьдә шагыйрь, прозаик һәм драматург, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, Казандагы 321 нче балалар бакчасында (мөдире – Нурия Нурислам кызы Камалиева) булып, үзенең юбилеена нисбәтле чарада катнашты. Бакчага йөрүче балалар шагыйрь сүзләренә язылган җырларны башкардылар, әдипнең шигырьләрен яттан сөйләделәр.

● 17-19 ноябрь көннәрендә Казанда «Иделем акчарлагы» яшь иҗатчылар бәйгесенең чираттагы йомгаклау чарасы узды. «Идел» («Волга») яшьләр үзәгендә узган чараларның берсендә жюри әгъзалары Ә.Закирҗанов, Л.Лерон, М.Закир, Г.Закирова, Л.Шәех һәм Р.Сәлах катнашты һәм бәйгедә катнашучылар

алдында чыгыш ясады. «Безнең мирас» журналы хезмәткәре, шагыйрә Энҗе Хөсәенова «Поэзия» номинациясендә Гран-прига лаек булды. Котлыйбыз, Энҗе!

● 20 ноябрьдә «Безнең мирас» журналы редакциясе Тәтеш шәһәрендә «Тәтеш тарихында тирән эз калдырган шәхесләр» дигән темага «түгәрәк өстәл»нең күчмә утырышын үткәрде. Әлеге чарада Тәтеш муниципаль районы хакимияте башлыгы Р.Сафиуллов, тарих фәннәре докторы, академик И.Таһиров, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, ТР Мәдәният министрлыгының массакүләм мәгълүмат чаралары һәм иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек бүлеге мөдире, тарихчы А.Фәйзрахманов, Татарстанның атказанган урманчысы И.Халитов, Тәтеш районының имам-хатыйбы, Тау Ягы казые Инсаф хәзрәт Җәләлетдинов, Татарстанның атказанган агрономы Х.Камалиев, ветеран укытучы һәм төбәк тарихын өйрәнүче М.Вәлиев, ветеран журналист һәм төбәк тарихын өйрәнүче Ф.Нәфиев, «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре, район газетасы журналистлары һәм мәктәп директорлары катнашты. ■

«Безнең мирас» журналының 2021 елга библиографиясе

Дөньяда сүзем калыр...

Әдип Маликов. – №8. – Б.3.
Габделхәй Сабитов. – №6. – Б.3.
Гамил Афзал. – №5. – Б.3.
Гомәр Бәширов. – №1. – Б.3.
Ибраһим Гази. – №11. – Б.3.
Илдар Юзеев. – №9. – Б.3.
Мөдәррис Әгъләмов. – №10. – Б.3.
Рәшит Әхмәтҗанов. – №4. – Б.3.
Сибгат Хәким. – №12. – Б.3.
Хакимҗан Халиков. – №2. – Б.3.
Шәехзадә Бабич. – №7. – Б.3.

Тарихи мирас

XIX гасыр хәлегъ документы. – №10. – Б.14-15.
А.Гайнетдинов. Бибимаһруй Үтәмешеваның кабер ташы. – №8. – Б.26-27.
А.Гайнетдинов. Зәйтүнә Мәүлүдованың кабер ташы. – №7. – Б.48-49.
А.Гайнетдинов. Мәхмүд Мәрҗанинең кабер ташы. – №1. – Б.32-33.
А.Дубин. Тукай Әстерханда. – №4. – Б.42-45.
А.Сәйфетдинов, Л.Гобәйдуллин. Киң вә гали табигатьле Омски имамы. – №8. – Б.16-20.
Ә.Гафуров. Кемнәр алар типтәрләр? – №3. – Б.22-27.
Ә.Маликов. Шәҗәрәбез тарихы. – №8. – Б.44-48; №9. – Б.40-45.
Ә.Шәрипов. Нефтькә багышланган мөнәҗәт. – №10. – Б.18-19.
Б.Шәрәф. Садри Максудов янында. – №5. – Б.9-13.
Бәҗәнәкләр. – №2. – Б.8-9.
В.Ихсанов. Сарманның атлы казаклары. – №10. – Б.24-26.
Г.Акчокраклы. Кырымда татар тамгалары. – №12. – Б.24-29.
Г.Баттал. Троицк байларыннан Габделвәли Яушев. – №8. – Б.33-43.
Г.Дувалова. Мамадыш җырулары. – №7. – Б.32-33.
Г.Мырзагалиева. Фатыйма ханым. – №4. – Б.46-51.
Г.Нуретдинова. Сарманлылар Беренче бөтендөнья сугышында. – №10. – Б.27-29.
Г.Төхвәтова. Зәйтүнә Мәүлүдова мирасы – музейларда. – №4. – Б.28-31.
Г.Хаҗиева. «Минем кулым түгел, Гайшә-Фатыйма кулы...» – №4. – Б.39-41.
Г.Ханнанова. «Бу бик ышанычлы кеше...» – №9. – Б.9-13.
Д.Гайнетдинов. Алтын Урда тамгалары. – №10. – Б.4-8.
Д.Гайфуллин. «Учитель мулла Садыйк». – №10. – Б.16-17.
Д.Кәшипова. Сарманның бәхетле Фатыймасы. – №10. – Б.20-23.
Җ.Миңнуллин. Татар хәйрия җәмгыятьләре. – №11. – Б.26-35.
Җ.Миңнуллин. Татар эшкуарлары: авылдан шәһәргә таба. – №12. – Б.17-23.
Җүчи ханның шәҗәрәсе. – №9. – Б.4-8.
З.Мөхәммәтшин. Кем ул Гуркин? – №11. – Б.4-6.
И.Бикколов. Рәссам вә мосаувир татар. – №11. – Б.7-9.
И.Газизуллин. Татарлар һәм удмуртлар. – №2. – Б.18-23.
И.Мифтахов. Нарва ислам җәмгыяте. – №9. – Б.20-28.
И.Мөстәкыймов. Блокноттагы истәлекләр. – №4. – Б.32-33.
Казан фаҗигасе. – №10. – Б.9-10.
Коточкыч ачлык. – №1. – Б.22-31.
Кыпчаклар. – №1. – Б.10-11.
Л.Габдрафикова. Актанышта Беренче бөтендөнья сугышы сәхифәләре. – №3. – Б.38-43.
Л.Габдрафикова. «Байлар гадәтенчә көчәнмәгез!» – №12. – Б.4-9.
Л.Гобәйдуллин. «Җиде тотам ук атты...» – №6. – Б.8-9.
Л.Гобәйдуллин. Кыпчаклар ничек сугышкан? – №3. – Б.20-21.
Л.Гобәйдуллин. Сөңгеле яуга тимер калканың әзер булсын... – №5. – Б.14-15.
Л.Лерон. Алтайның атаклы рәссамы. – №11. – Б.10-13.
Л.Мортазина. Тукай һәм «Сөембикә». – №4. – Б.12-17.
Л.Нәгыймов. Секира коралы. – №1. – Б.21.
Л.Пасыева. Владимирда Василий Тимофеев эзләре. – №7. – Б.34-36.
М.Гайнанова. Садри Максуди: «Фәкыйрь булмыйк, бетәрбез!» – №7. – Б.26-31.
М.Госманов. Әҗегә археографик сәфәр. – №2. – Б.24-28.
М.Госманов. Батый хан архивы: ике көн мичтә яндырылган. – №12. – Б.38-43.
М.Госманов. Имеш, мин чын-чын шагыйрь... – №11. – Б.34-39.
М.Госманов. Кульязмалар табып булмасмы? Кульязмалар!.. – №6. – Б.30-33.
М.Госманов. Минем соңгы археологик табышым... – №8. – Б.21-25.
М.Госманов. Нократ татарларына разведка. – №4. – Б.18-21.
М.Фәйзи. «Ай, авылда булырга!» – №10. – Б.42-47.
М.Фәйзи. «Җырлаулары белән сихерләндем». – №3. – Б.44-49.
М.Фәйзи. «Күңелебезнең үз иленә чыктык!» – №1. – Б.4-9.
М.Фәйзи. «Күңелем иркәсе булган авыл кызлары». – №7. – Б.50-55.
М.Фәйзи. «Күңелемне тартып калды». – №9. – Б.32-39.
М.Фәйзи. «Ямьнәр өстенә мәрҗәннәр тамды...» – №5. – Б.20-24.

Н.Галиева. Себернең югалган Казаны. – №8. – Б13-15.
Н.Гариф. Казан ханлыгында салымнар. – №2. – Б.10-11.
Н.Гариф. Коточкыч ачлык. – №9. – Б.29-31.
Н.Гариф. Татар көймәсе. – №7. – Б.16-17.
Н.Гафиятов. Кама аръягы төбәге татарлары тарихыннан. – №3. – Б.32-37.
Н.Каштанов. Кыр Бикшиге авылының Татарстан халкы белән туганлыгы. – №11. – Б.20-25.
Н.Мәхмүтов. Сарманның Фәхерле бәете. – №10. – Б.11-13.
Н.Михайлов. Аның тырышлыгы белән тоткыннар азат ителгән. – №7. – Б.4-43.
Р.Әминев. Башкорт-мещеряк гаскәрендә татарлар. – №3. – Б.28-31.
Р.Галләм. Җөри хан турында риваять. – №1. – Б.12-13.
Р.Мәрданов, И.Һадиев. И авылым, яшең күпме?.. – №5. – Б.16-19.
Р.Мәрданов, И.Һадиев. Казаннан читтә татар китабын бастырган матбагалар. – №1. – Б.22-28
Р.Мәрданов. Адниш хафизга бәйле табышмак. – №4. – Б.10-11.
Р.Мәрданов. «Әй шәкертләр, ваемсыз булмагыз!» – №6. – Б.10-12.
Р.Мәрданов. Ибраһим Хәлфиннең Казан тарихына багышланган хезмәте. – №3. – Б.55-57.
Р.Мәрданов. Кем ул Тогайка Беляков? – №7. – Б.18-25.
Р.Мәрданов. «Япон дигән патшага плин булдык…» – №9. – Б.14-19.
Р.Муллахмәтова. Ижау каласын ямьләгән якташыбыз. – №7. – Б.37-40.
Р.Нәфыйков, Ф.Вәлиев. Әйтикиннәр. – №8. – Б.4-9.
Р.Сәетов. Бараж нәселе яки Иске Сәфәр авылына кем нигез салган? – №12. – Б.30-33.
Р.Фәхреддин. «Себергә бөек гыйльми камиллекне бүләк итеп алып кайтты». – №8. – Б.10-12.
Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин. Коточкыч ачлык. №2-4, 7, 11, 12.
Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин. Омскидагы татар матбугаты. – №8. – Б.28-32.
Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин. ТАССРда беренче Сабан туйлары. – №6. – Б.22-25.
Р.Шәфигуллина. Сарман һәм Мөслим районнарының уртак тарих чорлары: 1963-1965 нче еллар. – №10. – Б.34-41.
Руи Гонсалес де Клавихо. Тимербәкнең илйортына сәяхәт (1404-1406) көндәлеге. – №2-7.
Ф.Әмирхан. Кабиләчелек низаглары. – №6. – Б.13-17.
Ф.Бәйрәмова. Түбән Варта шәһәре татарлары. – №6. – Б.18-21.
Ф.Бәйрәмова. Шәмсуар йолдызлыгы. – №1. – Б.14-20.
Ф.Закиров. Нагайбәк туганайлар, сез кайдан? – №12. – Б.10-16.
Ф.Зариф. Гәүһәршад. – №12. – Б.44-47.
Ф.Ислаев. Чирмешән төбәгендә ачлык. – №5. – Б.25-29.
Ф.Кутлу. Теләкләрем тормышка ашты. – №4. – Б.34-38.
Ф.Мусин. Яңавыл (Ирнур) – Мари Илендәге татар авылы. – №7. – Б.8-15.
Ф.Нәфиев. Хәзәрләр сабагы. – №2. – Б.12-17.
Ф.Салихова. Сарман сәяси репрессия еллары шаукымында. – №10. – Б.30-33.
Ф.Сәйфи-Казанлы. Ачлык падишаһлыгы (Спас кантоны). – №6. – Б.26-29.
Х.Габидуллина. Тукайга киемне кемнәр теккән? – №4. – Б.22-27.
Э.Сәлахова. Метрика язмаларында Актаныш төбәге. – №3. – Б.58-61.
Я.Мураками. Корыч эретүнең «Татара» ысулы: тарих һәм технология. – №11. – Б.17-19.

Татар гаме

«Әтрәч укулары»нда Туфан Миңнуллинны искә алдылар. – №9. – Б.46-49.
«Безнең мирас» котлый! – №4-12.
А.Борһанов. Ык елгасы үзәнлеге – ачылмаган тарих. – №6. – Б.40-42.
А.Горшкова. Чирек гасыр бергә. – №4. – Б.59-60.
Ә.Зарипов. Җәүһәр иясе Җәүһәриягә. – №1. – Б.42-47; №2. – Б.32-39; №3. – Б.70-75.
Б.Ваһабзадә. Очыгыз, тулпарларым! – №5. – Б.32-36.
Г.Толымбай. Бабичның беренче адымнары. – №7. – Б.56-60.
Г.Тукай. Валлаһи. – №8. – Б.76.
З.Зәйнуллин. Эстәрлебаш дарелфөнүне. – №11. – Б.50-53.
З.Нәҗметдинов. Мөслим авылы метрикәләре. – №6. – Б.43-46.
И.Таһиров. Хәкимов. – №9. – Б.64-70.
И.Һадиуллин: «Татар кешесе үзенең кыйблсасын сакларга тиеш». – №3. – Б.69.
И.Юзеев. Мин сездән, авылдашлар… – №9. – Б.55-58.
Иске Сәфәрдә – китап бәйрәме. – №12. – Б.54-55.
Казаковлар мирасын саклыйк! – №11. – Б.40-49.
Л.Гобәйдуллин. Тукай Троицкига кайтты. – №8. – Б.77.
Л.Лерон. Калининградка сәфәр. – №9. – Б.72-82.
Л.Лерон. Күмәчче Хәким оныгы яки Бисмиллалы гомер. – №8. – Б.61-68.
Л.Лерон. Туксанбайда – Акмулла авылында. – №12. – Б.48-52.
М.Әмирханов. Уразмәтнең фаиз углы. – №1. – Б.34-41.
М.Вәлиев. «Сары умырзая эзләдем». – №9. – Б.50-54.
М.Шәймиев. Нурлы шәхес. – №4. – Б.56-58.
М.Шәймиев. Ышанычыбыз аклана. – №8. – Б.60.
Мифтахетдин Акмулла шигырьләре. – №12. – Б.53.
Наил Вазыйхов: «Яшьләрне авылда калдыру – мөһим мәсьәлә» – №11. – Б.54-58.
Нурихан ага ватанында. – №8. – Б.78-79.
О.Хисамов. Минзәлә сөйләше. – №3. – Б.64-68.
Р.Җамал. Атлар, этләр һәм кешеләр. – №10. – Б.58-63.

Р.Муллин. Мөслим турында уймак уйлар. – №6. – Б.34-36.
Р.Харис. Ике халыкның мирасы. – №5. – Б.30-31.
Р.Шәрәфиева. Чын халык шагыйре. – №7. – Б.64-65.
С.Сәлимшина-Шаһимәрданова. Тукай «таныштырды». – №4. – Б.61.
Төбәкне өйрәнүчеләр җыены. – №6. – Б.38-39.
Туган тел – изге тел. – №3. – Б.62-63.
Ф.Бәйрәмова. Себер сүзе. – №8. – Б.70-76.
Ф.Нәфиев. Акыл – мидәге сырлар... – №9. – Б.63.
Ф.Уразай. Җәфалый торган җанисәп. – №10. – Б.53-57.
Фәрит Хөснуллин: «Үткәнебез – горурланырлык, киләчәгебез – өметле». – №10. – Б.48-52.
Х.Әюп. Ык буенда җил исә... – №6. – Б.37.
Хаҗи Абдулла Дубин. – №3. – Б.76-77.
Ч.Зарипова-Четин. Остазым Рәдиф Гаташ турында. – №4. – Б.63-69.
Чүпрәледә – «Мунчәли укулары». – №9. – Б.59-62.
Ш.Бабич. Мәхәббәт тоткыны. – №7. – Б.61.
Ш.Бабич. Хөррият бүләге. – №7. – Б.62.
Шәехзадә Бабич музее. – №7. – Б.66.

Дини мирас

2021 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр. – №1. – Б.72.
А.Али. Ислам хакында хакыйкать. – №1. – Б.60-61.
Азиз Али шигырьләре. – №1. – Б.64-65.
Ә.Рәхими. Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре. – №12. – Б.69.
Габдерәшит Ибраһимов. Ислам дөньясы. – №1-12.
Җ.Али. Әтием Азиз Али турында. – №1. – Б.62-63.
И.Җиһаншин. «Тәбәнәк Бохаралы»ның бөек эшләре. – №12. – Б.64-68.
И.Таһиров. Мәңгелеккә юнәлеш. – №1. – Б.54-59; №2. – Б.46-51.
Исмәгыйль хәзрәт Сәлимшин нәсыйхәтләре. – №9. – Б.89-91.
Л.Байбулатова. Ризаэддин Фәхреддин милләтләр үсеше турында. – №7. – Б.74-75.
Н.Исхаков, Р.Исхакова. Үтәмеш: беренче мәхәллә тарихы. – №5. – Б.44-49.
Н.Исхаков, Р.Исхакова. Үтәмеш: дини хәрәкәт. – №6. – Б.55-59.
Р.Фәйзрахманов. Мөхәммәд (с.г.в.) сөннәте һәм татар галимнәре. – №2. – Б.52-55.
С.Бикбулат. Дин дәресләре. – №7-12.
С.Сәлимшина-Шаһимәрданова. Нарыш аксакалы. – №1. – Б.66-71.

Әдәби мирас

«Бу дөньядан китеп барсам әгәр...» – №12. – Б.90-91.
«Ялкын»лы ялкынлы еллар хатирәсе. – №1. – Б.88-89; №4. – Б.86-87.
А.Тимергалин. «Кешеләрне кызганам...». – №10. – Б.84-85.
А.Хәмзин. Кыйсса итеп сөйләрлек. – №11. – Б.85-86.
Ә.Шәрипов. Такташ һәм Сирин. – №1. – Б.80-83.
Ә.Шәрипов. Хәсән Туфан һәм Сирин. – №12. – Б.75-77.
Әхмәд Ләбиб Каран (1887-1964) шигырьләре. – №7. – Б.78-81.
Белмим, үзең сизәсеңме... – №1. – Б.87.
Г.Каюмова. Ризван Хәмиднең «Хан кызы» драмасында Сөембикә ханбикә образы. – №10. – Б.88-93.
Г.Төхвәтова, Л.Медведева. Безнең өчен мәңге изге йорт... – №2. – Б.56-59.
Г.Утыз-Имәни. Дөррәт әл-фахирә яки Ахирәтнамә. – №5. – Б.56-61; №6. – Б.64-69; №7. – Б.82-87.
Гарифҗан Мөхәммәтшин шигырьләре. – №11. – Б.82-83.
Зәки Нури шигырьләре. – №12. – Б.82-83.
И.Гази. Безнең авыл. – №11. – Б.76-81.
И.Гази. Яңгыр астындагы мәхәббәт. – №11. – Б.84.
И.Таһиров. Тукай мәңгегә халык күңелендә. – №4. – Б.80-85.
М.Әгъләмов. Әби биргән сабак. – №10. – Б.86-87.
Мамадыш шагыйре. – №7. – Б.90-91.
Н.Каштан. Фәтхи Бурнаш һәм шәһри Казан. – №1. – Б.84-86.
Р.Ахунҗанова. «Кайсыгызның кулы җылы?» – №6. – Б.70-71.
Р.Туфитуллова. Сыкрау. – №2. – Б.70-73.
Р.Фәттахова. «Алар бик нык ышаналар...» – №8. – Б.53-56.
Р.Шәрәфиев. Милләт гамьле Флера. – №12. – Б.92-96.
С.Баттал. Тукай һәйкәле янында. – №2. – Б.68-69.
С.Сөләйманова. Югалган дәфтәр. – №10. – Б.79-83.
Садрый Хәмид (1905-1987) шигырьләре. – №2. – Б.60-63.
Т.Галиуллин. «Гомернең дулкыннары» турында. – №4. – Б.88-90.
Т.Галиуллин. Тәңре юлында. – №7. – Б.88-89.
Тугры Шәйхи шигырьләре. – №7. – Б.92-93.
Үткәннән хатлар. – №12. – Б.88-89.
Ф.Зөлкарнәй. Сүз шатлыгы. – №12. – Б.78-81.
Ф.Фәтхелисламов. «Котадгу белек» – бәхетле итүче белем. – №4. – Б.70-72.
Х.Миңнегулов. «Игү аты»н калдырган инсан «үлемсез». – №5. – Б.50-55.
Х.Миңнегулов. «Тарихын белгән халык – теп-тере бер милләттер». – №3. – Б.84-87; №4. – Б.73-79.
Х.Миңнегулов. Бөек шагыйребез Котб әсәренең Истанбул басмасы (1968). – №10. – Б.74-78; №11. – Б.68-69.
Х.Миңнегулов. Сәйф Сараи лирикасыннан мисаллар. – №6. – Б.60-63.
Х.Миңнегулов. Суомида татарлыкны дәвам иттерүче. – №1. – Б.74-79.
Х.Миңнегулов. Татар мөһаҗире Рәсәйнең элеккеге башкаласында. – №12. – Б.72-74.
Х.Миңнегулов. Тукайның Суомида басылган бер җыентыгы. – №8. – Б.49-52.
Хәсән Туфан ядкяре. – №2. – Б.64-67.
Ш.Юзеева. «Ихласым бик дан – милләт юлына». – №11. – Б.72-75.

Ш.Юзеева. Җыр белән атлыйбыз. – №12. – Б.84-87.
Э.Шәрифуллина. Әдип абый – әдәп үрнәге. – №8. – Б.56-59.
Э.Шәрифуллина. Горурлык хисе. – №2. – Б.74-79.
Э.Шәрифуллина. Соклангыч шәхес иде. – №11. – Б.70-71.

Очты дөнья читлегеннән

Л.Лерон. Илдар Юзеев вафаты (1930-2008). – №1. – Б.90-93.

Хәтер сандыгы

А.Вәлиева. Себерне өйрәнгән галим. – №8. – Б.88-95.
Ә.Хәйри. Остазларым белән горурланам. – №11. – Б.87-91.
З.Бәширов. Гомәр Бәшировның фотомирасы. – №1. – Б.94-96.
И.Низамов. Мирасыбыз хәзинәсенә бөртекләр. – №11. – Б.92-96.
Истә, һаман да истә! – №1-12.
Л.Мөхәммәтҗанова. Себер киңлегеннән – халык күңеленә. – №8. – Б.96-99.
Л.Хәмидуллин. Аркаимга сәяхәт. – №10. – Б.100-103.
Мирхәйдәр Фәйзи кабере – Баймакта. – №11. – Б.97.
Н.Камалиева. Рәшит Ваһапов белән очрашулар. – №4. – Б.112-113.
Р.Батулла. Кара тәкъдир. – №1-12.
Р.Батулла. Нәселдәнлек. – №5. – Б.68-73.
Р.Мөбарәкшина. Каһарман язучы. – №12. – Б.97-99.
Р.Хәбибуллина. Мөслим бабай варислары. – №5. – Б.62-67; №6. – Б.72-79.
Р.Хәйруллин. Мамадышның мәшһүр рәисләре. – №7. – Б.94-97.
С.Сәүбанова. Адәм баласыниләр күрми. – №5. – Б.76-80.
Сүз һәм сурәт. – №7. – Б.98-101.
Т.Галиуллин. Гамьле затлар онытылмый. – №10. – Б.94-100.
Ф.Бәхтияри. Меңләгән кешенең әңгәмәдәше һәм сердәше. – №4. – Б.108-111.
Ф.Закиров. «Казан мәгарәсе»ндә очрашу. – №1. – Б.97-101.
Ф.Садыйков. Мөгаллим язмалары. – №2. – Б.80-85.
Э.Сәлахова. «Истәлек итеп сакларсың!» – №6. – Б.80-85.
Э.Шәрифуллина. Каракош. – №6. – Б.86-91.
Э.Шәрифуллина. Фаил блокноты, Ишморат хаты... – №5. – Б.74-75.

Фикер дәрьясы

Р.Садриев. Нигез. – №2. – Б.90-93.
Р.Садриев. Яһүдләрчә. – №1. – Б.106-109.
Р.Сәгъди. Театр яктысы. – №2. – Б.94-95.

Сәнгати мирас

«Әллүки» җыры. – №4. – Б.102-103.
«Баламишкин» җыры. – №6. – Б.108-109.
«Бөдрә тал» җыры. – №11. – Б.108-109.
«Галиябану» җыры. – №3. – Б.112-113.
«Зәңгәр күз» җыры. – №10. – Б.110-111.
«Кәләү Гайшә» җыры. – №12. – Б.106-107.
«Ком бураны» җыры. – №5. – Б.110-111.
«Күзге ачы җилләрдә» җыры. – №9. – Б.110-111.
«Су буйлап» җыры. – №8. – Б.110-111.
«Тәфтиләү» җыры. – №2. – Б.112-113.
«Туган тел» җыры. – №1. – Б.112-113.
«Хәмдия» җыры. – №7. – Б.110-111.
Ә.Зарипов. Аллаһ колының варисы. – №5. – Б.95-101.
Ә.Зарипов. Алтын йөрәкле кеше. – №11. – Б.102-107.
Ә.Зарипов. Әнвәр абый Гобәйдуллин рухына догам... – №8. – Б.104-107.
Ә.Зарипов. Онытылмасын Гай бабай. – №6. – Б.102-105.
Г.Сафиуллина. Затлы дәвам фестивале. – №2. – Б.96-103; №3. – Б.92-99.
З.Гыйльметдинова. Татар җырчылары. Кадерле мизгелләр. – №1-9, 11.
И.Диндаров. «Ярмәк вагы». – №7. – Б.106-109.
К.Саттаров. Алмания безне алкышлады. – №5. – Б.90-94.
К.Саттаров. Алманиягә сәфәр. – №4. – Б.91-95.
К.Филиппова. Арчада «Җыр бәйрәме». – №9. – Б.104-107.
Л.Нәгыймов. Милли музейда – ПЕ-2 самолеты. – №6. – Б.110-111.
М.Хәбибуллин. Чал тарихка бер караш. – №2. – Б.104-109; №3. – Б.100-111; №4. – Б.96-101.
Ф.Арслан. «Җырлаганда... җылата иде». – №5. – Б.102-109.

Без – татарлар!

Г.Тукай, Р.Фәхреддин, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Дәрдемәнд, Н.Фәттах. – №3. – Б.2-3.

Тел күрке – сүз

Р.Юсупов. Матбугат һәм туган тел. – №5. – Б.84-89; №6. – Б.96-101.

2021 ел – туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы

Минтимер Шәймиев: «Телне саклап калуга һәркайсыбыз тиңсез өлешен кертә ала». – №3. – Б.4-9.
Мин татар! – №3. – Б.10-11.

Шаян мирас

Көлке куа килә... – №1-12.

Балачак мирасы

Без барыбыз да – балачактан. – №5-12.

«Безнең мирас» хәбәрләре. – №1-12.
Мирасворд. – №1-12.
«Безнең мирас» елъязмасы. – №1-12.

*Басмага **Ләйсән Данилова** әзерләде.* ■

МИРАСВОРД

Күренекле татар шагыйре

Бензин маркасы

Шагыйрь Зәки ...

Риза булу

... Юзиев

Гете трагедиясе

Эскимос көймәсе

«Чияләнгән ...» (Ринат Мөхәммәдиев)

Шагыйрь ... Сафин

Син ... дә мин ...

...-клукс-клан

... Хангилдин (тел белгече, педагог)

Күп яки ярамаганны ашап маемлау, күңел болгану

Грузин халкының этнографик төркеме

Быргы (иск.)

Мавритания акчасы

Грек мифологиясендә гайбәт Алласы

... елан

Гарәп артикле

Гарәп-фарсы, төрки халыкларда бәрмә уен коралы

Әйттем ... кайттым

... Гарипов (башкорт шагыйре)

Сибгат Хәким поэмасы

Язучы, «Язгы җилләр» романы авторы

Мәркәзе – Вьентьян

Тирә-як, әйләнә-тирә (иск.)

Актриса ... Хәйретдинова

Аяз Гыйләҗев повесте

Сибгат Хәким сүзләренә Шакир Мәҗитов язган җыр

Борынгы ныгытма, кальга

Татарның акча янчыгында

Акмал, Даутов

Кириллица хәрефе



Мирсәй ...

Латвиянең еврога кадәрге акчасы

Себер шаманы

Ханның язма указы, грамота

Фәүзия Бәйрәмованың 2015 елда чыккан китабы

Япон театры

... Акмулла

Он тузаны

Мисыр мифологиясендә кояш Алласы

11 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: «Рәүфә», Ярми, Перро, Иркә, Амаяк, ату, әрдәнә, Урда, ама, көлтә, бурлат, исә, вә, Әнәс, тән, ип, Әтнә, Роза, вирд, Пикуль, Бату, Порт, Неру, шор.
Өстән аска: Әбелмәмбәтов, арау, әзи, «Фөрьяд», «Нарспи», кәрлә, Ания, Брно, «Мәктәп», патер, Тит, Яхин, «Ул», Кутуй, «Артист», мөкатдәс, Нил, уа, әпә.

Рәис Габдулла төзеде.

«Безнең мирас»
елъязмасы / декабрь

Казандагы Һади Такташ һәйкәле. ***Фотосурәт realnoevremya.ru сайтыннан алынды.***

785 ел элек (1236)

Бату (Батый) хан Идел буе Болгар дәүләтен яулап ала.

550 ел элек (1471)

Литва кенәзе Казимир, Мәскәү кенәзлеге һөҗүмнәрен татарлар кулы белән туктатырга өметләнеп, Олы Урдага илче итеп Кирәй атлы татар кешесен җибәрә.

145 ел элек (1876)

2 декабрьдә күренекле сәяси эшлекле, Төркия Президенты Мостафа Кәмаль Ататөрекнең мәдәният һәм сәясәт эшләре буенча киңәшчесе Йосыф Акчура (1876-1935) дөньяга килә.

115 ел элек (1906)

Декабрь аеннан, атнага ике мәртәбә үзбәк телендә чыгып килгән «Тәрәккъый» (мөхәррире – Казан татары Исмәгыйль Габиди) газетасы, «мәсләге хөкүмәт өчен зарарлы», дип, Рәсәй хөкүмәте цензорлары тарафыннан чыгудан туктатыла.

95 ел элек (1926)

21 декабрьдә Татарстан китап палатасы оештырыла.

90 ел элек (1931)

8 декабрьдә Һади Такташ (1901-1931) вафат була.

10 ел элек (2011)

15 декабрьдә Марсель Сәлимҗанов исемендәге Актерлар йортында тәнкыйтьче, шагыйрь, галим вә мөхәррир Фәиз Зөлкарнәйнең (1951-1997) тууына 60 ел тулу уңаеннан «Кайту» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Кичәне шагыйрь Ркаил Зәйдулла алып барды.

Журналга ***Айдар Закиров*** *әзерләде.* ■

Содержание. Декабрь 2021

И останется в мире слово моё...: Сибгать Хаким.

Историческое наследие: «Откуда будете, потомки нагайбек?» Ф.Закиров; «Племя Бараж или кто основал деревню Старое Сафарово». Р.Саетов; «Страшный голод»; «Архив Батый хана: два дня топки в печи». М.Гусманов; «Гаухаршад». Ф.Зариф.

Татарский мир: «В Туксанбае, в деревне Акмуллы». Л.Лерон; «Праздник книги в Старом Сафарово».

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов; «Хадисы пророка Мухаммада (с.г.в.)». А.Рахими; «Уроки религии». С.Бикбулат.

Литературное наследие: «Татарский эмигрант в бывшей столице России». Х.Миннегулов; «Стихи Заки Нури»; «Писатель-герой». Р.Мубаракшина.

В глубинах памяти: «В памяти, до сих пор в памяти!»

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Алхәбәр:

Шиһабетдин Мәрҗани кабере (Яңа Татар бистәсе зираты)
(«Шиһабетдин Мәрҗани вафаты – замандашлары истәлекләрендә»)

- **Татар ул – дәүләти халык. Индус Таһиров**
- **Арба гына димә. Тәлгат Галиуллин**
- **Атлы кеше вакыты кайтырмы? Зәрия Хәбипова**
- **Милләт сагында. Фираз Харисов**
- **Нурихан Фәттах көндәлекләре. Руфинә Фәттахова**
- **Шиһабетдин Мәрҗани вафаты – замандашлары истәлекләрендә**

Фотоларда — Сибгат Хәким һәм аның замандашлары

Сибгат Хәким һәм Мәхмүт Хәсәнов балалар белән очрашуда. 1978 ел

Сибгат Хәким һәм Сара Садыйкова



Шагыйрь Сибгат Хәким хатыны Мөршидә һәм улы Рафаэль белән



Казандагы 13 нче мәктәптә. Сулдан уңга: Сибгат Хәким, Усман Әлмиев, Нур Баян, Җәүдәт Фәйзи, Муса Җәлил. 1939 ел

Сибгат Хәким (уңда) һәм Әхмәт Фәйзи



БАКЧАСАРАЙ ЯДКЯРЛӘРЕ

Исмәгыйль Гаспринский музеендагы экспонатлар. Кырым, Бакчасарай

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 51), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.